Мансур Шиһапов

# Җырлыйсы җырларым бар әле



Җырлар,
шигырьләр,
публицистика

Казан
Татарстан
китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-6
Ш 48

**Шиһапов Мансур**

Ш 48 Җырлыйсы җырларым бар әле: Җырлар, шигырьләр, публицистика. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 239 б.

Әлеге китапка танылган шагыйрь Мансур Шиһаповның җырлары, шигырьләре, очерк һәм мәкаләләре тупланды.

ISBN 5-298-04064-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Мансур Шиһапов, 2005

## *Еракка яңгырасын безнең җыр!*

Мансур Шиһапов — якташым ул минем. Хәер, кешеләрне олы мәгънәгә ия берәр максат, уртак эшчәнлек берләштермәсә, якташлыкның әллә ни әһәмияте юк. Безне берләштерә торган уртаклык — халкыбызга, туган ягыбызга ихлас хезмәт итү дип беләм. Без — гади халык арасыннан чыгып иҗатка килгән кешеләр. Мантыйк буенча, үзебезне үстергән шул халыкка хезмәт итәргә, алган хакны кайтарырга тиешбез дә.

Бер авылда туып, бер мәктәптә укымасак та, бер урамнарны таптап, кичләрен кыз-кыркын озатышып йөрмәсәк тә, Мансур замандашны кырык еллап беләм инде мин. Беренче очрашуларда ук «киң күңелле, тапкыр, аралашучан, оештыру эшләрендә махир, олпат кеше икән бу абзый» дигән фикер калган иде. Күп еллар үтеп, яши-яши, күңелдә кайбер төсмерләр үзгәрсә дә, фикер үзгәрмәде, хәзер дә аны шул сыйфатларга ия дип беләм.

Мансур Шиһапов гомере буе иҗат кешеләре күмәк булып оешкан коллективларда эшләде. Аның рухы һәм сәләте шулай кушадыр инде. Татар дәүләт драма һәм комедия, курчак театрларының директоры, Г.Камал театрының баш администраторы, Язучылар берлегенең оештыру эшләре буенча рәис урынбасары, Зур концерт залының директоры... Гел халык арасында, гел иҗат кешеләре белән бергә. Гадәттә, иҗат эше ялгызлыкны, тынычлыкны тансыклый. Күп әсәрләр дөнья белән бергә-бер ялгыз калып илһамланганда туа. Әмма жанрларның да төрлесе бар бит; әйтик, җыр — демократик, халыкчан жанр. Өстәвенә шагыйрь, композитор, башкаручы бергәләп иҗат итә торган коллектив жанр. Мансур Әхмәт улы Шиһапов үз табигатенә туры килә торган сәнгатьнең нәкъ шул төрен сайлады да. Һәм дөрес эшләде. Сәхнә, җыр, моң, тамашачы алкышы — аның бәгырендә. Шуңа да ул халык арасында бик популяр булган дистәләгән бик матур җырларның авторы була алды. Ул җырлар турында заманында М.Мәһдиев, Г.Ахунов, Р.Батулла кебек мәртәбәле кешеләр язып чыкты инде. Кабатлап тормыйм, үзен татар дип санаган һәр кеше аларны белә булыр.

Мансур Шиһаповның туган якка мөнәсәбәте, авылдашларына, якташларына мәрхәмәтле карашы сокландыра мине. Игелекле бала әти-әнисен кадерләгән кебек, чын кеше туган җирен изге санап, аны зурларга, олыларга тиеш. Кайтырга вакытын да таба Мансур якташ кирәк чакта сүз беләнме, эш беләнме ярдәм итү җаен да таба. Әле быел яз башында гына талантлы балаларның сәләтен үстерү ниятеннән, район күләмендә үз җырларының фестивален уздырып, бер күркәм эш башкарды ул. Санап китсәң, андый гамәлләре байтак аның.

М. Шиһапов бүгенге көндә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы директоры. Зал дип кенә әйтеп булмый аны, бу бина Россия күләмендә мәшһүр сәнгать сарае. Ул анда инде залның яңартылып ачылган көненнән бирле эшли. Килгән чит ил кешеләренә, ил башлыкларына горурланып күрсәтә торган бинада эшләүнең үз кыенлыклары, хикмәтләре бар. Дөньякүләм атаклы җырчылар, музыкантлар, ансамбльләр чыгыш ясый анда. Шунсы куандыра: татар музыкасы, халык җырлары да еш яңгырый бу залда. Үзебезнең татар әдәбият-сәнгать вәкилләренең авторлык кичәләре, концертлары еш була. Якташларын җыеп, зур сәнгать бәйрәмнәре дә ясый... Боларның күбесе Мансур Шиһаповның тырышлыгына, максатчан хезмәтенә бәйле. Кайчак уйлап куясың, әгәр бу урында бүтән берәр кеше, космополитик рухлы башка берәр иптәш утырса?..

Безнең Балык Бистәсе дип йөртелгән төбәк, шөкер, талантларга бай. Дистәләгән язучы-шагыйрь дисеңме, артист-җырчы дисеңме... Сүз уңаенда әйтеп узыйк: аның бертуган абыйсы Рәшит тә (Рәшит Шиһап) талантлы шагыйрь, берничә китап авторы иде. Заманында безнең яктан чыккан популяр композитор Фәтхерахман Әхмәдиев бар иде. Мансур Шиһапов дигәндә, еш кына әнә шул композиторның исеме искә төшә. Белүемчә, алар яхшы ук таныш булганнар үз вакытында. Ф.Әхмәдиев, туган ягыбызны зурлап, бик матур җырлар калдырды. Дөрес, М.Шиһапов көй чыгаручы түгел, ул сүз белән җыр чыгаручы, менә дигән җыр текстлары язучы. Үткәннәрдән яхшы үрнәкләр бар безгә. Якташыма теләгем шул: яңа иҗат уңышлары юлдаш булсын! Туган халкыбызны, туган ягыбызны зурлауда бергә булыйк, исән-сау булыйк!

*Равил Фәйзуллин*
Татарстанның халык шагыйре

# Мин әнкәйнең бер бөртеге идем

Җырлар

# *Мин әнкәйнең бер бөртеге идем*

*Илфат Дәүләтшин* көе

**Andantino**






Бер бөртеге идем әнкәемнең,
Бөдрәләнгән ап-ак чәченең.
Бер бөртеге идем сагынганда
Таммый калган кайнар яшенең.

Кушымта:
Мин — әнкәйнең
бер бөртеге идем,
Алсулыгы бер як битенең.
Кадерлесе идем, күз алмасы,
Бердәнбере идем җиденең.

Бәхет миңе ингән маңгаеның
Берсе идем тирән сырының.
Бер сипкеле идем нурлы йөзенең,
Моңы идем сихри җырының.

Кушымта.

Әнкәемнең зур өмете идем,
Күңел күрке, шатлык, иманы.
Җиргә биргән, сулыш өргән өчен,
Фәрештәм дип саныйм мин аны.

Кушымта.

## *Туй кулмәге*

*Мәсгут Имашев* көе

**Tempo di valse**







рын тың - ла - дык.
Яз - лар бә - хет бү - ләк ит - те без -
гә, туй күл - мә - ген ал -
дык нәкъ шул көз - дә, тик
ки - яр - гә на - сыйп бул - ма - ды.
Яз - лар бә - хет бү - ләк ит -
те без - гә, туй
күл - мә - ген ал - дык нәкъ шул көз - дә,
тик ки - яр - гә на - сыйп




Килү белән язлар, һәр кич назлап,
Пар сандугач җырын тыңладык.
Язлар бәхет бүләк итте безгә,
Туй күлмәген алдык нәкъ шул көздә,
Тик кияргә насыйп булмады.

Мин еш киләм чишмә аккан җиргә —
Яшьлек эзем, татлы хыялга.
Чишмә ага чакрымнарын иңләп,
Минем хисләр без танышкан җирдә;
Ник килмисең, иркәм, шул ярга?

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
Кабатланмас булса ялгышлар.
Башкаларны йөрәк кабул итми,
Күз алдымнан буй-сыннарың китми;
Күңелемдә әрнү, сагышлар.

Чишмә җыры бик ямансу була,
Бигрәк моңсу була көзләрен.
Януларым, көюләрем белән
Сагынганда туй күлмәген киям,
Һәм юлларда була күзләрем.

# Яшьлегем эзләре

*Рим Хәсәнов* көе






Җил белән серләшкән каеннар
Яңарта яшьлегем хисләрен.
Шомыртлар ак шәлен ябынса,
Сагынам авылым кичләрен.
Сагынам, сагынам, өзелеп,
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

Назлы җил, салмак җил китерә
Чәчәкле болынның исләрен.
Мин тоям, тоям мин җилләрнең
Яшьлектән наз булып искәнен.
Сагынам, сагынам өзелеп,
Шул назлы яшьлегем эзләрен.

Бирелеп хыялга, уйларга,
Тыңлыйм мин агышын чишмәнең.
Чишмәләр җырлыйлар моң итеп,
Җырлыйлар яшьлегем хисләрен.
Мәңгегә сакласын авылым
Давыллы яшьлегем эзләрен.

## *Мәңгелек ут*

*Рәшит Гобәйдуллин* көе

**Andante**






Җыйнап сугыш серен,
Мәңгелек ут сөйли,
Сүзсез сөйли тарих ялкыны:
Исән калды микән,
Дөрләп янды микән
Ап-ак шәлен япкан яу кызы,
Алтын Йолдыз таккан таң кызы?

Чәчләрдәге бәсләр,
Күзләрдәге яшьләр...
Югалганнар, өмет өзмим мин.
Утлы юллар узган
Таң нурыдай кызлар,
Яз җилләре иссә, түзмим мин,
Чәчәкләрдән сезне эзлим мин.

Мәңгелек ут дөрли.
Кояш җиргә сөйли.
Шаһит дөнья яман ярсулы.
Бәхет өмет иткән,
Туйлар вәгъдә иткән,
Хыялдагы туйны күрми киткән —
Мәңгелек ут — җаннар ярсуы.

# Әйләнеп кайтыгыз

*Рим Хәсәнов* көе

**Animato**



Агыла тын гына,
Җыр булып моң гына,
Кемнәрдер кайларга китәләр…
Сагыштан янганнар,
Яшьләре тамганнар
Юлларда өзелеп көтәләр.

К у ш ы м т а :
Күңелдә йөргән яр,
Төшләргә кергән яр,
Кайсыбыз сагынмый, әйтегез?!
Яшьлекнең таңында
Вәгъдәләр хакына
Тизрәк әйләнеп кайтыгыз.

Парлылар бергәләп,
Йөрәкне телгәләп,
Күңелне әрнетеп үтәләр.
Олы юл чатында
Күрешү көннәрен
Ялгызлар зарыгып көтәләр.

К у ш ы м т а .

Туган җир тарта ул,
Исәннәр кайта ул,
Кавышу көннәрен беләләр.
Хәбәрсез югалган
Дусларын юллардан
Тол кызлар һаман да көтәләр.

К у ш ы м т а .

## *Безнең яшьлек нидән башланды?*

*Сара Садыйкова* көе

**Moderato**






Безнең яшьлек нидән башланды?
Ирләр утка кергән дәвердән.
Ятимнәргә назлы җылы биргән
Әнкәемнең мамык шәленнән.
Бәлкем, башлангандыр әткәй булып
Колхоз кырын сөргән таңнардан.
Унҗидедә чишмә буйларында
Сөю бүләк иткән язлардан.

Бәлкем, башлангандыр чик буенда
Илгә биргән антны үтәүдән.
Безнең яшьлек, утны-суны кичеп,
Татарстан данын күтәргән.
Безнең яшьлек әле үтелмәгән,
Үтеләчәк авыр юлга тиң.
Безнең яшьлек әле язылмаган,
Җырланачак моңлы җырга тиң.

# *Җиңү көне җиңел бирелмәде*

*Сара Садыйкова* көе

**Sostenuto**



Яшь каеннар яфрак ярган таңда
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә салып,
Утка төренеп яуга керделәр.

К у ш ы м т а :
Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк җылый Муса, Алиш өчен,
Егермеләп миллион җан өчен!

Тарих шаһит — үлмәс Карбышевлар
Әверелә бозга — ил сатмый.
Татар улы — батыр Газинурлар
Күкрәкләре белән ут каплый.

К у ш ы м т а .

Яңгыра, җыр, тыйнак илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып,
Батырлыгы булып халкымның!

К у ш ы м т а .

## Бирсәнә түзем

*Илгиз Закиров* көе

**Andante**






Татлы төннәрдә
Киләм күлләргә.
Ялгыз сандугач,
үзәкне өзеп,
Сайрый таңнарда,
Кунып талларга.
Сагынганнарга
бирсәнә түзем.

Айның нурлары
Айкый юлларны.
Назлы кар ява,
капланган эзең.
Яну да көю,
Шулдыр чын сөю.
Сөю хакына
бирсәнә түзем.

Иске ай бата,
Яңасы калка;
Балкып китәр күк
сагышлы йөзең.
Тагын ничә җәй,
Тагын ничә көз,
Язы, кышы бар,
бирсәнә түзем.

Күкләргә карыйм,
Йолдызлар саныйм.
Ул балкышлары
нәкъ синең күзең.
Таралыр сагыш,
Таралмас өмет.
Барыбер көтәм,
бирсәнә түзем.

# Туган җирсез яшәү юк сыман

*Сафьян Ибраһимов* көе



Ямьле авыл таңын,
Каеннарның шавын,
Май кояшы нурын юксынам.
Мин кырларга гашыйк,
Авылым сагынам шашып,
Туган җирсез яшәү юк сыман.

Тугайларның нурын,
Тургайларның моңын
Сагына йөрәк, гомер тиз ага.
Шәһәр бәхет нуры,
Ә мин авыл улы,
Җирне сагынып, күңел сызлана.

Көрәшләрдә күпме
Данлы еллар үтте
Буразнада үскән батырлар.
Алар җырын җырлап,
Туган җирне зурлап
Шаулашалар моңсу каеннар.

## *Минем өчен син генә*

*Фәтхерахман Әхмәдиев* көе

**Adagio**












Җир йөзендә үскән чәчәкләрнең
Иң матуры була бер генә.
Шул чәчәктән кала гүзәллекнең
Икенчесе бары син генә…

Шул чәчәктән кала гүзәллекнең
Икенчесе бары син генә.

Күк йөзендә янган йолдызларның
Иң нурлысы була бер генә.
Таң йолдызы кебек, юлларыма
Яшәү яме сипкән син генә…

Күңелеңнең саф, пакьлеген өстәп,
Яшәү тәме биргән син генә.

## *Көт мине*

*Фәрит Хатыйпов* көе

**Andantino**









Язгы кичләр юмарт була
Сагышка, моңга.
Сагыш-моң йөрәккә үтеп
Әйләнеп җырга,
Язгы хисләр күңелеңне
Дәшсәләр юлга...
Көтәрмен дигән антың бар,
Ялгышма, уйла!

Яр буендагы каеннар
Яфраклар ярса,
Ал чәчәк атса...
Тәрәз каршында бер шаян
Тальянын тартса,
Яман уйлар җанда уйнар,
Вәгъдәңне сакла.

Юллары ямансу, диләр,
Ялгыз чишмәнең,
Зәңгәр томаннар капласа
Яшьлек эзләрен.
Кинәт кәккүк тавыш бирсә,
Ак бәхет теләп.
Көт мине, яшәү бүләк ит
Көтүең белән.

Вакытлыча болыт каплау
Язмышың күген —
Бу бит әле мәңгелеккә
Аерылу түгел.
Сагынулардан чәчләреңә
Бәсләр төшсәләр,
Көт мине, мәңге ышанмам,
Көтми, дисәләр.

## *Язгы җыр*

*Рим Хәсәнов* көе






Җылы нурлар җир өстеннән бөркелә,
Йөрәкләрне җилкендереп, яз килә.

Кушымта:

Язны котлап җырлыйк, дуслар,
Безгә кушылып сайрый кошлар.
Зәңгәр күктә сөенешеп
Янсын серле йолдызлар.
Ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла-ла (2 кат),
Зәңгәр күктә сөенешеп
Янсын серле йолдызлар.

Кояшка таба үрелә саф гөлләр,
Хезмәт җырына күмелә күңелләр.

Кушымта.

Бәхет балкый һәр кешенең йөзендә,
Яз сагынып килә безне үзе дә!..
Кушымта.

Язны котлап җырлыйк, дуслар,
Безгә кушылып сайрар кошлар!..
Кушымта.

## Тиңсез ярату

*Фәрит Бариев* көе



Юлларыңда кыенлыклар туса,
Күңелең минем белән булганда,
Әрнүләрем эри томан сыман,
Яратуың тиңсез булганда.

Алларыңда таулар күтәрелсә,
Үтә алмам диеп уйлама.
Алар сиңа яшәү урыны булыр,
Яратуың тиңсез булганда.

Көрәш кырларында ялкын сыман,
Өермәләр сине буганда.
Ике йөрәк барын җиңеп чыга,
Яратуың тиңсез булганда.

## Унҗиде яшем

*Рәис Нәгыймов* көе

**Allegretto**






Язгы ямь белән йөрәк серләшә,
Каеннар шавы — киләчәк дәшә.
Кулда — таныклык, чәчәк бәйләме,
Бу безнең язмыш, яшьлек бәйрәме.

Кушымта:

Нәрсәгә тиңлим унҗиде яшем?
Ул — кояш нуры, ул — көчле яшен.
Ул — саф таңнары без барыр юлның,
Туачак моңы без җырлар җырның.

Күктән сокланып тулган ай карый,
Йомшак май җиле бөдрәләр тарый.
Бөдрәләр бизи сылу йөзләрне,
Зөһрә йолдыздай нурлы күзләрне.

Кушымта.

Әйләнә яшьлек ургылып хискә,
Бу онытылмас бәхетле кичләр.
Күңелдә — шатлык, йөрәктә — көю,
Беренче хатлар, беренче сөю.

Кушымта.

# Әткәм сулышы

*Сара Садыйкова* көе




Язгы таңда чишмә тавышыннан
Әткәм сулышы күк моң килә.
Сабый балачагым, данлы җиңү көне
Искә төшсә тагын,
Әткәй, бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

Ил шатлыгы иде теләкләрең,
Ил бурычы иде җилкәңдә.
Илем дәшә алга…
Кыенлыклар туса,
Җиңел булсын җанга,
Әткәй, бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

Аяз күктә янган йолдызларның
Тыныч җиргә нуры сирпелә.
Шат илемдәй балкып,
Олы юлга чыксам,
Өстәр өчен ялкын,
Әткәй, бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

## *Май аенда кар ява*

*Илһам Байтирәк* көе




Em7(♭5) Gm/A A7 Dm7
чай - ка - ла. Йөз ел - га
Gm7 B/C
бер ге - нә тап - кыр, бер ге -
C7 Fmaj7 B♭maj7 B♭
нә тап - кыр май а - ен -
Em7(♭5) A7 Dm7
да кар я - ва.
A7 Dm7 Gm7
Ни - гә һәр көн сыз - лый и - кән,
C7 Fmaj7
сө - ю ки - тер - гән,
A7 Dm7
я - ра.

Шомыртлар ап-ак чәчәктә,
Ай күлгә төшкән, яна.
Карлы суда ялгыз басма
Айкала да чайкала.

К у ш ы м т а :
Йөз елга бер генә тапкыр,
Бер генә тапкыр
Май аенда кар ява.
Нигә һәр көн сызлый икән
Сөю китергән яра?

Сандугачның моңын эзлим,
Тынлыкта миңа пар ул.
Икәү йөрсәң — бәхет төсе,
Ялгызга — гади кар ул.

К у ш ы м т а .

Айкалган-чайкалган дөнья,
Үзәннәр толымы мин?
Басмада ялгыз тирбәлгән
Мәхәббәт колымы мин?

К у ш ы м т а .

## *Айнымас Самат*

*Марс Макаров* көе

**Animato**






Урам буйлап алпан-тилпән
Атлый айнымас Самат.
Каршы килсәң, сугып ега,
Кайберен кала янап.

Эх, уйламыйсың, Самат,
Ни була эчсәң чамалап,
Чыккан сумнарың санап?

Өйгә керә тәрәзәдән…
Кем булсын? Борча Самат.
Йодрык йомып, хатын куа,
Куйганнармыни канат?

Акыл кererме, Самат!
Унбиш тәүлеккә япсалар,
Алыр идең лә сабак.

Җир казыды, утын ярды,
Чыгар көннәрен санап.
Дүрт аяклап кайтып кереп,
Буран уйнатты кабат.

Үҗәт икәнсең, Самат!
Муенында баш түгелдер,
Утыртканнардыр кабак.

Күрдем, дәваланып йөри,
Өстендә чуар халат.
«Турадылар ашказанын», —
Дип елап йөри Самат!

Һай, әйбәт булган, Самат!
Эчмәссең тамчысын кабат,
Йөрмәссең кеше янап.

# *Бүләк ит син*

*Сафьян Ибраһимов* көе

**Andante**



Бүләк итмә ал чәчәкле алан,
Саргаялар алар күзләрен.
Буш аланда ялгыз каен сыман
Синсез калсам мин соң нишләрмен?

Кушымта:
Бүләк ит син миңа җан җылысы,
Саф-пакь сөю, кайнар хисләрең.
Шул хисләрсез калу — илсез калу,
Ә мин илсез, синсез нишләрмен?

Күктән йолдыз чүпләп бүләк итмә,
Ялтырый да оча кичләрен.
Таң атканда янар соңгы йолдыз,
Син дә сүнсәң, мин соң нишләрмен?

Кушымта.

Бүләк итмә ялгыз сандугачны,
Сихри күлләр тынып калмасын.
Иректә ул үз тиңдәшен тапсын,
Безгә бәхет теләп сайрасын.

Кушымта.

## *Синең турында*

*Фәрит Хатыйпов* көе

**Moderato**






Иртәнге чык чишмәләргә
Моң булып тамса,
Кыр чәчәкләре алланып
Бөресен ачса,
Зәңгәр күктән жыр агылса
Кояш нурында,
Бар гүзәллек сөйли кебек
Синең турында.

Пар аккошлар туй ясарга
Кайтсалар илгә,
Яшел яфрак ярган каен
Шауласа җилдә,
Бәхетле яшьлек гөрләсә
Идел буенда,
Нәкъ шул вакыт җырлар туа
Синең турында.

Сихри күлнең талларына
Сандугач кунып
Сайраганда, яшьләр түкмә,
Күңелең тулып,
Бәхет алып килгән көмеш
Гомер юлымда,
Онытырга мөмкин түгел
Синең турында.

# Аккош белән серләшү

*Зөфәр Хәйретдинов* көе

**Moderato**



Язгы таңда күңелемдә калды
Ялгыз очкан аккош тавышы.
Аккош мине яшьлегемә илтте,
Уртак, диде, йөрәк сагышы...

Кушымта:
Аккош өмет өзми,
Яшьлек ярын эзли.
Олы хисләр уртак түгелме?
Син дә ялгыз аккош,
Мин дә ялгыз аккош,
Кем юатыр безнең күңелне.

Белми идем әле аккошларның
Мәхәббәттән дөрләп янганын.
Керсез дустын, саф бәхетен эзләп,
Керфегеннән яшьләр тамганын.

Кушымта.

Синең җанда аккош каны бар, дип
Җавап бирде ялгыз аккошым.
Сагышларың түгел, ялгышларың
Теләп алган ачы язмышың.

Кушымта:
Аккош өмет өзми,
Яшьлек ярын эзли.
Олы хисләр уртак түгелме?
Ялгышыммы, аккош,
Язмышыммы, аккош?
Юат җанны, юат күңелне.

## Сагынам Балык Бистәсен

*Илгиз Закиров* көе






Ялгыз аккош парын эзли,
Язлар килгән, нишләсен.
Төшкән күлгә — гүзәл җиргә,
Сайлап Балык Бистәсен.
Таңнар аткан, ярын тапкан,
Серләшә, күз тимәсен.

Таң сандугачы тирәктә,
Мактап сайрый чишмәсен.
Миң дә бер рәхәт, гүзәл кош,
Күңел кылларын чиртәсең,
Яшьлек үткән серле якны —
Зурлап Балык Бистәсен.

Читкә киткән изге җаннар,
Сагынып Кама иртәсен,
Аккошлар булып кайталар
Чибәрләр, әй, күз тимәсен.
Туй ясарга бу якларга,
Сайлап Балык Бистәсен.

## *Иркәләнер көннәр алда әле*

*Сафьян Ибраһимов* көе

**Andantino**



Каен тәлгәшеннән моңнар тамып,
Сагыш басса, яшьләр түкмә әле!
Уртаклашыр серләр, бүленгән хис,
Аңлашасы сүзләр күпме әле.

Дуамал җил көтмә диеп шаулар,
Белмәс кичне, белмәс иртәне.
Ярын җуйган ялгыз аккош сыман,
Ярдан ташланырга иртә әле.

Йөрәгемнең балкыр нурларында
Бүләк итәр җылы калды әле.
Миләш кызын үпкән тирәк сыман
Иркәләнер көннәр алда әле.

## *Халкым җыелган җирдә*

*Илдус Якупов* көе






*Зиннур Мөхәммәтдинов* көе

**Sostenuto**






Сөембикә манарасы
Ае нур сипкән көндә
Бөтен дөнья татарлары
Азан әйттеләр бергә.

Кушымта:

Кунак булыйк, милли бәйрәм —
Сабантуйда, татарлар!
Уйныйк, көлик, җырлыйк, биик,
Дошманнар сөйләп йөрсеннәр:
«Татар барда — хәтәр бар!»

«Татар барда — хәтәр бар» дип
Шау киләләр һәр илдә.
Сафлык, пакьлек, шатлык, хаклык
Халкым җыелган җирдә.

Кушымта.

Аяз күгемдә мәчетләр
Алтын нур сипкән кичтә
Данлы Казан, моңлы азан
Мәңге сакланыр истә.

Кушымта.

## *Гүзәл затка бир түзем*

*Илһам Байтирәк* көе






Бәйрәмнәр бетте... Саклады
Сигезенче март үзен.
Инде башкача әйтәм мин
Ирләрчә котлау сүзен:
Күңелләр җәүһәре булган
Асыл затка бир түзем,
Асыл затка бир түзем.

Үзгәрде заман... Саклады
Изге җан нурлы йөзен.
Яшәү көче, сулыш биргән,
Әйтеп иманлы сүзен...

Мәхәббәтнең таҗы булган
Әнкәйләргә бир түзем,
Әнкәйләргә бир түзем.

Сулдылар гөлләр һәм ирләр,
Шиңде чәчәкләр көзен.
Таллыкта моңнар тараткан
Сандугач тынды кичен.
Мәңге сүнмәс, төсен җуймас
Гүзәл затка бир түзем,
Гүзәл затка бир түзем.

## *Сагыныр өчен*

*Зөфәр Хәйретдинов* көе

**Allegretto**






Челтерәп аккан чишмәле,
Айлы, кояшлы ягым.
Кем генә сагынмый икән
Әкияттәй бала чагын.

К у ш ы м т а :
Авылымнан киттем, авылны
Шашып сагыныр өчен,
Язгы ташкын булып кайтып,
Таңда, каршына тезләнеп,
Аңа табыныр өчен.

Чалгы яный чишмәлектә,
Кем булсын, әткәй җаным.
Әнкәй судан кайтып килә,
Талир тәңкәләр тагып.

К у ш ы м т а .

Күкләреннән йолдыз чүпләп,
Күзләрне күзгә багып...
Ничек сагынмасын күңел
Сөекле авыл таңын.

К у ш ы м т а .

## *Туй балдагы*

*Сафьян Ибраһимов* көе

**Moderato**






Яшь парлар балдак алыша,
Моң агыла тын гына.
Кыңгыраулар бәхет җырлый,
Атлар алга ыргыла.

Кушымта:

Әх, шәм шикелле ун бармак,
Пар бармакта пар балдак.
Туй балдагы — вәгъдә бирү —
Ата-бабадан калган.

Юртаклар юлны яралар,
Дага эзе ак карда.
Күпме хис килен йөзендә,
Күпме сөю бу җанда.

Кушымта.

Мәңгелек ут дөрләп яна,
Гашыйклар чәчәк сала.
Сафлык анты — туй балдагы —
Тулган ай кебек яна.

Кушымта.

Соңгы кат кияү егете,
Кочаклап яшьлек дустын,
Тальян чыңы җырлап, елап
Озатты авыл кызын.

Кушымта.

## *Кыр казларын бергә каршылыйк*

*Марсель Иванов* көе

**Tempo di valse**






Кыр казларын бергә каршылыйк
Күл өстендә яткан басмада.
Казлар белән язлар ташып килә,
Беренче хис, сөю башлана.

К у ш ы м т а :

Кыр казлары булып, күлгә төшсен
Күктән, бик биектән язмышым.
Тагын ничә еллар каршылармын
Бу басмада язны ялгызым?

Казлар туй ясыйлар күл читендә,
Уйга талган сихри таллыкта.
Туй җырында күңелләрдә әрнү,
Туй моңына йөрәк талпына.

К у ш ы м т а .

Казлар белән, ап-ак болыт булып,
Туган якка кайт син, яшьлегем!
Ага шаулап гөрләвекләр түгел,
Сагынулардан тамган яшь минем.

К у ш ы м т а .

# *Бәхилләшмим – саубуллашам*

*Рәис Нәгыймов* көе

**Andante**




Мин дөньяга килү беләν,
Анам кат-кат юган чишмә…
Саубуллашырга дип килдем
Язгы кичтә, чумып хискә.
Саубуллашам ярлар беләν,
Ярда үскән таллар беләν,
Тәпи баскан, нурга күмеп,
Юл яктырткан
таңнар беләν.

Беренче хис хатирәсе —
Юл чатында ялгыз каен.
Каен кебек тәлгәшләрем
Булды башым игән аем.
Ялгыз яндым көннәр-төннәр,
Тик сынмадым,
сыгылмадым.
Бәхилләшмим —
саубуллашам,
Бала чагым, туган ягым.

Яшәү көче биргән әнкәм,
Җан җылысын өрә-өрә,
Ак күлмәктән, ак чәчәктән
Пакь җан булып төшкә керә.
Кызыл, зәңгәр, ак, шәмәхә,
Чәчәкләрдән чәчәк туган,
Бәхилләшмим — саубуллашып
Китеп барам кайтыр юлдан.

Пар ат җигеп, язмыш юлын
Парлап үткән тормыш дустым,
Яраланган яшьлегемә
Канат биргән очар кошым,
Яшь-җилкенчәк тә көнләшсен,
Сөю хисен чәчик әле,
Тагын йөз ел, бәхилләшми,
Җир җимертеп яшик әле.

## *Мин яшәргә тиеш шул хакка*

*Рамил Курамшин* көе






Яз кояшы көлеп карар вакыт,
Биргән вәгъдәләрне син сакла.
Кайгы-шатлыкларны бүлгән кешем,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.
Язгы таңда басып ялгыз талга,
Сайрап куйса бер кош шул чакта.
Сагышлардан яшь бөртегең тамса,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.

Сирень агачлары чәчәк атар,
Яшел нурлар төшәр яфракка.
Янар яшьлек бүләк иткән кешем,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.
Барыр юлым — иксез-чиксез әле…
Язмыш илтеп куяр кай якка?
Кайтыр юлда бәхет гөле булсаң,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.

# Йөрәгем бит һаман яшь әле

*Зөфәр Хәйретдинов* көе

**Andantino**



Кабан күлендәге сердәш аккошларның
Берсе кайткан ялгыз, пары юк инде.
Ярларына басып сиңа җырлар идем,
Кушылмассың, беләм, соң инде.

Кушымта:
Соң икәнен беләм, беләм, соң булсын,
Соң булса да, әйдә, әйдә, уң булсын.
Урамнарда күрсәң, күрсәң, дәш әле,
Йөрәгем бит һаман яшь әле.

Бөдрә чәчен артка җилләр тарап салган
Каен кызы, сөйлә сереңне.
Җан җылыңны биреп кабат яратырга
Аңлыйм, җаный, аңлыйм, соң инде.

Кушымта.

Кабан күле өстен куе томан сарган,
Ярларында хәзер синсез моң инде.
Башым иеп әгәр синең янга килсәм,
Кичермәссең, беләм, соң инде.

Кушымта.

## *Өлешемә тигән, әй көмешем!*

*Азат Хөсәенов* көе






Таллыктагы ялгыз сандугачның
Язгы җырын тыңлап юанам.
Әй өлешем, чишмә ярына кил,
Көмеш сулар булып мин агам.

Кушымта:
Көянтәне асып, басмаларга басып,
Сине җырга кушып су алам!
Таң атканда, йолдызларга кара,
Җан жылысы булып мин янам.

Аяз кичтә күктән күзең алма,
Балкып кына калмам, дөрләрмен.
Башка йолдызлардан нурлар алсаң,
Дөрләп кенә калмам, көнләрмен.

Кушымта.

Тиңдәшемне эзләп, ничә көзләр
Ай кызына карап уйландым.
Өлешемә тигән, әй көмешем,
Алтыным бул яшьлек дөньямның.

Кушымта.

# *Сагыну*

*Рамил Курамшин* көе

**Tempo di valse**






Кошлар китсә, илдән парлап китсен,
Ялгыз башы язын кайтмасын.
Ялгыз кошым, кара күзләреңне,
Сагыш баскан ап-ак йөзләреңне
Минем өчен кояш назласын.

Көткәннәргә бик ямансу була
Шомырт чәчәк аткан иртәләр.
Шул иртәдә бәсле чәчләреңне,
Керфегеңдә калган яшьләреңне
Минем өчен җилләр иркәләр.

Сагынганда, җәй айлары озын.
Хыялый ай алтын нур сибә.
Адашудан, ялгышудан саклан,
Ялгыш уйлар башка гел килә,
Беренче яр була бер генә.

## *Тол ханым*

*Зөфәр Хәйретдинов* көе

**Andante**






Кабан күлендә дулкыннар
Серен сорый моңсу ярның.
Суга карап уйга чумган
Әле бик яшь бер тол ханым.

К у ш ы м т а :
Ялгызлыкта ялгыз янып
Кимсенмә син, әй тол ханым.
Парың тапсаң юаныр ла
Рәнҗеп арган изге җаның.

Салмак җил иркәли аны,
Яңгыр юа толымнарын.
Ник соң яшьли ул тол калган,
Ни гаебе бар соң аның?

Кушымта.

Казан таңда хискә чумган,
Сандугачы сайрый талның.
Ак мендәрдә ялгыз ята
Әле бик яшь бер тол ханым.

Кушымта.

## *Васыять*

*Риф Гатауллин* көе

**Moderato**






Чишмәлектә язын бик тә моңсу,
Тирәлектә сайрый таң кошы.
Сагынып еларсыңмы су алганда,
Чагылып китсә гәүдәм балкышы?

К у ш ы м т а :
Васьятемне җырлап йөрерсеңме,
Җыр калдырсам синең турында?

Ташкын булып аккан хисләреңә
Сагыш алып килсә кар-сулар.
Иренем тәмен искә алырсыңмы,
Җаның сусаганда ярсудан?

К у ш ы м т а .

Төшләреңә туй көннәре керсә,
Йөрәгеңдә калсын сер булып.
Язгы тауда сулар сибәрсеңме,
Тишелеп чыкса җаным гөл булып?

К у ш ы м т а .

## *Күзләремнән килеп кара*

*Илһам Байтирәк* көе

**Andante**




H7 Em7 F♯m7 H7
ләп үт - кән сук - мак. Гөр -
Em7 F♯7
лә - век - ләр жы - рын тың - лап,
Am D7
йө - рим яр - ла - ры буй - лап.
Gmaj7 G7 Cmaj9
Күз - лә - рем - нән ки - леп
H7 Em7
ка - ра: я - ман - су -
Am7 D7 Gmaj7
- лык, әй мон - су - лык.
G7 Cmaj9 H7
Күл өс - тен - дә мин ак - чар -
Em7 1. Am7
лак, ял - гыз о - чам
D11 Gmaj7
нәү - миз бу - лып.




Истән чыкмый Болак буе,
Икәүләп үткән сукмак.
Гөрләвекләр җырын тыңлап,
Йөрим ярлары буйлап.

К у ш ы м т а :

Күзләремнән килеп кара:
Ямансулык, әй моңсулык.
Күл өстендә мин акчарлак,
Ялгыз очам нәүмиз булып.

Сулар ташый, карлар ашый,
Боз эри, сөю түгел.
Көткән кадәр көтсәң әгәр,
«Кайтыр» дип алдый күңел.

К у ш ы м т а .

Йөрәгемдә калган юлчым,
Чуалттың йомгак очын.
Юатырсың, елатырсың —
Күрешик, зинһар өчен.

К у ш ы м т а .

# *Клара*

*Зөфәр Хәйретдинов* көе



Гөлләрнең, ай, гүзәл төрләре күп,
Сиңа тиңдәше бар — ул яран.
Йөрәк яраларын кат-кат бәйләп,
Яшәү дәрте биргән Кларам.

Кушымта:
Рәхмәт инде сөйгән-көйгән өчен,
Кара кашлы, нурлы кара күз.
Күпне күрдең инде, түздең инде,
Калган елларда да нык бул, түз.

Язгы кичтә яңа чыккан аем,
Күккә карап йолдыз юл яра.
Шул юллардан айкап-чайкамыйча,
Мине әйдәп килгән Клара.

Кушымта.

Читкә китсәм җанга кемдер җитми,
Җитми бердәнберем Кларам.
Йөзләгән җыр язып, кичер мине,
Сиңа багышланган җыр калган.

Кушымта.

## *Мишәр кызы*

*Зөфәр Хәйретдинов* көе






Ҫихерле карашың белән
Йөрәгемә ут салдың.
Ҫерле карап, бер елмаеп,
Йөрәктә урын алдың.

К у ш ы м т а :
Мишәр кызы чая телле,
Үзе шундый сөйкемле.
Эх, егетләр, сак булыгыз!
Исән калу икеле...

Қүз карашы туры карый,
Йөрәкләрне үтәли...
Сөю уты кабындырып,
Бәгырьләрне телгәли.

К у ш ы м т а .

Нечкә билле, очкын күзле,
Иреннең иң татлысы...
Кызларның да иң уңганы,
Татарның иң затлысы.

К у ш ы м т а .

Сөйсә дә, ул сөям димәс,
Сөймәсә якын килмәс...
Яндырыр, көлгә калдырыр,
Башкага сине бирмәс.

К у ш ы м т а .

# *Кайтыр идем*

*Мәсгут Имашев* көе




Кайтыр идем туган авылыма,
Күрер идем моңсу ярларын.
Аланында сузылып,
сузылып,
кырын ятып,
Тыңлар идем камыш шауларын.

Чылтырап аккан чишмәләрнең җырын
Тыңлар идем басып ташына.
Кайтыр идем, туган авылым, сиңа,
Кайтыр өчен йөрәк ашкына.

Кайтыр идем туган авылыма,
Буйлар идем елга буйларын.
Бик сагындым,
авылым,
туган авылым, сине,
Сиңа кайта һаман уйларым.

# *Синең күзләрең*

*Мәсгут Имашев* көе

**Tempo di valse**






Язгы таң кояшы балкыгач,
Безгә тиң пар чәчәк эзләдем.
Нурланып ачылган бөрене
Мин синең күзләргә тиңләдем.
Шул нурга төренгән
Сихерле чәчәкләр —
Әйтерсең ул синең күзләрең!
Әйтерсең ул синең күзләрең!

Кич җитеп йолдызлар калыккач,
Безгә тиң пар йолдыз эзләдем.
Күктәге һәр йолдыз балкышын
Мин синең күзләргә тиңләдем.
Шул моңга төренгән
Тылсымлы йолдызлар —
Әйтерсең ул синең күзләрең!
Әйтерсең ул синең күзләрең!

## *Марья, Лина, Натуша*

*Зөфәр Хәйретдинов* көе

**Allegretto**






Кашың ай күк билен бөккән,
Ә Ходай пәрештә иткән.
Җапрак бәйрәмнәре җиткәч,
Ни эшләрбез соң без, иркәм?

К у ш ы м т а :

Чибәрләрнең чибәре шул
Марья! Лина! Натуша!
Әти-әни, ерак җиңги
Сезне сөймәскә куша.

Патша тәңкәләре таккан,
Кәлүшләр аягында.
Барлык дуслар көнләшерләр,
Балкып торсаң янымда.

К у ш ы м т а .

Җиде күлмәк, дүрт бал итәк
Приданыйга тулырмы?
Питрауларда гөрләттереп
Туй итәсе булырмы?

К у ш ы м т а .

Күгәрчен сөтләре салып,
Алтын чәркәләр бирсәм,
«Прощай милай, до свидания»
Диеп дәшмәссеңме икән?

К у ш ы м т а :

Чибәрләрнең чибәре шул
Марья, Лина, Натуша.
Әткәй, әнкәй, Иван дәдәй
Сезне алмаска куша.

# *Сулар үргә акмый, диләр*

Илнар Сафин көе

**Moderato**




Сулар үргә акмый, диләр,
Минем яшьлеккә ага.
Беренче сөю китергән
Чишмә юлына таба.

Басмада көянтә, чиләк,
Көтеп калган кыз бала.
Йөрәк түрендә янар хис
Үрдән тауларга ага…

Сулар үргә акмый, диләр,
Күңелдә ага икән.
Сагынып арган күзләре
Сүнә дә яна микән.

Сулар үргә акмый, диләр,
Үрләрдә күлләр бар бит.
Син минем йөзек кашымда
Уелып калган яр бит.

## *Бер авыл баласы мин*

*Әнвәр Шаһиморатов* көе






Шәһәргә килеп адашкан
Бер авыл баласы мин.
Озатып калган әнкәйнең
Йөрәге ярасы мин.

Кушымта:

Ташлап китте дип рәнҗемә,
Сагынуларым үзем белән.
Авыл, кайгы-хәсрәтләрең,
Шатлыкларың минем белән.

Сабан туенда сайраган
Бер былбыл баласы мин.
Казанда акыл туплаган
Чын татар агасы мин.

Кушымта.

Көтәдер бәбкә үләне,
Яланаяк йөргән кар.
Сөйгәнемә кайттым инде,
Туган җиргә вәгъдәм бар.

Кушымта.

Сандугач булып
җырлыйдыр
Бакчада әткәй җаны.
Көтегез, инеш буйлары,
Көт, серле авыл таңы.

Кушымта.

## *КамАЗ төзүчеләр җыры*

*Сара Садыйкова* көе

**Allegro moderato**






Кама суы җырлап ага,
Дулкыны ярга кага.
Ватаныбыз яшь буынга
Бөек бурычлар сала.

Кушымта:
Хыяллар тормышка аша,
Күцелләрдә якты яз.
Күп орденлы комсомолның
Даны син, КамАЗ!

Безнең яшьләр —
тыйнак яшьләр,
Ашкынмый алар данга.
Йөрәкләре кушылып тибә
КамАЗга, ерак БАМга.

Кушымта.

Октябрь нуры балкытты
Яшьлекнең барыр юлын.
Яңа Чаллының таңнары —
Туган ил горурлыгы.

Кушымта.

## *Казанның тарихи вокзалы*

*Шамил Тимербулатов* көе

**Allegretto**






Җидегән йолдыз күк җемелдәп,
Нур сибә чал шәһәр байрагы.
Әй гүзәл шәһәрнең язлары,
Бакчада гашыйклар назлары.
Тукайча дәртле син, нурлы син,
Моңлы син, Казанның вокзалы.

Толларның күз яшен яшерде
Сагышлы Иделнең чал яры.
Җиңүләр маршына кушылып
Җырлады Кремль чаңнары.
Мусаны юксынып елады,
Казанның тарихи вокзалы.

Бәхетле яшьлекне яшьнәтеп
Ямьләнә башкалам таңнары.
Кол Шәриф мәчете милләтнең
Үткәнен, иманын саклавы.
Татарның мең еллык көзгесе —
Казанның тарихи вокзалы.

# Чиксез мәхәббәтем бар

Шигырьләр

## Бик якын син, Яншык киче

Сандугачлар чут-чут итеп сайраганга,
Ак каеннар әкрен-әкрен шаулаганга,
Һавасына таралганга гөлләр исе,
Күңелемә бик-бик якын Яншык киче.
Урамында Ильич уты кабынганда,
Егетләрнең шат җырлары агылганда,
Биләп ала күңелемне шатлык хисе —
Нинди матур һәм гүзәл син,
Яншык киче!!!
Кар, бураның биткә бәреп кыйнаса да,
Шаян җилләр җиңгә кереп уйнаса да,
Гашыйк итә туган якның сихри көче —
Күңелемдә нурлы, моңлы
Авылым киче.

## Көз

Ак каеннар, ямансулап,
Сарыдан киенгәннәр.
Яшь имәннәр, сергә чумып,
Моңаеп иелгәннәр.
Нигә бу көз ләззәтле дә,
Авыр да була икән,
Табигать аша күңелдә
Сагыш тудыра икән?

## Җылы җилләр исә

(Җыр)

Җылы җилләр исә,
Җылы җилләр,
Җылы җилдә битең иркәлә.
Җылы җилләр,
Тапшырыгыз әле
Кайнар хисләремне иркәмә.
Җылы җилләр исә,
Җылы җилләр
Толымыңны кагып уйныйлар.
Алар шулай,
 сине назлый-назлый,
Бәхет таңы сиңа юрыйлар.
Җылы җилләр исә,
Җылы җилләр
Яулыгыңны алып китмәсен.
Җылы җилләр,
Алай шаярмагыз —
Бер кыз бала көтә иркәсен.

## Туган якның якты иртәсе

Туган якның язгы иртәсе.
Күләгәдә кырау җемелди.
Чыркылдаша шаян чыпчыклар,
Күгәрченнәр дәртле җыр көйли.
Ә арырак — бакча артында,
Якты балкып, урман аланы
Кызыктырып дәшә үзенә,
Чакыргандай нәни баланы.
Ирексездән чыгам шунда мин,
Тик дәү инде: ат-ат уйнамыйм;
Бары ак бәс төшкән болынга
Әкрен басып атлыйм бер көйгә.
Алтын балачагын сагынып,
Йөрми микән шулай кайсыбыз?
Артка карыйм, анда бары тик
Бормаланып ята яшел эз.

## *Урай урманы*

Урай, Урай! Синең кочагыңда
Каеннарны беләм, юкәне.
Яшь егетләр, кызлар юлларыңнан,
Чәчәк тотып, һаман үтәме?
Көннәр буе эшчән бал кортлары
Аланыңда чәчәк саныймы?
Көмеш чыклы үлән арасыннан
Ромашкалар көлеп карыймы?
Әйтче, урман, нәни куакларда
Алсуланып пешә чияме?
Сине мактап кошлар җыр сузадыр,
Талгын җилләр назлап сөяме?
Күңел тарта никтер синең якка
Җәйләрең дә тарта, көзең дә,
Урай, Урай! Синең юлларыңда
Суынгандыр инде эзем дә!

## *Гомер хакы*

Гомер юл башына кайтамын да
Кире киләм үткәннәрне барлап:
Әнә балачагым башак җыя,
Бармаклары белән басу тарап.
Балачакның сыек иңнәренә
И салганнар күпме тормыш йөге.
Кемдер яндырган да хыялларын,
Йөрәгендә калган аның көле...
Яшьлек бара Казан урамыннан,
Түфләсенең ертык үкчәләре.
Аңа кырын гына карап уза
Башкаланың ыспай бичәләре.
Ә яшьлекнең такыр кесәләре,
Яшәү, уку өчен, саллар сүтә.
Идел шавы аңа рухлар өсти,
Дулкын җыры аны көчле итә...
Бүгенгедәй уйлап куям: нинди
Кыенлыклар күрми кеше заты.
Ә шулай да әгәр тормыш
Утка-суга салып алмый икән,
Гомер бәясе дә шалкан хакы.

## *Кабер ташына язылачак шигырь*

*( Васыять )*

Зиярәткә килеп керсәң, әй якташым,
Туктап кал да укып кара кабер ташын.
Туган илне сагынып кайтып тән иңдерде,
Гомер буе читтә йөргән авылдашың.

## *Үзенә дә төште*

*( Хатирә )*

Ярлы иде. Кигән чалбары да,
Ышанмассың — кырык ямаулы.
Бары бу тормышка зур мәхәббәт
Яшәткәндер зирәк малайны.
Авыл халкы әйтә торган иде:
«Башлы үзе, әйбәт укучы.
Киләчәктә яңа фикерләрдән
Булыр шәп ачышлар тукучы...»
Берчак ачтан үлмәс өчен, кырда
Кулын сузган бер уч киндергә.
Актив Газиз, моны күреп калып,
Озаттырды ерак Себергә.
Ул чактагы вәхши кануннарга
Кече-зуры һич юк язмышның.
Барысы да бер казанда сүнде,
Ямен күрә алмый тормышның.
Ул кайтмады...
Еллар аша актив Газизне дә
Каһәрләре
Тотып алды бугай малайның.
Бер сәбәпсез кереп асылынды
Мунчасына Билал бабайның...

Ә ул көнне... күкләр каралды,
Яшен күкрәде дә, болыт таралды...

## Кырыс җилләр

(Җыр)

Кырыс җилләр
Агач башларына
Сагышларын элеп калдырган.
Агачы да усал,
Шул сагышны
Минем күңелемә тамдырган
Кырыс җилләр хәзер,
Пыр тузынып,
Көлеп уйный минем тирәмдә.
Ә арыгач,
Рәхәтләнеп сузылып,
Ял итәләр яшел келәмдә.
Кырыс җилләр
Азат сагышлардан…
Мин сагышлы — көтәм берәүне.
Кара чәчкә көмеш яңгыр яугач,
Гашыйк булдым — кара юләрне!

## Сөеләсе изге бер җан калды

Ят кешеләр барда җаным уйный,
Таба гына алмыйм ишләрем.
Сөеләсе изге бер җан калды,
Нишләдең син, язмыш, нишләдең?

## Мәхәббәтем бар

Җил-давыллар кузгалып,
Мине күмсә кар —
Ул карларны эретерлек
Мәхәббәтем бар.
Боз таулары өскә килсә,
Ара булса тар —
Боз тауларын туктатырлык
Мәхәббәтем бар.
Дөнья матурлыгыннан да
Матур минем яр.
Аңа галәм кебек чиксез
Мәхәббәтем бар.

## Сер

*(Этюд)*

Яшь бер усак, оялгандай,
Назланып башын салган.
Бөдрәләнгән чәчләренә
Тәлгәш эленеп калган.
Йолдызлар җиргә сер сөйли,
Алар күзәткән күктән:
Имеш, төнлә усак кызын
Миләш егете үпкән.

## Казанка яры биек...

*(Җыр)*

Казанка яры биек...
Тау итәгенә менеп
Тыңлап торам агышын.
Арча ягыннан искән җил,
Ак дулкыннарга төреп,
Тарата Идел суына
Тукай моңын, сагышын.
    Казанка яры биек...
    Таллар аралап кереп,
    Тыңлыймын дулкын кагышын.
    Мәскәү ягыннан искән җил
    Канлы упкында уйната
    Мулланурның тавышын,
    Вахитовның сагышын.
Казанка яры биек...
Гүзәл җиренә менеп,
Муса баскан уйланып.
Оренбург ягы җилләре,
Ал дулкыннарга төреп,
Тарат илләр буенча
Үлмәс шагыйрь җырларын.
    Казанка яры биек...
    Яшьлек, елмаеп-көлеп,
    Көймәләрдә чайкала.
    Алтын нурларга күмелгән
    Дәртле, моңлы башкала
    Кремль ярларын юган
    Казанкадан башлана.

## Тиңләрмен

*Гөлнарага*

Дөньяның читендә, дисәләр,
Елларны, юлларны иңләрмен.
Елларның иң авыр көннәрен,
Сагышлы газаплы төннәрен
Кавышу язына тиңләрмен.

Салават күперен күзәтеп,
Юлларда теләкләр теләрмен.
Бәхетем төсләрен тараткан
Дуамал җылысын җилләрнең
Мин синең сулышка тиңләрмен.

Рәнҗеше төшкәндер кемнәрнең:
Бер таңда чәчәген өзделәр
Без парлап утырткан гөлләрнең.
Тамыры сулмаган гөл кебек,
Кояшым, мин сиңа үрләрмен.

## Бер шагыйрьгә ияреп

Ачуланма минем хакта,
Җыр чыгармый дип, сөеп.
Җырларсыз да мөмкин икән
Яшәргә янып, көеп.

Яшерен сөю ул — горурлык,
Ул — егетлек, ул — түзем.
Җырлар да йөрәктән чыгалар,
Йөрәгем бит — син үзең.

## Үпкәләмә

Үпкәләмә, сеңлем, бер үпкәнгә,
Шагыйрьләр бит алар хиселләр.
Күрәсеңме уймак иреннәрең
Ничек алсуланып киттеләр.
Үпкәләмә, сеңлем, бер үпкәнгә,
Хис ялкыны булып тамдың син.
Ә ул миңа илһам өстәде дә...
Һәм җырыма кереп калдың син.

## Ялгыз ай тыңдашен эзли

Иске елның соңгы киче,
Ай, никтер тонык янып,
Әйләнә җирнең тирәсен,
Уйланып, сагышланып.

Яңа ел туар кичендә,
Теләкләр тели-тели,
Ай күк әйләнеп күңелем
Сезнең якларда йөри.

Өй түрендәге чыршыда
Мин йолдыз булып янам;
Тәрәздән искән серле җил —
Чәчеңнән сыйпап багам.

Талган күзеңнең нурларын
Җан җылым белән төреп,
Керфегеңдә калган яшьне
Киптердем өреп-өреп.

Яңа язган яңа җырым —
Моң булып агылам да,
Әрнүләрне таратырга
Кайттым дип безнең янга.

Үзеңә авыр булса да
Сораштың минем хәлне.
Яңа елда бәхет теләп,
Сәгать сукты бермәлне.

Парлылар җырлап уздылар,
Тиберәтеп йөрәк түрен.
Ялгыз ай тиңдәшен эзли,
Айкап дөньяның күген.

## Тиңләдем

Кич булып йолдызлар калкуга,
Безгә тиң пар йолдыз эзләдем.
Салават күпере балкышын,
Таллыкта сайраган таң кошын,
Чылтырап агышын чишмәнең
Мин безнең сагынуга тиңләдем.

## *Акчарлаклар үкси һаваларда*

Чәчәкләрдән
Такыя үрдем Сиңа — сөйгәнемә,
Элеп куйдым Кама күкрәгенә.
Һич борчылма, безнең учак яна!
Күчердем мин аны йөрәгемә...
Акчарлаклар үкси һаваларда,
Канатына моңны алалар да.
Күңелемне сызлатыйм ла
сызылдырып,
Яшисең син минем яраларда...
Акчарлаклар үкси һаваларда.

## *Су һаман шаулап ага...*

*(Җыр)*

Авылым күге өстендә
Һәр кич пар йолдыз яна.
Йолдыз нурына төренеп,
Пар каен яфрак яра.
Без икәү килгән чишмәдә
Су һаман шаулап ага,
Су һаман җырлап ага.

Әйтерсең лә бәхет теләп,
Сандугач канат кага.
Мин ялгызым моңланганда,
Сандугач аваз сала.
Беренче яр, ди, йөрәкнең
Мәңге түрендә кала.
Су һаман шаулап ага...

Без парлап килгән чишмәнең
Кемдер каенын кискән.
Күкне дә болыт каплаган,
Йолдыз нур сипми кичтән.
Төшләремә һәр көн кермә —
Кабат яңара хисләр.
Һич тә чыкмыйсың истән.

## Тәңкә карлар

Тәңкә карлар ява,
Тәңкә карлар
Нәфис кенә куна битләргә.
Тәңкә карлар кунган чигәләрең
Кызлар үпсә — белмим нишләргә?!
Тәңкә карлар ява,
Тәңкә карлар
Мәрҗәннәр күк юлга түшәлә.
Яшьләр сөеп әле оныта ала,
Картлар сөйсә, ничек түзала?
Тәңкә карлар ява,
Тәңкә карлар,
Ап-ак канат чыршы ылысы.
Беренче сөю — дөрләп сүнгән утлар,
Ә соңгысы — гомер җылысы.

## Кем кирәк?

*(Җыр)*

Бәхетлеләр бәхет эзләп бергә булса,
Иң беренче теләкләре — бала кирәк.
Бу парларга иң кадерле минут килсә,
Бәләкәйгә яшәү көче — Ана кирәк!

Кулларына китап алган сабыйларның
Йөзләре шат, күзе нурлы, күңел зирәк.
Фәннәр белән танышканда юл ярырга,
Кушу, алу, тапкырларга — Ана кирәк!

Сандугачлар парлап сайрый, күңелдә яз,
Унҗиде яшь, хисләрең саф, яна йөрәк.
Шатлыкларны, әрнүләрне таратырга,
Серләреңне бүлешергә — Ана кирәк!

Җитәр көзләр, олы юлдан җилләр исәр,
Сагышланып яфрак кояр моңсу тирәк.
Илгә бәхет, безгә бәхет өстим дисәң,
Гомерең буе илһам биргән —
Әниең кирәк!

## *Мин сиңа үпкәләмим*

(Җыр)

Ай Зөһрәсе, айкап күкне,
Үз тиңдәшен эзли күпме.
Бирешми вак хисләргә.
Үпкәләмим барсы өчен,
Унсигез тулар-тулмаста,
Сөю алып килгән кешем
Ай калыккан кичләрдә.

Хәтереңдәме — сагыштанмы,
Яшьлектәнме, ялгыштанмы —
Яшь түгеп көткәннәрең?
Синең алда ап-ак саф юл,
Кабатланмас горурлыгым,
Тик ялгышма, бәхетле бул,
Мин сиңа үпкәләмим.

Күңелләре китек, диләр,
Өметләре өзек, диләр,
Ярларны көткәннәрнең.
Олы җанлы, киң күңелле,
Хезмәткә дәрт, яшәү көче
Бүләк иткән син түгелме?
Юк, мәңгегә үпкәләмим!

## *Ярсу һәм айну*

— Аерылам! — диде Гатаулла, —
Ничек инде болай яшәп була?
Бер йөз грамм кәксәм — чәрелдисең,
Артык китсә, куркып дерелдисең.
Төчкерсәм дә —
яфрак төсле калтырыйсың,
Көлсәм — диванадай аптырыйсың.
Ачуланасың да, кичләр үтә ямьсез,
Ашың була тәмсез, үзең гамьсез.
Ничек инде булсын болай яшәп?
Миңа башка — ипле хатын хаҗәт!..
Әйтте хатыны: — Аерыл, Гатаулла,
Синсез дә бик әйбәт яшәп була.

Тик шуны бел:
Беренче яр — түшәк, гаиләң ак кояшы,
Икенчесе — хәсрәтеңнең килер башы!

— ...Да-а, шулай шул,— диде Гатаулла.

## *Туган ягым*

*(Җыр)*

Мирәт буйларында үстем,
Салкын суларын эчтем.
Чылтырап аккан суы тәмен,
Сихри болынның ямен
Ташлап, еракка киттем.

К у ш ы м т а:
Эх, Мирәт күл буем!
Кайтыр идем, күрер идем,
Тибрәнә синдә уем!

Күл өстендә акчарлаклар
Табигатькә ямь өсти.
Басмадан су алган кызлар
Һич тә исемнән китми.

К у ш ы м т а.

Бирер идем әллә ниләр,
Күрер өчен агышың.
Кайтып яр буенда йөрсәм,
Күлдә ай йөзгәнен күрсәм,
Бетәр кебек сагышым.

К у ш ы м т а:
Мирәт буе камышлар,
Сезгә кайтсам таралалар
Читтә җыйган сагышлар.

## *Гармун моңы*

Авыл тын. Утлар сүнгәннәр.
Ай Җиргә сибә нурын.
Тик бер гармун су буенда
Тарата яшьлек моңын.
Моң, ай нурына күмелеп,
Тибрәтә күңелләрне.
Сызылып барып кочып ала
Сихри зәңгәр күлләрне.
Дулкынлата ул күлләрне,
Тибрәтә ул тирәкне.
Нигә соң били алмый моң
Бары бер яшь йөрәкне?

## *Син генә...*

Күк йөзендә янган йолдызларның
Иң нурлысы була бер генә.
Таң йолдызы кебек, юлларыма
Яшәү яме сипкән син генә.
Күңелеңнең саф-пакьлеген өстәп,
Яшәү тәме биргән — син генә.

## *Ялгыз аккош кайда оча?*

Туган җиргә язлар килгән,
Сиреньнәр чәчәк аткан.
Ялгыз аккош кына оча
Без юлга чыккан яктан.
(Кемне эзлисең, якташ?)

Әйләнә күлләр өстеннән,
Яшьме, яңгырмы тама?
Сагышка, моңга кушылып,
Сулар ага да ага...
Каеннар яфрак яра.

Таң күлендә кыр казлары
Парлашып канат кага.
Ялгыз аккош, күкне иңләп,
Кемнәргә аваз сала?
Яшь-яңгыр һаман тама.

Әйтегезче, наныйларым,
Сез очып кайткан җирдән
Без барасы юл ерак, дип,
«Тәскирә» көенә җырлап
Үтмәделәрме ирләр?

Йөрәк янды, канат талды,
Җавап ала алмады.
Тик үзара серләштеләр
Сихри күлнең таллары.

## Моңлану һәм сызлану

Әллә инде җилләр усалланган,
Әллә инде каты күз тигән,
Яшьлегемнең сихри җырчылары —
Ак каеннар сулып баш игән.
Тургайларым гүя мәрткә киткән,
Сүрән чыгып килә кояш та.
Урамнарда өйләр кечерәйгән —
Тәбәнәеп калган бер башка.
Урай урманы да боегып тынган,
Җырлап акмый Шыңгый чишмәсе.
Аҗаганнар уйный шырпы сызып,
Кыр түрендә төннәр киртәсе...
Ах, ак җәй бит әле! Мондый күренеш
Керфегемә нигә эленгән?
...Күңелемдә сары яфрак шавы,
Гомерем агышына көз килгән.

## Тау менгәндә

Тормыш тавы сыкрата да куя
Кайвакытта тиеп теңкәгә:
Менгән чакта, йөгең артка сөйри,
Төшкән чакта төртә җилкәңә.
Ә табигать тавы рәхимлерәк:
Әгәр калсаң анда адашып,
Авазыңны ерак яңгырата,
Кемдер килеп таба җан атып.
Тормыш тавы алдый. Син белмисең
Менгән мәлдә нәрсә буласын.
Хыянәтчел: кайчак упкынына
Баш-аягың белән чумасың.

## Яшен

Ялтырады яшен, гүя кереп
Утлы аждаһалар төсенә.
Кинәт суга инеш ярларына
Тирес аударучы кешегә.
Болытларны мамык кебек тетә,
Аннан бик аз тынып тора да,
Бәрә күккә корым ыргытучы
Юан, биек тимер торбага.
...Кышның уртасында яңгыр коя,
Җәйнең уртасында кар ява.
Адәм табигатьне пычратканга,
Бу Күк җәзасыдыр дөньяга.
Кеше агу ата һаваларга,
Агулый ул елга-суларны.
Сулышы кысылганга, яшен әллә
Шуңа күрә аны сугамы?

## Буран

Улый буран, дулый буран,
Котыра төне буе.
Гүя күктән җиргә төшә
Шашынган пәри туе.
Алар бииләр шикелле
Кыекта һәм чормада.
Өй эченә керер иде,
Керә алмый — догада!
Әкрен генә курку били,
Балачак бит, балачак!
Тормыш иблисләре белән
Алыш алда булачак.
Алар белән көрәшләрдә
Йөрәгем таланачак.
Прометей төсле чукылып,
Бәгырем канаячак...
Улый буран, елый буран,
Төшә дә моржаларга.
Аннан үксеп, моңнар булып
Тарала чормаларга.
Мич башында җылы, рәхәт,
Тыңлап ятам тын гына.
Ә күңелем түрләрендә
Гаҗәеп бер моң гына.

## *Ничәнче ел ялгыз аккош кайта*

*( Җыр )*

Ничәнче ел ялгыз аккош кайта,
Ничәнче ел моңсу язларын,
Күлгә төшкән серле йолдыз кебек,
Юлда калган беренчесен көтеп,
Ялгыз каршы ала таңнарны.

Ничәнче җәй ялгыз аккош йөзә,
Ялгыз башын чайкап суларга.
Ә бәхетлеләр, сабыйларын сөеп,
Тигез шатлык кичеп, парлашып
Китеп бара ерак юлларга...

Тал төбенә җан җылысын өреп
Кышлап калды ялгыз аккошым.
Хәтерләтеп гүзәл җирне, иңләп,
Миллион еллар үз тиңдәшен эзләп,
Күкне айкап йөргән ай кызын.

Язлар җитәр, сихри бозлар китәр,
Тагын сагыш басар ялгызны.
Туган күлен, хисен алышмаган,
Ялгыз аккош язмышына тиңлим
Беренчесен көткән пакь кызны.

## *Ирләргә тиң пакь ханымнар*

*( Җыр )*

*Сугыш юлын үткән*
*артистка Бикә Шәкүровага*

Мәйданнардан тарих үтә:
Ветераннар саф-саф атлый,
Җиңелмәс юл хатирәсе —
Алтын Йолдыз нурда балкый,
Горур атлый ир батырлар.
Батырларга тиң ханымнар:
Утта калып та янмыйча
Илгә кайткан пакь хатыннар
Ирләргә тиң-тол ханымнар.
Егермеләп миллион чәчәк...

Ятып калган изге җаннар
Мәңгелек ут булып яна.
Тарих уты — ветераннар:
Исәннәре үксеп елый,
Ела-җырла — әй, хакың бар.
Мең дә дүрт йөз унсигез көн[1],
Мең дә дүрт йөз унсигез төн,
Яшь түкмәгән пакь ханымнар.
Сиксән алты[2] герой кызны
Мәскәү—Берлин юлы бирде.
Ун меңләбе зурлап үлде
Җан иңдергән туган илне.
Каннарында яшьлек дәрте,
Их, килгәндер сөеләсе...
Алсу ирен тәмен татып,
Бер янасы-көенәсе,
Иркәләнеп бер үбәсе.

## Туфрагында — юлаучы

Балкый җиһан. Менә туган авыл.
Таныш урам, таныш сукмаклар.
Бездән калган җырны җырлый кебек
Шыңгый ярындагы учаклар.
Яшь пәрдәсе каплый керфекләрне,
Диңгез сыман кайный бу күңел.
Каян килгән ят кеше соң диеп
Карап торасыңмы, и сеңел?
Юк, мин изге Хозыр Ильяс төсле
Алларыңа күктән төшмәдем.
Син тәгәрәп үскән урамнарда
Мин дә тәгәрәп бит үскәнмен.
Кем нәселе? Кәҗә Гаязыннан.
Күрәм, аның нурлы карашы...
Ул, авылда калып, бәхет тапты,
Мин бәхетсез — авыл ярасы.
Балкый җиһан! Балкый авыл күге,
Хәтта каз үләне сөйкемле.
Тик мин генә басып торам чатта,
Чит-ят бер юлаучы шикелле.

[1] Бөек Ватан сугышы 1418 көн бара.
[2] Сугышта 86 хатын-кыз Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.

## Җил

Борылып, борылып
ага кар суы...

*Халык җыры*

Тәрәзәдән керә дә җил
Хәлемне сорый минем,
Пар канатын кага-кага,
Туган илдән сәламнәр, ди.
Мең рәхмәт, туган, димен.
    Тәрәзәдән керә дә җил,
    Адәм күк уйга калып,
    Сызгыра «Тәскирә» көен,
    Мәңге иелмәс башымны
    Сагышка, моңга салып.
Моң, кар суы булып агып,
Йөрәк ярларын кагып,
Беренче хисне яңартты,
Ничек түзәргә тагын?
    Мәңге истән чыкмас инде
    Гомеремнең шул таңы.
    Халык белеп җырлый икән:
    Авыр, диеп, яннарыңда
    Җан сөйгәннәр булмавы.

## Бердәнбере идем җиденең

Мин заманның кадерсезе идем,
Бер үксезе идем чорымның.
Таптап китү белән баш калкыткан
Тузганагы идем болынның.
Ятиме идем басу капкасыннан
Яулык болгап калган авылның.
Кисү белән яңа шытым биргән
Бер тәлгәше идем каенның.
Әмма ләкин бер бөртеге идем
Мин әнкәйнең ап-ак чәченең.
Кадерлесе идем, күз алмасы,
Бердәнбере идем җиденең.

## *Сабантуй көннәрендә*

Арышлар серкә очыра,
Сабантуйлар көне җиткән,
Электән калган гадәт дип,
Егетләр яшьлек дусларын
Урлап кайталар кичтән.

Кодалар да килеп төшә
«Волга» дигән ап-ак атта,
Елмаялар, якланалар…
Кыз киткәнгә шатланалар,
Шундый йола безнең якта.

Сөлге җыя яшь-җилкенчәк,
Тальян моңы урам яра,
Килен йөзе
Әйтерсең лә йолдыз яна,
Ә күзләре шомырт кара.

Урамдагы ак каеннар
Юксыналар яшьтәш кызны.
Таң атканчы зур туй бара,
Яше-карты тәбрик итеп,
Сузып җырлый тәүге җырны.

Пар бармаклар пар балдакны
Кабул итсен җиңел кулдан,
Пар сандугач парлап сайрап
Гөрләп үтсен язмыш дигән,
Тормыш дигән олы юлдан.

## *Агар су булсам иде*

Салкын чишмә суы булып
Аксам теләгән җиргә,
Кайтыр идем, юллар ярып,
Иң элек туган илгә.

Борма-борма эз калдырып,
Далалардан бермәлне
Үтәрмен мин тамырына
Шиңеп калган гөлләрнең.

Урармын урман-болыннан,
Сандугач моңын тыңлап,
Ялгыз аккош уйнар иде
Суымда, җырлар җырлап.

Янган тамагын чылатсын
Җаны көйгән дошманым.
Көмеш кебек саф-пакь суым
Эчә килсен дусларым.

Зур Иделгә кушылырга
Ашкына минем күңел.
Ярында сөйгәнем калды,
Нигә соң мин су түгел?

## Газиз әнкәм йортына

*(Җыр)*

Кар сулары җырлар җырлый,
Моң агыла тын гына.
Язгы кичләр, кайнар хисләр,
Сабый чак назларын эзләп,
Тарта әнкәм йортына,
Газиз әнкәм йортына.

Сиреньнәр ак шәлен япкан,
Күңел кайда омтыла?
Яшьлегем эзләрен эзләп,
Тарта әнкәм йортына,
Газиз әнкәм йортына.

Гүзәл илем юлларыннан
Поезд алга ыргыла.
Чәчләремә бәсләр төшкәч,
Ялгышканда киңәш сорап,
Кайтам әнкәй йортына,
Газиз әнкәм йортына.

Керфегеннән яшь кипмәгән,
Таңнарда уты яна.
Тик әнкәй сагынып көтә,
Барсын әнкәй гафу итә,
Без әнкәйгә гел бала,
Мәңге без аңа бала.

* * *

*Якташым*
*Хәлим Җәләлевка*

Бер карасаң — олуг шагыйрь,
Бер карасаң — сүз остасы,
Зур талант Хәлим Җәләй!
Кемгә языйм мактау хаты,
Неужели бу артистка
Тукай бүләге җәл, әй?

## Күккә юллаган үйлар

*(Хуҗиәхмәт һәм Рәшит абыйларга бер дога)*

Кайвакытта, җанны учка кысып,
Күккә карап алган көннәр бар.
Йөрәгемне сызлаттың да киттең,
Ул дөньяда, абый, ниләр бар?
Бармы анда җиде җәннәтләре,
Хур кызлары тиңсез сөйкемле,
Уты кайнап торган тәмуглары —
Монда безнең тормыш шикелле?
Юктыр, димен, анда кан коюлар,
Мәкер, явызлыклар, хыянәт.
Җирдә генә бит ул күзгә карап
Эшләнелә күпме җинаять.
Сездә кәеф кору тыелгандыр,
Тәңребезнең кулы катыдыр!
Дөньялыкта әле гел искечә:
Күбесендә иман — «ярты»дыр.
Хокукларда сезне кысмыйлардыр,
Барыгыз да анда тигездер.
Синең чактагы күк, биредә һаман
Ялган белән хокук игездер.
Кайчагында, җанны учка кысып,
Күккә карап алган көннәр бар.
Киек Каз Юлының йолдызыннан:
«Уең дөрес!» — дигән өннәр бар.

## Ил бәласе

Киек казлар китә... Офыкларга...
Күзгә күктә моңнар агышы.
Алар кебек, кешеләр дә китә,
Туган җирдә кала сагышы.
Адәм баласында гынадыр ул
Язмышларның иң дә кырысы.
Ватан кочагына бар да сыя,
Тик барысына җитми җылысы.
Азмы даһи башлар китеп барды,
Җитмәгәнгә җылы һавасы.
Гомер бакый ил кадәрле илнең
Бу бәласе һәм дә җәзасы.
Киек казлар кайта... Каршы ала
Туган якта калган сагышы...
Чит илләрне дан-шөһрәткә күмгән
Безнең күпме галим-зыялының
Җаны гына кайтып барышы.

## Яшәү сере

Тәгәрәп лә елыйсылар килә
Кайчагында ачы зарлардан.
Кемгә кирәк хәзер кеше зары,
Аңлаучылар сине кайларда?
Ташып алып югаласы килә
Диңгез дигән зәңгәр киңлектә.
Мәңге дөнья дигән матур ялган
Тотып тора җиһан-бишектә.
Сүтелеп лә китәселәр килә,
Җыеп алалмаслык иттереп.
Юк шул. Тормыш, чиш, дип алларыңа
Каршылыклар өя китереп...
Аптырагач, хис ташкыны булып
Кушылам да китәм язларга.
Заман кырыс. Хисләреңне менә
Аңлаучылар мохтаҗ назларга!
Ләкин җирдә гомер бакый һаман
Кешелекне Сөю коткара.
Сөю булса — фани дөнья яши,
Ул булмаса — Яшәү туктала.

## *Сагындым*

*ТАССРның атказанган артисткасы Л.Миңнуллинага*

Сәнгать туфрагыннан калкып чыккан
Умырзая идең, акыллым;
Сәхнә өчен үскән зифа гәүдәң,
Янар күзләр, тапкыр сүзләреңне,
Сихри моңнарыңны сагындым.
Ирләр булып түгел, кеше булып
Талантыңа кат-кат табындым,
"Гәлимә"нең[1] моңсу тавышларын,
«Мөнәвәрә»[2] ханым сагышларын,
«Туй күлмәге»[3] җырын сагындым.
Кара толымнардан төшкә кереп,
Йөрәк кылларыма кагылдың.
Уяндым да бөек Волжская,
Камская, Ильская[4] кебек
Сәхнә йолдызларын сагындым.

## *Кар суында шәл ага*

Кар башына кар җитә, дип,
Язгы тәңкәләр ява,
Кызлар күңелен җилкетеп,
Тамчы булып моң тама.
Су ташкыны ярны ашый,
Шул моңны җырга салып,
Чишмәдә кер чайкаучы кыз
Җыр тыңлый, уйга калып.
Шатлыктан елмайган кояш
Җиргә нурларын сибә,
Кар суына пакьлек өстәп,
Бер ак шәл йөзеп килә.

---

[1] «Кара йөзләр» драмасында төп каһарман.
[2] Г.Ахуновның «Хәзинә» драмасында төп каһарман.
[3] «Туй күлмәге» исемле җырны беренче башкаручы.
[4] Волжская, Ильская, Камская — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының тарихка кереп калган артисткалары.

Басмага баскан бер егет
Тальянын сузып-сузып
Уйнады да уйга салды
Ярдагы каен кызын.
Каен егете көнләшеп
Куйды да авыр сулап,
Язгы җил белән чайкалып,
Шәл алды бозлы судан.
Кар башына кар җитә, дип,
Язгы тәңкәләр ява.
Яр буйлатып шәл артыннан
Шәм шикелле кыз чаба.
Каен егете мутланып
Кызга сузды ак шәлне,
Басмадагы тальян моңы
Туктап калды шул мәлне.

## Әй, гафу итсәнә, йөрәгем

Чәчәкле болында
Пар йолдыз нурында
Ай кызы аңлатты серләрен.
Бу, диде, пакь кичем,
Беренче саф хисем.
Бәхетле киләчәк теләдем,
Аңламый ялгышты йөрәгем.
Сайрады, таң тугач,
Тирәктә сандугач,
Әрни ул сагыштан, беләмен.
Уйланып ялгызым,
Сагынсам таң кызын —
Мин аңа киңәшкә киләмен.
Әй, гафу итсәнә, йөрәгем.
Ә күңел әрнүле,
Офтана, сызлана,
Чын сөю югалткан сагыштан.
Ярдәм ит, йөрәгем,
Иң соңгы теләгем —
Беренче ярымны табышсаң,
Нишлим соң, узмыш юк язмыштан.

## *Серле йолдыз — Алия*

*(Жыр)*

Гөлстанда чибәрләр күп,
Кемнәр янымнан үтми;
Татар кызының карашы
Күз алларымнан китми.

Кушымта:
Серле йолдыз — Алия!
Мин түгел, алсу йөзеңә
Ай, кояш та баш ия.

Каршыбызда гөл-чәчәкләр,
Бульварларда гүзәллек.
Гүзәллекләрдән гүзәл син,
Белмим ничек түзәрмен?

Кушымта.

Ул сүзләрең — тартым көче,
Елмаюың нур өсти.
Матурлар күп бакчаларда,
Татар кызына җитми.

Кушымта.

## *Фәйрүзә*

Күңелемнең түрләрендә
Гөлләр, чәчәкләр үсә.
Шул чәчәктән букет бирсәм,
Алырсыңмы, Фәйрүзә?
Яз тургае Фәйрүзә!
Карашың бәгырьне өзә,
Йөрәгем ничек түзә?
Маңгай бөдрәләрең сыйпап,
Иркәләп җилләр исә,
Таралсын йөрәктә сагыш,
Бер елмайчы, Фәйрүзә.
Яз тургае Фәйрүзә!
Карашың бәгырьне өзә,
Йөрәгем ничек түзә?

Каршыбызда бәхет таңы
Юлларга гөлләр тезә.
Киләчәктә, пар йолдыздай,
Балкып яныйк, Фәйрүзә.
Яз тургае Фәйрүзә!
Карашың бәгырьне өзә,
Йөрәгем ничек түзә?

## Үзең өчен генә өз син мине

Серле күзнең
Серле тамчылары
Кушылып агар кебек яңгырга.
Яңгыр булып ю да өз син мине,
Урам гөле итеп калдырма.
Өз син мине
Үзең өчен генә,
Алларыңа куеп иркәлә.
Таңда каплар болыт,
Өз син бүген,
Соңга калуың бар иртәгә.
Күңел йолдызларын,
Йөрәк сагышларын
Барыр юлларыма сипкәннәр.
Ай Зөһрәсе булып
каш сикертеп ала
Төшләремә кереп үткәннәр.

## Алма-Атаның алмасы

*(Җыр)*

Кояш нуры кызарта
Алматаның алмасын.
Саф күңелемнең бүләген
Ал, йөрәгең янмасын.

Кушымта:
Йөзең пешкән алмадай,
Ай күк тора нурланып,
Таң йолдызым, кайтырмын,
Яшь түкмә син моңланып.

Янмасын йөрәкләрең,
Ал, бәгърем, бүләкләрем.
Алтын алмадай сакла,
Шул соңгы теләкләрем.

Кушымта:
Йөзең пешкән алмадай,
Ай күк тора нурланып,
Таң йолдызым, кайтырмын,
Яшь түкмә син моңланып.

## *Соңгы үпкә*

*(Җыр)*

Айлы кичнең йолдызлары,
Җем-җем итеп ялгызлары,
Ялгызлары оча күктән.
Йолдыз кебек очар идем,
Иркәләнеп кочар идем,
Онытылса соңгы үпкәм.
Соңгы үпкәм,
Соңгы үпкәм...

Кушымта:
Йолдызлар! Ачыгыз аңа
йөрәгем серен.
Аннан башка бер ямь дә юк,
Аннан башка яшәү дә юк,
Шул серләргә яшеренгән
бәхетем минем.

Йолдызларның парлысына,
Сафлысына, пакьлесенә
Безгә тиңләп карыйм, иркәм.
Яшьлек бәхетең кайтсын дисәң,
Беренче кат башың исәң,
Еллар йөрткән серле үпкәм,
Бетмәс микән,
Бетмәс микән.

Кушымта:
Йолдызлар! Ачыгыз аңа
йөрәгем серен.
Аннан башка бер ямь дә юк,
Аннан башка яшәү дә юк,
Шул серләргә яшеренгән
бәхетем минем.

## *Күкләр алдамады*

Ни өчендер Күкләр хупламады
Яшьлектәге ашкын хыялны.
Ә хыялда
Тиңсез матурлыклар, бәхет эзләп
Үтү иде озын юлларны.

Чакырып торды Урал биеклеге,
Ангараның ярсу шаулары.
Ләкин мине тартты Кама-елга.
Балачакның Бәтке таулары.
Хыялымда үзенә кул изәде
Төрки дала, Татар бугазы.
Әмма юлым гүзәл Иделемнең
Ярларыннан ерак узмады.
Күкләр гүя миңа бәйләп куйды
Кендек каным тамган җиремне.
Ах, туган як!
Синең киңлегеңнән бу дөньяның
Бөтен матурлыгы күренде.
Юк, күкләрем мине алдамады,
Үскән туфрак булган тәхетем.
Ят тарафта таба алмас идем,
Туган җирдә таптым бәхетем.

## *Юк, кеше яши*

Сүнгәннәр яшәми, диләр,
Сүнгәч тә яши кеше.
Аны үлемсез итә бит
Калдырып киткән эше.
Ул — үзе утырткан агач,
Урманнар булып үсә.
Тирен түккән бакчаларда
Җимешләр булып пешә.
Чишмәләр булып ага ул,
Киткәнгә юлын ачып.
Яңа төзелгән калалар
Булып тора ул басып.
Алмашларның һәр эшендә
Зур тормыш төсле яна.
Менә җыен әшәкедән
Тик тузан гына кала.
Галимнәр — ачышларында,
Шагыйрьләр — поэмада,
Язучылар романнарда
Гомер сөрә дөньяда...
Мин дә җырларым калдырам,
Беләм, бер сүнәчәкмен...
Үлгәндә дә үлмәсемә
Ышанып китәчәкмен.

## Ташлама, шигърият

Язмыш мине салып кыйнаганда,
Йөрәгемдә янды бер ният:
Юлда бәхет ташлап китсә китсен,
Тик юлдашым булсын Шигърият.
И Шигърият! Гомерем кышларында
Булдың миңа кайнар учагым.
Тормыш суыклары өткән чакта,
Урын бирде җылы почмагың.
Айлы төнем, якты көнем идең,
Өмет өрдең шомлы таңыма.
Яшәү ялкыннары өстәп тордың
Кыйналудан арган җаныма.
Рәхмәт Сиңа, кире кабул иттең,
Һич сорамыйм шигъри тәхет тә.
Нурланышы булып моңнарымның,
Син әйләндең көткән бәхеткә.
Һәрбер туган таңым һәм көннәрем
Шул моңнарым белән башлана.
Языласы күпме җырым дәшә,
Пәйгамбәрем, мине ташлама!

## Өйрәттеләр

Гөнаһларым алай булмаса да,
Кемнәрдер арттан күзәттеләр.
Дөрес сүз бит, әйт, дип типте йөрәк —
Хак сүз сөйләмәскә өйрәттеләр.
Тәңре миңа моңлы күңел биргән,
Моңнар җанда җырлар дөрләттеләр.
Ул җырларда халык зары иде —
Мине җырламаска өйрәттеләр…
Тормыш юлы шома баскыч төсле,
Ул баскычтан йөкләр күтәрттеләр.
Тәгәрәп лә елар чаклар булды —
Мине еламаска өйрәттеләр…
Күтәрелде ташып яңа заман,
Заманга да иркенлекләр кирәк!
Аның мәйданында хак сүз сөйләп,
Иске кысаларны җимерә йөрәк.

## *Күңелдәге моңнар*

Авыл. Шыңгый яры. Туган нигез.
Ярдан тавыш бирә керәшә.
Гүя йөгереп чыгасың күк, әнкәй,
Күңел синең белән сөйләшә:
Күзләреңдә яшьләр... Сагындыңмы?..
Тик каргама мине, каргама.
Миндәй күпләр газиз туфрагыннан,
Нигезеннән китеп алдана.
Минем дә бит менә сагынуларым
Алларыңа кайтып ишелде.
Дәшмә... Беләм... Авыр...
Югалдым шул
Синең соңгы казың шикелле.
Соңгы бәбкәң кебек юкка чыктым,
Тормыш дигән тилгән урлады.
Ләкин ышан, бервакытта да син
Йөрәгемнән чыгып тормадың.

## *Хата киңәш*

Җырчы булма, диден миңа,
Ул сиңа кирәк түгел.
Шагыйрь гомере — бәхетсез,
Ул гомер — утлы күмер.
Бул син, диден, сәясәтче,
Алар нинди көчлеләр.
Күкне иңнәрендә тоткан
Алып Антей төслеләр.
Бар шөһрәт-дан аларныкы,
Бәхете күктән ява.
Алар тотка ясаучылар
Син яраткан дөньяга!

...Юк, тотмадым киңәшеңне,
Мин идем моңлы бала.
Сәясәтче килә-китә,
Ә җырчыдан җыр кала.

## Сызлану һәм юану

Шатлык килде,
Бар дусларга
Уртак бүлдем;
Кайгы килде —
Алар качты,
Ялгыз идем.
Бәхет кунды —
Барысына
Тигез бүлдем.
Сагыш кунды —
Мин һаман да
Ялгыз идем.
Газапларны
Учларымда
Ялгыз сыктым.
Мин берүзем
Тирән юллар
Сызып чыктым.
Минем белән
Бары кара
Күзләр иде.
Йөрәгенең
Җылысын ул
Миңа бирде...

## Энекәш

Хәсрәтләрне бушатырга теләп,
Йөрәк таләп итсә бер сердәш,
Өшеп калган җанны җылытырга,
Ярый, син бар әле, энекәш.

Башларыма уй-кайгылар төшсә,
Сорап килсәм сиңа бер киңәш,
Дөрләп-гөрләп сөйләшерлек кеше,
Ярый, әле син бар, энекәш.

Чал чәчләре аның әткәйдәндер,
Нурлы йөзе — әнкәй, мәңге яшь.
Затлы нәселемнең дәвамы бул,
Бердәнберем, төпчек энекәш.

## Ирләр йөрәге

Ирләрнең йөрәген таш, диләр,
Ташның да күп гасыр ятканы.
Утларда калды ул — янмады,
Суыкта калды ул — сынмады,
Сынмады, бары тик чатнады.
Заманны күтәргән җилкәләр
Әйтемнең хаклыгын аклады.
Корычтай коелган мәрмәрдәй
Бастырсаң юлларның чатына,
Чын ирләр йөрәге эрер күк
Бары тик мәхәббәт хакына,
Бары тик сабыйлар хакына.

## Уйлану

Кул таягы башы
бүрек кигән:
Аякларны сагынып
сыкрый идән.
Җир-ананың газаплары
кими төсле.
Тол аналар зары, белмим,
бетәр микән?

## Кеше һәм заман

Гөрли заман,
Сөйли заман,
Мактый заман кешелекне,
Күмә-күмә гөлчәчәккә,
«Кеше» сүзен символ итеп,
Марс алыр киләчәктә.
Кешеләр ул — туачак моң,
Яңа марш, яңа җырлар.
Бәйсез дәүләт — Татарстан,
Без барасы яңа юллар...
Санап китсәң кешелекнең
Иксез-чиксез эш эшлисе,
Фикер йөртсәң — заман түгел,
Бар дөньяны буйсындырган
Кеше-титан иң көчлесе.

## Көнбагыш

Нинди кызу, челлә, җәй кояшы,
Нинди сихри кичен көнбаеш...
Кояш көнбаешка барган саен,
Аңа башын бора көнбагыш.
...Куштан савыт тота хуҗасына,
Көнбагыш күк, башын бора да.
Ялагайлар үрчи! Мәкер кавем!
Артык каза булып дөньяга.
Бик астыртын сатыла әхлак, намус,
Саф йөрәкле кеше сатыла.
Шундый түбәнлеккә төшә кемдер,
Үзе яшәп калу хакына.
Көнбагышны алай гаепләмим,
Ул бит табигатьнең җимеше...
Менә нигә сата-сатыла икән
Тәңре җимеше булган бу кеше?

## Модалар

Вакыт узып, чорлар үзгәрәләр,
Тик үзгәрми бары нужалар.
Заманалар кире кайткан кебек,
Кире кайтып йөри модалар.
 Егерменче еллар...
«Долой стыд» дигән төркемнәрдән
Шаулап тора Казан урамы.
Ярым шәрә кызлар-егетләрнең
Каннарында «ирек» бураны.
Барысы да тына...
Әдәп кайта үзенең кысасына,
Тормыш күген яулый яңа чор.
Әхлак эзләп таба иярен,
Туа таза рухлы яңа җыр.
Заман үзгәрде дә...
Шул ук мода тагын кире кайтты,
Урамнарда кыска итәкләр.
Ялан ботлы уйнак чибәрләрне
Азган хисләр бара җитәкләп.
...Заманалар кире кайткан кебек,
Кире кайтып йөри модалар.
Ата-ана, ил хәсрәте өчен
Мода булып килә нужалар.

## Карурман

Җирдә генә үсми каруманнар,
Кеше күңеле дә карурман.
Кайберсендә аның ерткыч йөри,
Кайсысына сагыш, моң тулган.
Сагыш-моңым төяп барган чакта,
Карурманда юлым саташтым.
Ләкин адашмадым... Менә синең
Карурманга кереп адаштым.
Күпме вакыт сукыр пәйгамбәрдәй
Йөрим һаман бәрелә-сугыла.
Сулга барсам — салкын йөрәгеңнән,
Уңда — мәкереңнән егылам.
Чыгар идем, сукмак таба алмыйм,
Ах, караңгы синең урманда.
Мин эзләгән зәңгәр чәчәкләр дә,
Сайрар кошлары да юк анда.
Минем урманымда чәчәкләрнең,
Кошларның да һич юк исәбе...
Ике карурманда — ике дөнья,
Нишләдең син, Сөю, нишләдең?

## Дөрес сүзгә җавап юк

Чәпчеде каен юкәгә:
— Мин агачның агачы!
Алдымда берни дә тормый
Хәтта бу алмагачы.
Миннән себерке ясыйлар,
Синнән — черек мунчала.
Себеркем белән кинәнеп
Чабыналар мунчада.
Ул кеше өчен шифалы,
Дару кебек сихәтле.
Хуҗалыкта да юк агач
Миннән битәр кыйммәтле!..
Юкә әйтте тыныч кына,
Чәпчүенә карамый:
— Кәперәймә,
Синең тактаң коймага да
Кагарга бит ярамый!

## Солдат күңеле

Солдат күңеле — янар хыяллар ул,
Үтелмәгән авыр юллар ул.
Постта торган һәрбер минутында
Туган ягын сагыныр, уйлар ул.

Солдат күңеле — алсу чәчәкләрнең,
Яшел тугайларның исләре.
Янып эшләп үскән колхоз кыры,
Тальян моңы, авыл кичләре.

Солдат күңеле — яшьлек дусларының
Вәгъдәләре, өмет чишмәсе.
Көткән кызының сагыш-хыяллары,
Укылмаган китап киштәсе.

Солдат күңеле — авыр чорыбызның
Ышанычы, көче, терәге.
Күз яшьләре тамган аналарның
Өметләре, керсез йөрәге.

## Тиктерделәр...

Аракы сөйгән берәүне
Җыелышта теттеләр.
Соңыннан, өенә барып,
Төне буе күңел ачып,
Самогонын эчтеләр.

## Сыраханә янында

Озын чәчле яшь бер чибәр егет
Кайдан алган яхшы гадәтне?
Килгән саен илле грамм сала —
Кеше булса булыр әдәпле.

Аз эчәсең, димен, тәртиплесең,
Акыллысың, хәйран китәрлек.
Ә бу әйтә: «Абзый, исе килсен,
Җуләрлеге миндә җитәрлек».

## Гарип калды

Яхшы кеше, уңган егет
Шофер Солтан.
Ниләр килми алтын кебек
Кулларыннан.
Дуслар бердәм, чумара да
Уртак иде.
Хезмәт кергән, аз булса да
Кабыйм, диде.
Иртүк торып баш төзәтү,
Аннан әбәт...
Кичләрен дә салмады ул,
Һич тә жәлләп.
Көнен салды, атна салды,
Елын салды.
Инде салмас, параличтан
Гарип калды.

## Юлга чыксаң

Юлга чыксаң,
Якын дусты
Була ала
Кешенең эт.
Әгәр дустың
Эт күңелле
Кеше булса —
Яманлык көт.

## Кеше түзә

Салкын урам,
Ачы буран...
Бара кеше,
Җилгә түзә.
Кеше түзми
Ачы сүзгә.
Ялган сүзләр
Үзәк өзә.

# *Көттермәгез*

*(Җыр)*

Язын юлда парын җуйган
Бер сандугач тирәктә
Кичтән таңга кадәр сайрап,
Ялкын өсти йөрәккә.

Кушымта:
Сандугач кебек өзелеп
Сагынмыйбыз кайсыбыз?
Көтегез, дип, киткән җаннар,
Көттермәгез, кайтыгыз.

Тирәкләрне тибрәндереп,
Канатын кага иртән,
Күңел серен уртаклашып,
Киңәшләр сорый җилдән.

Кушымта.

Ай, нуры белән төргәләп,
Юлларны айкый-айкый,
Керфегеннән тамган яшь тә
Сагышын баса алмый.

Кушымта.

Шомыртлар ак шәлен япкан,
Сиреньнәр чәчәк аткан,
Юлда югалган сандугач
Яшьлеген эзләп тапкан.

Кушымта:
Сандугач күк кавышырга
Хыялланмый кайсыбыз?
Көткәннәргә бик тә авыр,
Көттермәгез, кайтыгыз!

## Люциякәй

Люциякәй, каршы очраганда,
Мин эндәшсәм, миңа дәш, яме!
Син бит минем күңелем кырларында
Янар чәчәкләрнең бәйләме.

Люциякәй, алларыңа килеп,
Башым исәм, кабул ит, яме!
Син бит минем барыр юлларымда
Яшьлек көче, яшьлек бәйрәме.

Люциякәй, алларыңа килеп,
Кулым бирсәм, аны ал, яме!
Син бит минем,
Бары минем генә
Гомер сукмагымның бер яме!

## Чистару

Бу тормышның ыгы-зыгысына
Ис китмәде безнең,
Ис китмәде.
Хис күленең аккошлары идек,
Ни җитмәде сиңа,
Ни җитмәде?
Миндә янар таулар кайнарлыгы,
Синдә иде ак кояшның нуры.
Икебезнең дә шашкын йөрәкләрне
Наз дулкыны юды...
Бергә яккан сөю учагында
Хәзер сүнде ялкын.
Арабызга эзен салды шомлы,
Җан өшеткеч салкын.
...Дөнья гүзәл!
Аның күкләренә йолдыз итеп
Сөенечләрем атам...
Син вакытында язмышымнан киткән
Минем иң зур хатам!

## *Мәхәббәт сынавы*

*(Җыр)*

Таң аткач тыңлап таң калдым
Сандугач елаганын.
Хәлем аннан авыр иде,
Ләкин мин еламадым.

К у ш ы м т а:
Үз-үземә җавап бирәм,
Йөрәгем сызлаганда.
Ирләр гомердә бер елый,
Мәхәббәт сынаганда.

Язын күргәнең бардыр, әй,
Кыз бала елаганын.
Сөю килгән күңел тулган,
Уңайсыз, сорамадым.

К у ш ы м т а.

Көзен күзәткәнем бар, әй,
Кыр казы тавышларын.
Юлда калган парын эзләп
Очканын сагышланып.

К у ш ы м т а.

## *Күңел дулкыны*

Урай буйларында аксыл рәшә,
Инеш ярларында керәшә.
Тал кызлары, толымнарын сүтеп,
Йөгерек дулкын белән серләшә.
Ә сез кая, минем киек казлар?
Калдыгызмы чит-ят җирләрдә...
Рәхмәт сезгә, минем торналарым,
Кайткансыз бит туган илләргә.
Тургайларым, зәңгәр һаваларда
Гел сайрагыз шулай бирелеп.
...Зур тормышның тәрәзәсе аша
Балачакка карыйм үрелеп.

## Яшьлегем үткән урам

(Җыр)

Бер сандугач, ярын эзләп,
Таңнарда талга кунган,
Шул гашыйкның җырын тыңлап,
Сиңа унҗиде тулган.
Язын безне таныштырган
Яшьлегем үткән урам.

Бер аккош күлләрне иңләп
Эзләнә, дустын җуйган.
Бәхетлеләр моңын тыңлап,
Миңа егерме тулган.
Көзен безне кавыштырган
Яшьлегем үткән урам.

Юлларны кичтем әйләнеп,
Гомерне булмый урап.
Пар сандугач сайраганда,
Үткән көннәрне уйлап,
Истән чыкмый вәгъдәм калган
Яшьлегем үткән урам.

## Бу җир ял йорты түгел

Яшеллекнең сабый чагы,
Кая тартыла күңел?
Янса-көйсә, ашкынса да,
Күңелгә үпкәләрем юк,
Бу җир ял йорты түгел.
Каеннарның егет чагы,
Миләш кызына карап,
Алар гашыйк булган кичтә
Яшьлегем эзләрен эзләп,
Дөбъяз ягына барам.
Алатның гүзәл тавында
Сандугач моңын тыңлап,
Олы җанлы, киң күңелле,
Иң акыллы кызы белән
Таңнарда йөрдек җырлап.
Нәкъ безне генә яктыртып,
Йолдыз нур сипте күктән.

Иреннәр иренгә тигәч,
Усак егете көнләшеп,
Тал кызын кат-кат үпкән.
Йөрәкне таш түгел, диләр,
Нечкәрде хисләр бүген.
Бәхет алып килгән кешем,
Сине уйлыйм иртән-кичен,
Ничек сагынмасын күңел,
Бу җир ял йорты түгел.
Янып торган күзләреңне
Баксам да күрмәгәнмен.
Мине өзелеп сөйгәнеңне,
Шатланганың, көйгәнеңне
Ничек соң белмәгәнмен?
Белмәгәнмен күңелеңдә
Пакь һәм саф хисләр барын,
Яныңнан киткәч аңладым:
Күпме кайнар хисләр яткан
Изге җаныңда тагын.
Бер-беребезне бәяләргә
Бу көннәр кирәк булган.
Син басып калган юл чаты
Күз яше белән тулган...
Бер шәүлә килә юлдан.

## *Кайда соң?*

Балык Бистәсе ягыннан
Алсу таң аткан чакта,
Иркәли Яншык җилләре,
Мин кайтам туган якка.

Әй, ямьле, нурлы үзәннәр...
Без малай идек ул чак.
Бәтке чишмәсе суында
Бит юа идек туктап.

Яшь юа иде чишмәдә
Соңгы ат, соңгы ирләр.
Өч авылдан өч йөз батыр
Соңгы кат үткән җирләр.

Әткәйнең сагышлы җырын,
Әй, ятлап калган кырлар...
Биш ятимнең күз яшеннән
Газиз әнкәйнең йөзенә
Бик иртә чыккан сырлар.

Мин кайтам хыялга чумып,
Каршымда авыл тавы.
Кайда ул Шынгый чишмәсе,
Кайда ул таллар шавы?

Нәкъ шул чишмә буйларында
Мин бер кыз сагаладым.
Бөрнәки очы сылуы,
Йөрәкне телгәләдең дә,
Гомерлеккә яр булалмый,
Күңелне яраладың.

«Туй күлмәге» дигән җырым
Шул чибәр җаваплары...
Сагынудан талды микән,
Саргаюдан арды микән
Яшьлегем канатлары?

Чишмә ярында тукталам,
Карыйм су тәмен татып.
Көмеш суда ак чәч йөзә...
Эх, ник тиз үтә вакыт?..

## Солтанлы мәктәп

Кайда юнәлсәм дә, минем өчен
Кадерлерәк төбәк юк ла ул.
Мин онытмам Солтан мәктәбенең
Яшьлек эзем салган сукмагын.

Шушы сукмак алып чыкты безне
Олы юлга, еллар чатына.
Хатлар язган идем яшьлегемә
Барып җитмәс ләкин хат кына...

Биләп ала кинәт хатирәләр, —
Киң урамнар безгә тар иде.
Солтан кызларына егетләнеп
Күзне кыскан чаклар бар иде.

Чал төшсә дә сүрелмәде ул дәрт,
Йөрәк һаман шул ук, яшь, кайнар.
Читләрдә дә олтан булмадык без,
Олтан буламыни Солтаннар?!

Олтан булмадык без, солтан булдык.
Шома булдык, нәсел — чуртаннан.
Рәнҗеткәннәр, гафу итсәгезче,
Бар булганны кабул итсәгезче,
Мин сезнеке инде — Солтаннар.

## *Мин булмам*

*(Җыр)*

Ах, бу күзге кичнең зәңгәрлеге!
Урамнарга сихри моң тулган.
Зәңгәр кичтә балкып килер идем,
Диярсең дә, ул чак мин булмам.

Шаулы язда нинди могҗиза бу,
Таулар итәгендә ак томан?
Томаннардан эзләп табар идем,
Диярсең бер, инде мин булмам.

Ялгызлыктан өшегән чагың булыр,
Ялварырсың: дустым, мин туңам!
Йөрәк җылысы белән җылыта иде,
Диярсең лә сыкрап, мин булмам...

## *Киек казлар кайта*

Киек казлар тагын кире кайтыр,
Туган якка тарткан — күңел ул!
Кеше гомере дә кире кайтса,
Икенче кат мин яшәмәс идем —
Кабатлану кызык түгел ул.

## *Үлем дәшкәч*

*(Әнгам Атнабаевка ияреп)*

Үлем дәшкәч нәрсә дияргә?
Якын итеп эзләп тапкан икән
Туры килә барсын сөйләргә.
— Бурычым күп, туган, судан —
салкын,
Уттан ялкын алдым, — бирмәгән.
Нәрсә булыр җирдә эз калдырмый,
Җиңел китсә шулай һәр адәм...
Беләгемнең көчен, йөрәк дәртен
Килә намусымны түләсем.
Шатлыкларым, кайгы-хәсрәтләрем
Түләмичә ничек үләсең?
Туган туфрагыма хакым бик зур,
Кабул итмәс, үлем, ялгышма.
Бер чибәргә бәхет вәгъдә иттем,
Түләмәдем, салдым сагышка.
Үтелмәгән юллар, корыч куллар,
Изге теләкләрем калмасын.
Илгә, халкыма да бурычым зур,
(Юк, юк, үлмим, Алла сакласын.)
Үлем кадәр олы башың белән
Очсызланма, калдыр, яшәрмен.
Бурычларым бетеп хәлсезләнгәч,
Кунак итеп үзем дәшәрмен.

## *Килеп чыгар әле каршыма*

Күлнең сандугачы илдән киткән,
Ярсып шаулый шомлы тал гына.
Кара чәчен артка тарап салып
Килеп чыгар төсле каршыма.

Яшьлек көтә язмыш кайтавазын,
Гафу итмәс кебек җан гына.
Гафу итмәс, җаным өмет итә,
Килеп чыгар диеп каршыма.

Соңлап кайткан кәккүк тавыш бирә,
Сагынудан янма, ярсыма.
Күзләреңә өмет нуры өстәп,
Килеп чык син, җаным, каршыма.

## *Сынмадым-сыгылмадым*

*( Җыр )*

Юл чатында ап-ак шәлдән
Чиккән яулык болгадың.
Себер урманнарын ярып,
Тальян булып чыңладым.
Дошман сынды, ә мәхәббәт
Сыналды, сыгылмады.

Зилзиләле давылларда
Илдән хәбәр тыңладым.
Тамырларымны куптарды,
Ләкин үзем сынмадым.
Туган яктан җыр агылса,
Дус-ишләрне уйладым.

Күпме язлар, кошлар кайтты,
Мин юк идем, дускаем.
Салават күпере чыкса,
Кавышуга юрадың,
Яшьләр түктең, рәхмәт, көттең,
Сынмадың-сыгылмадың.

## Ап-ак, чачлар

Маңгай бөдрәләрең бәсләнгәннәр
Кара иде, диләр, күптәнме?
Җыерчыксыз йөзгә салынганда,
Ак бөртекләр сөйли үткәнне.
Күптәнме әле тальян гармуннарда
Моңга салып сихри күңелне
Соңгы җырлар утлы давылларда
Күз яшьләре белән күмелде?
Ул бөртекләр биргән вәгъдәләргә
Тугрылыклы булып агарган.
Ил кичергән еллар авырлыгы
Саклап калды мине яманнан.
Ул ак чәчләр халкым өметләре,
Акландылар барсы азактан.
Аклансам да, һаман агаралар
Шул көннәрне уйлап, газаптан.
Язмыш, никтер, сөеп иркәләми,
Безнең яшьтәшләрне гел какты.
Ап-ак чәчтән күргәч, авыл халкым
Аягүрә торып кул чапты...
(Мин сәхнәдә идем ул чакны.)

## Сөю килгән кыз бала

*(Җыр)*

Сары-сары, сап-сары
Язның гүзәл чаклары.
Алсу йөзгә сипкел төшкәч,
Сөю какты капканы.
　　Күңелләргә шомнар салып,
　　Гөрләвекләр акканы...
　　Сөю килгән кыз баланың
　　Йокы күрми ятканы.
Яралар булып уелган
Зур сөю килер-китәр...
Сары төшкән йөзләреңне
Күбәләк сыйпап үтәр.
　　Кыр казлары аваз салыр
　　Ак болыт арасыннан,
　　Гашыйклар көзен саргая
　　Мәхәббәт ярасыннан.

## Алмалары пешәр әле

(Җыр)

Алмалары пешәр әле,
Җыеп алырсың әле.
Аерылып киттең еракка,
Исеңә төшәр әле.

Алмалары пешәр әле,
Җыеп алырсың әле.
Хәзер сагынмыйм, дисәң дә,
Бер сагынырсың әле.

Алмалары пешәр әле,
Җыеп сакларсың әле.
Алмагачлы юллар буйлап
Бергә атларбыз әле.

## Илдар Юзеевкә

(Дусларча шаяру)

Язучыдан — бөеклеккә
Менәргә төрле юл бар;
Еникинең[1] йөрешләрен
Подражать итә Илдар.

Башың түбән салып йөрмә,
Алга тарт Пегас йөген.
Бөеклегең һич кенә дә
Әмирханнан ким түгел.

## Нигә башны салга салырга

Алсу таңда, минем язмыш булып,
Бер сандугач җылый тирәктә.
Сулык-сулык сулыш алмый елый,
Ходай түзем бирсен йөрәккә.

Яшь күрсәтмә, яшьлек сандугачы,
Без сынарлык-сыгылырлык түгел.
Нигә башын салга салсын әле
Алтмыш яшьтә сөю көткән күңел?

---

[1] Халык язучысы Әмирхан Еники.

## Ләбиб Леронга

Күп пародия яздың,
Син, туган, тәмам аздың.
Атказанган исемне дә
Чират тормыйча алдың.

## Рәшит Шиһапка

*(65 яшь тулу уңае белән)*

Ике томлык китап
Бастырган Рәшит Шиһап.
Тугыз сум гонорар тигән,
Ясагач исәп-хисап.

## КамАЗ күтәрелә

*(Җыр)*

Гүзәл Кама буйларында
Тормышка аша хыял.
Әкият сыман чынбарлыкны
Ничек сыйдыра бу яр?

Кушымта:
Барлык җирләрдән көч алып,
Яшь йөрәкләр бердәм янып,
Татарстан күкрәгендә
Балкып КамАЗ күтәрелә.

Күтәреп ала якташлар
Төрле ил кунакларын.
Балкытсын гигант адымнар
Матур Чаллы якларын.

Кушымта.

Җир астында кара алтын,
Өстендә КамАЗ балкый.
Татарстан — республикам
Яңа уңышлар яулый.

Кушымта.

## Көймә чайкала

Идел ярында дулкыннар
Шаулый, айкала.
Толымнарын җил иркәли,
Көймә чайкала.

Кушымта:
Тибрәнә көймә,
Яшьлек дулкыннардай ярсып,
Ярларны сөймә.

Ярсу дулкын кочагында
Чибәр язмышы.
Сагышларын моңга салып,
Җырлый таң кызы.

Кушымта.

Сихри җырдан ак каеннар
Кинәт тын кала.
Чал яр упкын тоткынынннан
Таң кызын ала.

Кушымта.

Яшькә чумган серле күздә
Ай нурлары бар.
Гашыйклардан мәрхәмәтле,
Хәтта җансыз яр.

Кушымта.

## Җыр пәйгамбәре

*Хөрмәтле җырчыбыз*
*Сөләйман Йосыповка*

Тавыш өләшкән чагында
Иң алдан килдең мәллә,
«Иң затлысын җәлләмичә
Бирегез!» — дидең мәллә?

Күп тавышлар арасында
Синеке — бигрәк көчле,
«Җиз кыңгырау»[1] моңы аккан
Язгы бер ташу төсле.

[1] «Җиз кыңгырау» җырын беренче башкаручы.

Шаляпинга тиңләр идек,
Һич тә шаярмый-көлми,
Шаляпин бит, тезеп-тезеп,
Татарча җырлый белми.

Ничек инде котламыйсың
Шундый күркәм бәйрәмне,
Җаныбызны дәвалаган
Сөләйман пәйгамбәрне!

Һаман яшьлеккә кайтарсын
«Пар ат»та[1] җырың-хисең.
Котлы булсын киләчәгең —
Йөз яшьлек бенефисың!

## Яңа елда яңа теләк

Яңа елда
Чыктык юлга,
Бик тә чиста кар ява.
Ак кар кирәк,
Пакь кар кирәк,
Сафлык җитми дөньяга.

Юртак чаба,
Карда чана,
Ә чанада туй бара.
Татлы сүзләр,
Гашыйк күзләр,
Сөю җитми дөньяда.

Йөрәкләрдә,
Күңелләрдә
Кемдер калдырган яра.
Уйныйк, көлик,
Җырлыйк, биик,
Шатлык җитми дөньяга.

Хаклык теләп,
Пакьлек теләп,
Өмет утлары яна.
Ә мәхәббәт
Дәвам итсен,
Алмаш килсен дөньяга.

[1] «Пар ат» — җыр.

## *Өр-яңа председатель*

### 1

Туйган идек,
Күпне чөйдек:
Берсе — надан, берсе — яман,
Берсе — куык, берсендә — тел.
Җибәрделәр безгә тагын
Өр-яңа бер персидәтел.
Килеп төште һәм кереште...
Җиң сызганып,
Эшләпәсен кыңгыр салып,
Басуларны йөреп чыкты,
Түтәйләрне күреп чыкты,
Кайберсенә кереп чыкты.
Кызып китеп,
Ферманы да карап чыкты,
Мал-туарны барлап чыкты.
Һәм шуннан соң,
«Не то!» диеп,
Каш сындырып йөзен чытты.
Үзбәкчәләп тел шартлаткач:
— Кич җыелыш идарәдә,
Йөз процент явка булсын,
Аңлагансыз, Илдар ага! —
Диеп, яңа персидәтел
Китте-барды шул арада.

### 2

Җыелыш бара.
Халык — колак.
«Леп-леп» йөрәк,
«Келт-келт» сәгать.
— Ни ит, ни сөт,
Ни җон, ни май
Колхоздагы терлектән.
Полный лилипутия бит!
Бар мал вакланып беткән.
Дүрт йөзгә якын сарык,
Берсеннән-берсе арык.
Көлке тагы сыерлар,
Җилем селкеп су ера.
Минем тәкъдим — суярга!

Кәҗә хәтле андый сыер
Чынлап торып закусить итсәм,
Минем эчкә дә сыер.
Казларны сую хаҗәт!
Пускай алар аз булсын,
Аз булса да китайски,
Пләмәнни каз булсын.
Аннан үрдәк мәсьәләсе:
Ул үрдәкләр үрдәкмени?
Күргәзмәдә үрнәкмени?
Чыпчык хәтле биш йөзе дә,
Нәселсез барлык үрдәк.
Алпан-тилпән килеп бүтән
Йөрмәсләр безне үртәп, —
Суярга, диеп әйтмим.
Сатарга минем тәкъдим.
Юкмы Сәвиткә каршылар?
Юк, минемчә!
Әйткәнемчә,
Өстән килде шундый карар —
Токымлы мал арттырырга.
Долой җыен лилипутлар!
Кирәк барсын весь кырырга,
Кырып бетереп фермабызга
Нәселле мал тутырырга.
Шулай иткән чакта гына
Безнең эшләр гөрләячәк.
Һәр колхозчы йөрәгендә
Эш ялкыны дөрләячәк.

### 3

Җыелыш бетте.
Көннәр үтте.
Үрдәк-казлар очып китте.
Сарык, сыер — бар лилипут
Фермабыздан таеп бетте.
Хәзер бездә токымлы мал.
Барсы — эре,
Барсы — үрнәк:
Җиде сыер,
Унбер сарык,
Унике каз,
Унбиш үрдәк.
Колхозыбыз гөрли хәзер,
Йөрәкләр дә дөрли хәзер.

Бар колхозчы үзбәкчәләп
Тел шартлатып йөри хәзер.
Молодец шул персидәтел,
Белә икән эшнең рәтен.
Дөрес, бу да бик аз торды.
Аз торса да, колхозны ул
Агач атка атландырды.
Теңкә корды.
Күпне чөйдек.
Берсе — надан,
Берсе — яман,
Берсе — куык,
Берсендә — тел.
Тагын өстән килә, имеш,
Менә дигән персидәтел.

## Әби белән бер кыз диалогы

Көч-хәл атлап,
Яулыгының
Чите белән
Битен каплап,
Очраганнан
Саулык сорап,
Әдәп саклап,
Юлдан бара
Түбән очның
Хөппи карчык.
«Саумы, әбкәм!
Сүзең бүләм», —
дип, каршымда
Нидер сөйли,
Ярсып-ярсып,
Югары очның
Сары Гөләм.
Үзе чибәр,
Үзе зәһәр.
Чәчләр җирән…
Бигрәк күркәм.
Ул күлмәкләр…
Ул күкрәкләр…
Ул башында
Заграничный,
Гармоничный,
Кабартмадай
Сары берет.
Ул күзләре!
Елан кебек
Боргаланып,
Урам иңләп
Йөрешләре,
Үзләре бер
Авторитет.
Хөппи карчык,
Шаярткалап,
Мавыктыргыч
Сүз аткалап,
Күңел кылларын
Тарткалап
Сорау бирде:
«Чемодан да
Кулларыңда,
Кияү дигән
Афәтеңә
Әллә, бәбкәм,
Китү мәллә?»
«Аңа түгел,
Икенчегә.
Интеллигент
Гарык итте,

Ягъни, барам
Игенчегә.
Китәм, әбкәм,
Китәм инде.
Борыч Гайфи
Хатыныннан
Аерылгач,
Яучы килде.
«Чемоданың
Бик бәләкәй», —
Диде карчык.
«Заманы шул,
Бу заманда
Бирмәсен дә
Ходай артык, —
Диде Гөләм,
Тәмам ярсып. —
Мескенкәйләр,
Бичаралар...
Сезнең заман,
Әйтер идем,
Ник булдыгыз
Шулай надан?
Төягәнсез
Түшәк, ястык,
Чүпрәк-чапрак,
Чана тартып,
(Ха-ха-ха-ха)
Көлеп үләмгә
Тау кадәр мал
Җый да, имеш,
Кияүгә бар».
«Алай, — диде
Хөппи карчык, —
Безнең заман
Кызы, олан,
Булса да тормыш
Бик яман,
Бирнәсен дә
Күп җыйнаган.
Сафлык, пакьлек
Иргә киткән,
Тешен кысып
Сабыр иткән.
Ирне ир дип
Гомер иткән.
Хәер,
Сез яшьләргә
Ике айга
Шул чемодан
Бик тә җиткән», —
Дигән дә
Хөппи әби,
Үз юлына киткән.

## *Бер табактан ашаучылар*

Янартаулар бәреп чыктымыни,
Тетрәде бар Америка җире.
Гүя тотты аны гөнаһысы,
Тотты гүя үзенең яман чире.
Болытларга ашкан биналары
Ком тавыдай ишелде дә төште.
Бер гөнаһсыз меңләгән җан китте,
Күккә качкан фәрештәләр төсле.
Сыкрады җир, барлык халыклар да,
Бәддогалар яуды явызларга.
Террорчылар сабак укыттылар
Күкрәк суккан ачык авызларга.
Җитди уйлаганда — зур фаҗига!
Планета буйлап үлем шуыша.

## *Язгы мәхәббәт*

*(Җыр)*

Лебер-лебер сөйләшәләр,
Серләшәләр каеннар.
Каеннар күк гашыйк булып
Башым игән аем бар.

Кушымта:
Бер өрүдә зур сөюнең
Шәмнәре сүнә микән.
Язын килгән мәхәббәтнең
Шаукымы бүтән икән.

Көянтәдә сандугачлар,
Ничек билләре түзә.
Беренче килгән олы хис
Язын үзәкне өзә.

Кушымта.

Җил булып елап йөрмәсен
Зур сөю язгы таңда.
Кил күңелгә өмет өстәп,
Бәхетләр теләп җанга.

Кушымта.

## *Мөхәммәтнең җаны тавыш бирә...*

*Мөхәммәт Мәһдиевкә*

Казанбашта камыш шавы тынган,
Шаулап аккан суы саеккан.
Кояш никтер, ул көн иртә чыгып,
Алсу таң атканда баеган.
Гөберчәкне моңсу томан баскан,
Бер сандугач җылый бакчада.
Мөхәммәтнең җаны тавыш бирә:
«Эзләүчеләр булса башкалада —
Мин оҗмахта, дуслар, Арчада!
Туган якта музей салып ятам,
Шомырт чәчәк аткан бакчада!»

## *Яшәгәндә булсын*

Кайвакытта бер нәрсәгә
Минем исем китә:
Ни өчендер
Шагыйрьләрне корбан булу
Күбрәк данлы итә.
Герой булмас иде Җәлил,
Башын чапмасалар,
Бу хакта язылып калган
Җырын тапмасалар.
Бәлки, зурланмаслар иде
Кутуй, Кәрим, Алишның
Язган җырлары да,
Әгәр ятып калмасалар
Сугыш кырларында.
Туфанны ал. Бу әүлия
Күпме каһәрләнгән.
Җырчы бөеклеге килде,
Менгәч җәһәннәмнән.
Корбан булмаганы әнә
Яза, китә тора.
Исән чакта исеме яши,
Аннан онытыла.
Нигә килә соң бөеклек,
Шагыйрь сүнгәч кенә?
Корбан булып,
Йә дөрләп бетеп
Гүргә кергәч кенә?
Кемгә кирәге бар аның,
Каплап алгач кабер?
Яшәгәндә булсын иде
Кешеләргә кадер!

## *Хатирәләр яңарганда*

Рус белән гомер кичердек
сайрашып...

*Г.Тукай*

Бәтке — урыс авылы. Малайлары
Безнең белән кузна уйнады.
Әгәр алар хәрәмләшә калса,
Хаклык өчен йодрык сынадык.
Каршы як та җебегәннән түгел —
Җилкәбезгә төште кәшәкә...

Аннан җыелып бер карарга килдек:
Мондый ызгыш ничек әшәке!
Дуслар булып өйгә таралыштык,
Үсеп җиткәч, илгә таралдык.
Еллар узган саен, дуслыгыбыз
Хатирәләр булып яңарды.
...Урыс белән тату гомер кичтек,
Бер бишектән төшкән шикелле.
Тормыш безгә бер үк сынауларны,
Бер үк җиңүләрне китерде.
Табыла әле хәзер Державада
Мәче йөгертүче арага.
Рус халкына юк ул, кирәк түгел,
Никтер кирәк
Кайбер сәясәтче агага.
Шовинистлар арта синдә, Рәсәй.
Бу сагайта, хәтта куркыта.
Берсен-берсе тигез күрсә генә,
Күп милләтле халык Ил тота.

## Туры сүз

Авыл халкы тикшерүчән
Энәсеннән, җебенә.
Бу арада сөйләмидер
Хәбирәне кем генә.

Хатын-кызлар пышылдаша:
— Ни булды икән аңа,
Өченче елы кияүдә,
Тапмый гына бит бала.

Усал теллесе өсти
Туры китереп сүз җаен:
— Беренчесен табар иде,
Кысырдыр ул, мөгаен!

Очрашканда сорадылар
Шушы хакта үзеннән.
Әйтте:
— Мондый тормышка Үзем
Ник туганга үкенәм!

## Татар язмышы

Кактылар да, суктылар да аны,
Сөрделәр дә аны, типтеләр.
Туган туфрагыннан ерак куып,
Нигезеннән мәхрүм иттеләр.

Планетаның төрле почмагыннан
Ишетелә татар тавышы.
Ул тавышта үпкә, әрнү хисе,
Туган ягына бетмәс сагышы.

Вакыт үзгә хәзер. Яңа заманада
Аек акыл җирдә ятармы?
Нигә җыеп алмыйсың син, Рәсәй,
Үзең читкә сипкән татарны?

## Мәңгелек сер

Әкиятләрдә бөтен Алыплар да
Җиңеп чыга Гыйфрит, Диюне.
Тик берсе дә җиңә алмаган һич
Эчтә дөрләп янган Сөюне.

Кеше тормышта да акылы белән
Тезләндергән кара көчләрне.
Аңа буйсынган да, ачалмаган
Тылсым көчен утлы хисләрнең.

Мәшһүр ханнар, гаярь патшалар да,
Мәхәббәттән янып-көюдән,
Ярты ханлык, патшалыгын биргән
Нечкә билле бөек Сөюгә...

Юк иткән дә, кеше ясаган да,
Шанлы иткән дә Ул адәмне.
Менә беркем берчак аңлатмас
Шушы сөю серен галәмнең.

Сөю-илаһ! Бары бер тартылыш
Итеп карыйбыз без ник аңа?..
Әгәр сөюләрсез генә калса,
Зур фаҗига килер Дөньяга.

## *Ахун бабай*

*(Ziратта каберен күргәч)*

Кешелекле, игелекле иде
Хода биргән озын гомерең.
Халкыбызның күркәм сыйфатларын
Җыйган иде изге күңелең.
Бөтен авыл сиңа килә иде,
Тишек чиләк, чәйнек күтәреп.
Шундый оста ямап бирә идең,
Утлы кургаш белән үткәреп.
Ярма яргычны да син ясадың,
Үзе җиңел иде, ипле ул.
Бәйрәмнәрдә, ярма ярдырганда,
Бар авылга хезмәт итте ул.
Ә гөсләңме! Уңган бармакларның
Көйли-көйли җыйды кылларын.
Милли җырдан торган зур сәнгатьне
Җанга салды аның моңнары.
Үзең җыйган гармун моңнары да
Иң дәһшәтле утлы елларда
Йорт-курадан кайгыларны куды
Өмет бирел килер елларга.
Безнең халкыбызда алтын куллы,
Талантлы шәхесләр күп алар.
Ләкин кирәк халык һөнәрләрен
Яшәтүче синдәй осталар.
...Син мәңгелек йортта... Баш очында
Бөдрә каеннарның шаулары.
Ә урамда гүя сине эзли
Гөсләң, гармуныңның моңнары.

## *Аяныч*

Ялгызлыгы аны җитәкли дә,
Алып чыга шәһәр бакчасына.
Ул җитмештә...
Ялгыз күңеле сабый бала төсле
Иярә дә уйный
Моннан узып йөргән барчасына.
Кала иңенә сыенып таулар йоклый,
Башларында изри каурый болыт.

Күккә карый. Ә күк нинди зәңгәр!
Шунда илтер җанын соңгы минут...
Һәм һәркөнне ашыгып каршысыннан
Эшкә үтә япь-яшь чибәр ханым.
Аккош сыман горур сыны атлый
Яхшы белеп чибәрлекнең санын.
Карт күзәтә: караш, йөз чалымы,
Атлап барулары нинди таныш!
Гүя яшьлегеннән тәүге ярын
Китергән дә куйган ачы язмыш.
Аһ, ул сөекле яр! Хатыны иде,
Аерылдылар. Харап итте ялгыш.
Хатын-кыздан бүтән мантымады, —
Гомере узды сүрән, нурсыз-ялгыз!
Ә ялгызлык яшен камчысыдай
Телә йөрәген дә, бәгырен дә.
Уе утлы: вакыты җитеп килә,
Кайсы мәрхәмәтле салыр каберенә?!
Тәүге ярда калды нәни кызы.
... Алар бүген берсен-берсе белми.
Шул үз кызы алларыннан үтә.
Ә карт ялгыз... Соңгы көнен көтә...

## Булса да

Тормыш күкрәгендә бәргәләнәм,
Җиһан киң һәм иркен булса да.
Ул иркенлек, белмим, кем өчендер,
Ә без әле һаман кысада.

Фикеремә, уйларыма кысан,
Әлегә сүз иреге булса да.
Иң кысылган ыру татардыр ул,
Шушы иркен вә киң дөньяда.

«Карурман»нан чыктык томырылып
Тулпарларда — кыен булса да.
Дөрес юлны кемдер саташтыра,
Алда кора күпме бусага.

Тулпарчылар! Изге мәсләгеңә
Бару кирәк — кыен булса да!
Татар максатына ирешә ул,
Алларында җирләр упса да.

## Уфтанмагыз

Иң яраткан кеше... Шулай язган —
Бер көн сүнә гомер агышы.
Сөйләшәсе килә алар белән,
Их, ишетәсе килә тавышын.
Бер сорыйсы килә: — Ахирәттә
Нинди хәлләр бар соң, кадерлем?
Кай дөньяда күбрәк беләләр соң
Кеше дигән затның кадерен?
Изге китапларда әйтелгәнчә,
Яшәү чынлап бармы анда да?
Сагынасыңмы? Әгәр яшәү булса,
Сагышларсыз булмый кайда да.
Нигә кире кайтып китүләр юк,
Вакытлыча гына булса да?
Чиксез зарыгулар кимер иде
Нигезендә бер кич кунса да?..
Юк кайтулар... Күккә юлласаң да
Бөтен кешелекнең гозерен.
Беркем ача алмас Мәңгелекнең
Мәңге ачылмаган бу серен...
Уфтанмагыз, алда көтә, диеп,
Мәңгелеккә күчү сызыгы.
Әгәр гомер кабатланыр булса,
Калмас иде яшәү кызыгы.

## Яшәвемнең бизмәне

Бу тормышның күпме авырлыгын
Иңнәремә салып яшәдем.
Шуңадыр ул җиңел чакта чыга,
Авыр чакта чыкмый яшьләрем.

Сабыр төбе — сары алтын, диеп
Өйрәттеләр мине олылар.
Сабырлыкта бары шомнар гына,
Кыенлыкның аның моңы бар.

Шуңа күрә кыенлыксыз гына
Яши алмыймдыр мин бу җирдә.
Кечкенәдән моң баласы идем,
Моңсыз калсам, кирәк мин кемгә?

## Язмыш җәзасы

Кыен чакларыңда, кил, дидең син,
Чакырмаган көнең күрмәдем.
Менә минем сиңа хис дуласа,
Белә торып, кил син, димәдең.
Башкаеңа зилзиләләр төшсә.
Килеп җитче, дидең, арала.
Араладым... Шундук кинәт кенә
Мин-минлегең керде арага.
Уйнар кош идең шул түрәләрдә,
Шуңа бик һавалы булгансың.
Син бу җиргә игелек өчен түгел,
Сөяркәлек өчен тугансың.
Ә түрәләр көлеп таралдылар...
Күзләреңә кереп барасың.
Тагын чакырасың... Юаргамы
Йөрәгеңнең
Җиңел акыллылык ярасын?
Аны җирдә беркем юа алмый,
Ул тирәндә ята —
Үтеп киткән тормыш төбендә.
Тапланган язмышың җәзасы ул
Картлыгыңа барган көнеңдә.

## Мирасчы карт

*Авылдашым Каюм*
*Мөхәммәтҗанов ядкаре*

Синең хакта якты хатирәләр
Нигезеңә кабат китерде.
Бакчаңдагы нарат шавын тыңлыйм,
Җыр тыңлаган бала шикелле.

Ул шаулардан гүя ишетелә
Малай чакның еллар агышы.
Таң калдырып, безгә әкият сөйләп,
Җанны тылсымлаган тавышың.

Сихерләде «Камыр батыр»ларың,
Ә «Алпамша»ң әсир иттерде.
Һәр әкиятең күңел түрләренә
Мәгърифәтнең нурын җиткерде.

Эх, саега милли мирасларны
Алмашка тапшыру йоласы.
Юктыр бүген безнең арабызда
Аның синдәй Хозыр Ильясы.

Төсең булып калган наратларың
Янына киләм кайткач илләргә.
Алар миңа гүя үзең булып
Әкият сөйли сыман җилләрдә.

## *Сихри көч*

Әкрен генә йөзе төссезләнә...
Яшәү белән йөрәк алыша.
Йөрәк туктыймын, ди... Яшәү исә,
Ул яшәсен, диеп тартыша.

Күзләреннән нурлар китеп бара,
Ә аларда күпме әрнеш, моң.
Яшәү әйди тормыш кырларына,
Йөрәк карыша: аңа инде соң.

Табиблар да, бар да аптырауда:
Авыруга башка юк дәва...
Чү, нәрсә бу? Кинәт ишек ачыла,
Палатага тоташ нур ява.

Фәрештәдәй яныма килеп бастың,
Аh, Синдә ул нинди гүзәллек!
Сиздермичә сүнеп барган җанга
Кабат гомер булып күчәрлек.

«Буйсынды да йөрәк гүзәллеккә,
Яшәү кабынып, итте тантана.
...Их, хатын-кыз! Авырлыкны җиңү
Сезнең яратудан башлана.

## *Милли җыр*

Капка төпләрендә яшь йөрәкләр
Бер-берсенә хисле сыенган.
Төннең карасыннан агылып чыгып
Бер җыр килә инеш буеннан.
Тынган зирек-таллар, тынган урам,
Тыңлый аны гүя барсы да.
«Хафизәләм, иркәм, и аппагым!..»
Бу җыр канатында
Узган чорлар баса каршыга.
...Ул чакларда татар егетләре
Карурманнан атылып чыккан да,
Ирек, азатлык, дип кылыч айкап,
Атта яулар чапкан дошманга.
Йөрәгендә Хафизәләр булган,
Асылъярлар тулган моң булып.
Җиңүләре, янып сөюләре
Безгә килеп җиткән җыр булып.
Рәхмәт, җырчы! Ах, син бүген күпләр
Оныта барган җырны терелттең.
Үз күңелен үзе туң иткәннең
Күңеленә ялкын йөгерттең.
Моңнан калтыранды төнге урам,
Калтыранды инеш, чишмәләр.
Авыл булган чакта милләт яшәр,
Милләт булса, милли җыр яшәр.

## *Туган тел*

Тарих шаһит: золым телебезгә
Ничә тапкыр кулын күтәрде.
Иң беренче аны Явыз Иван
Кылыч йөзе аша үткәрде.
Горур калып, урманнардан чыкты
Ул чагында татар телебез.
Баш имәде чукындырганда да,
Шуңа күрә туган телле без.
Кызыл еллар аның итәгенә
Бик астыртын гына ут төртте.
Милли мәктәпләрне яба-яба,
Матур сөйләп, каты утыртты.
Мондый чакта исән каладыр ул
Телнең иң төплесе, зирәге.

Югалтулар булды... Ләкин ана теленең
Кайнар калды типкән йөрәге.
Заманалар белән нигә безгә
Килә тора ачы гөнаһлар:
Бүген туган телнең тамырларын
Корыта бара катнаш никахлар.
...И туган тел! Дөнья кочагына
Алып кердең безне иң элек,
Аннан яшәү бирдең! Син үзең дә
Яшәү кебек сүнмәс, мәңгелек!

## Ник

Кинәт кенә күңелсезлек килә,
Кайчак югалта ул чамасын.
Кайгылары үзе эзләп таба,
Ә бәхетне эзләп табасы.

Яшькә күмеп якын кешең китә,
Өрлек кебек таза чагында.
Барыр юлын яхшы белгәннәр дә
Кайвакытта юлын югалта.

Әмма кеше яңалыкка бара,
Аны тудыру өчен җан ата.
Күпсенмәче, Тәңрем, кеше гомерен,
Корып куйма аңа каршылык...
Син яраткан Җирдә Ул булмаса,
Ник Кояшың кирәк, Яктылык?!

## Кем белә

Габдерәхим абзый колхозыннан
Соңгы атны алып кыйбатка,
Болыт сыман ялларыннан сыйпап,
Сүзен сөйләп тора шул атка:
— И чаптарлар, — ди ул, — очар канат,
Сез идегез илнең терәге.
Көрәш, хезмәттә дә сезнең белән
Бергә типте егет йөрәге.
Дәвер очкычларга атланды да
Чыгып китте галәм катына.

Абруегыз пыран-заран килде,
Кадер бетте тормыш атына.
Килер бер көн: бетәр нефть-газы,
Булмас бензин — туктар машина.
Шунда тагын илнең шактый йөге
Төшәр синдәй атлар башына.
Сез дөньяга көтү-көтү кайтып,
Йөрерсез лә иркен кыр тулып,
Гүя гасырларның карыныннан
Чыккан яңа матур җыр булып...

...Еллар берсен-берсе этә-төртә
Киләчәккә таба йөгерә.
Габдерәхим абзый сүзен уйлыйм,
Бәлки, ул хаклыдыр, кем белә?

## *Югалтулар*

Гомер уза тора. Үткәннәрдә
Нинди рәхәт икән күрелгән?
Безнең йөрәкләргә ил кайгысы
Тугач та ук, ахры, үрелгән.

Ил хәсрәте тынган араларда,
Югалтулар телде бәгырьне.
Күпме дуслар китте мәңгелеккә,
Күрә алмый тиеш кадерне.

Мин соң Таһир түгел идеммени,
Ялгыз калган чакта Зөһрәмнән?
Хәзер яратулы тавышы гына
Колагыма килә күкләрдән.

Күпләр кебек әтиле дә идем,
Аны да бик яшьли югалттым.
Әнием дә иртә дөнья куйды —
Тормыш күкрәгемә ук атты.

Кайберәүләр:
— Мондый зарны нигә язган икән,
Кызганмаган, — дияр, — вакытын?
Шуңа яздым: Халкым ярдәм итте
Бушатырга кайгым савытын.

## Айны, татар!

Борылды да тарих әйтте бер көн:
Сине көчле итеп
Мин тудырдым, татар баласы!
Уйламаган идем күкрәгемдә
Тик канлы эз булып каласың.
Сатып эчтең шәхси горурлыгың,
Саттың гореф-гадәт, йоланны.
Таптап уздың бабаңнарның рухын,
Тереләй күмдең милли дөньяңны.
Үз телеңә төкереп карап,
Ят куенга акты хисләрең.
Милләт хәтле милләт эреп бетте, —
Нишләдең син, татар, нишләдең?!
Бүген чын иманга дога юллап,
Мәчетләрдән чыгу урынына,
Чиркәүләрдән чыгып киләсең син,
Кургаш тәре тагып муеныңа.
...Бүген әле болар шикләр генә,
Җанның сыктап, сыкрап торуы.
Ә кем белә,
Әгәр татар тизрәк айнымаса,
Моның бик тә мөмкин булуы.

## Авыр мизгелләрдә

Нинди кич бу? Йолдыз сипкән күкне
Каплады да алды кара болыт.
Караңгылык карый тәрәзәдән,
Кара йөрәкләр күк, шомнар булып.
Ә көне бит нинди матур иде,
Нинди якты иде зәңгәр дөнья!
Менә хәзер җанга кинәт кенә
Әллә нинди салкын яңгыр коя.
Яшен уйный. Пәри туе төсле,
Түбәләрдә бии куркыныч җил.
Капылт кына искә төшә шунда
Коръән кәлимәсе: «Иманга кил!»
Үрсәләнгән халәт ләкин тыныч:
Имансызлык кылып йөргәнем юк.
Гомер бакый әле тормышымны
Һич тә дәһрилеккә төргәнем юк.

Бу дөньяда бар да вакытлыча —
Кеше, гөлләр, чәчәк, караңгы төн.
Болыт таралды да...
Алтын Айның канатына асылып,
Тәрәзәмә карый иртәге көн.

## *Алданма*

Тормыш каршылыклы, ике яклы,
Дөнья аны шулай яраткан.
Әгәр шатлык килсә, туарылма,
Хәсрәтләре килер азактан.

Минем дуслар хыянәтчел түгел,
Алар миңа тугры димәгез.
Шулар арасыннан бер дошманы
Илтеп терәр ярга көймәгез.

Кемдер төче, купшы сүзләр әйтсә,
Күңелне киң тотып алданма.
Купшы сүздә үз мәнфәгатьләрен
Истә тоткан матур ялган бар.

Хаклык үзе идеаль кебек тә бит,
Ул да арынмаган ялганнан.
Хак сүз сөйләп йөргән бәндәләрдән
Мин тормышта йөз кат алданган.

## *Сүнде шагыйрь*

Сүнде шагыйрь, җырлар язмый, диләр,
Яңа моңлы сүзләр яумый күктән.
Җырлар туар өчен сөю кирәк,
Ә чын сөю тора гел хистән —
Хисләр сүнеп бара...

## *Кайтыйк әле*

*Якташ шагыйрь Роберт*
*Әхмәтҗанга Г.Тукай бүләге*
*бирелү уңаеннан*

Яншык — Арыш* — икесе куш дөнья,
Арада тик Мирәт-тау гына.
Шушы изге таудан килеп төштек
Дәшеп торган тормыш шавына.

Казан безне майлы кашык биреп,
Ботка тотып каршы алмады...
Ләкин көтте шигырь Иделенең
Җыр дулкыны тулы ярлары.

И яктырды аның киңлекләре!
Төшсә, энә эзләп табарлык.
Әмма никтер моңа ваклык белән
Түли килде мәнсез татарлык.

Соң булса да, уң булсын дигәндәй,
Таныдылар шигъри Кыяны.
Танымый калу мөмкин түгел иде
Прометеен җырлы Дөньяның...

Язлар белән
Кайтыйк әле Мирәт буйларына,
Яшьлекне дә бер яд итәрбез.
Чал Мирәттә каен кызын кочып,
Сөю җыры язып китәрбез.

## *Сызлану*

Җәйләр килсә, кичке зәңгәр күкләр
Йолдыз мәрҗәненә чигелә.
Күкләр мәңге матур! Җирдә генә
Кеше ашыга ямьсез чигенә.

---

* Иске Арыш — Р.Әхмәтҗан, Яншык — М.Шиһапов туган авыллар. Аралары бик якын. Балык Бистәсе районы.

Көзләр килсә, кара толып төсле
Кара болыт баса иңнәргә.
Илдә эшлексезләр арта бара,
Ил язмышы белән нишләргә?!

Кышлар җитсә, буран котырына,
Ач ерткычтай улый төннәрдә.
Ерткыч кебек миһербансыз үрчи,
Заман таянычы кемнәрдә?

Ах, арыдым!.. Гомерләрем буе
Төрле газап талкый күңелне.
Тик бер тыныч көнгә бирер идем
Артта калган бөтен гомерне.

## *Аерма*

Тезелеп китте кошлар көзләрендә,
Тарта дөньяның кайсы яклары?
Язларында күбесе кире кайтты,
Ә күбесе кире кайтмады.
Югалганын нинди упкын йотты,
Нинди давыл канат каерды?
Шундый матур күктән, шат җиһаннан
Юл афәте мәңге аерды.
...Тезелеп китте ана балалары,
Тик җаннары гына тартмады.
Бик күпләре калды ят туфракта,
Туган җирләренә кайтмады.
Кошлар белән кеше язмышлары
Охшаш диеп языла шигырьләр.
Алай микән?
Моны бары тирән хискә бирелеп
Язалардыр нечкә шагыйрьләр.
Кошлар китә үз теләге белән,
Күкләр
Табигатен шундый иткәннәр.
Ана балалары?! «Кайнар нокта»ларга
Ил әмере белән киткәннәр.
Кешелекнең бүгенгегә юлын
Түшәп килгән күпме корбаннар.
Тау илендә таулар әйтерсең лә
Корбаннардан торган курганнар.

## *Мирас*

Тормыш тавы сыкрата да куя,
Кайвакытта тиеп тәңкәгә:
Менгән чакта йөгең артка сөйри,
Төшкән чакта төртә җилкәңә.

Ә табигать тавы рәхимлерәк:
Әгәр калсаң анда адашып,
Авазыңны ерак яңгырата,
Кемдер килеп таба җан атып.

Тормыш тавы алдый. Син белмисең
Менгән мәлдә нәрсә буласын.
Хыянәтчел: кайчак упкынына
Баш-аягың белән чумасың.

Минем әле, шөкер, егылган юк,
Үтеп барыш тормыш тавыннан.
Чөнки монда нәсел-шәҗәрәмнең
Мин таймаслык юлы салынган.

## *Сагыш*

Ах, бу сагыш!..
Туганнарым, дуслар иртә китте,
Якын зыялылар тормыштан.
Чәчәкле җәй тулы күңелемә
Сары көзләр килде сагыштан.

Беренче яр дәшә офыклардан —
Кулын изи кояш баештан.
Гомерем буе бардым, җиталмадым, —
Йөрәк гүя үзе сагыштан.

Бу жанымда шаулый туган якның
Юкәләре, җырлы камышлар.
Беркайчан да җирдә юк һәм булмас
Мине биләгәндәй сагышлар.

...Чир ул чиргә йокмый дию хактыр,
Мин сынадым аны язмышта.
Һәм миңа да хәзер сагыш йокмый —
Чөнки үзем тоташ сагыштан.

## Яшәү

Зәңгәр күктә җәелеп кояш көлә,
Җәй кочагы гүя ял йорты.
Кешеләргә гомер өстәү өчен
Сихәтле бал җыя бал корты.

Урманнарда кошлар симфониясе,
Кырда тургай нәсел ишәйтә.
Ак күгәрчен уйный һаваларда,
Яшәү өчен канат көчәйтә.

Океан-диңгезләрдә яшәү кайный,
Яшәү уты тауда, кыяда.
Һәр җан ак кояшка кулын сузган
Шушы җирдә һәрбер ояда...

Бар да яшәргә дип омтылганда,
Тудырганда аның чарасын,
Утлы корал, ракеталар төяп,
Ә син, Кешем, кая барасың?!

## Күңел сәяхәте

Туган як, туган туфраксыз
Яшәве җиңел түгел.
Ә шулай да...
Чегәннәрнең таборына
Иярде китте күңел.
Алда ирек, анда хөрлек,
Болыннар һәм сулыклар.
Иксез-чиксез карурманнар,
Мавыктыргыч офыклар.
Кысып торган кануннарга
Газиз башны имисең.
Кимсетелү, җәберләнү,
Тарлыкларны күрмисең.
Иң мөһиме, бу тормышның
Иң азат баласы син:
Тирә-якта тургай җыры,
Күктә — кояш, җирдә — мин!..
Менә бермәл туйды күңел
Чегәннәр таборыннан.

Аңлады ерагайганын
Туган җир кадереннән.
Азатлык рәхәт! Тик һаман
Күңел сагышка батты.
Кире әйләнеп кайтты ул:
Үз халкына, туфрагына
Каны һәм җаны тартты.

## *Капма-каршы*

Тиледер мин. Игелек итү өчен
Талпынды да торды бу күңел.
Әмма арт ягын да күрсәтте ул —
Игелек кылу җиңел эш түгел.
Малай чакта күрше Габделхәй дус,
Каты авырып,
Алма теләп яткан бер көндә,
Ахун картның бакчасына кереп
Алма чәлеп бирдем ак төндә.
Мин икәнен белеп, Ахун бабай
Күлмәк якасыннан алды да,
Кәҗә бәтиедәй сөйрәп килеп,
Зәһәр кычыткanga салды да.
Балигъ булдым... Казан. Трамвайда
Карак кисте кеше кесәсен.
Кулын тоттым. Шуның өчен кинәт
Хәнҗәр ярды кәчтүм җиңсәсен...
Бу кылганнар, бәлки, вак-төяктер,
Нигездә бит алар игелек!
Тормыш өчен шундый вак-төякләр
Әзерләде мине иң элек.
Ә тормыш ул — чуар. Кемсәләр күп.
Шактыйлары атты таш белән.
Оныттылар алларына күпме
Савыт куйганымны аш белән.
Дөньяга да янар гөлләр иктем,
Ә чәчемне сукты кыравы.
Шат җиһанны үлеп яратсам да,
Иңнәремдә һаман сынавы...
Кайчак уйлыйм: әгәр шулай барса,
Этлеккә бит калам күмелеп.
Йөрәк куша:
Игелеккә дөрләт мине, җирдә
Иманнан да өстен Игелек!

## Бәхәс

Күңел кинәт әрнеп ярсыды да,
Охшап калып калай әтәчкә,
Сулъяк иңемдәге фәрештә белән
Кереп алдым кайнар бәхәскә.
Син нәрсә, дим, ялгыш абынсам да,
Гөнаһ итеп язып куясың.
Кемдер аркасында абындым ич,
Кеше языгын миңа җыясың?
Түрәләре пычрак кулы белән
Казна кесәсенә тыгыла,
Күреп, дәшми калсам, гөнаһ диеп,
Минем дәфтәремә языла.
Алар урлыйлар бит! Ә мин түгел!
Тик бары
Күрмәмешкә генә салышам.
Юк, изге җан, хаксыз кыланасың,
Болай барса,
Бугазыңа инде ябышам!..
Фәрештәнең һич тә исе китми,
Минем белән сүздә алышта.
Ак эт бәласе, ди, кара эткә,
Шулай түгелмени тормышта?!
...Заман капкасыннан карап торам,
Мәхшәр күзле адәм баласын.
Фәрештәне сатып алган заман,
Ничек кешене сатып алмасын.

## Бүрек белән түфлә

*(Шаяру катыш)*

Бүрек белән түфлә очраштылар,
Бер-берсенең хәлен сораштылар.
— Бигрәк ялтырыйсың, — диде бүрек, —
Исем китеп тора сине күреп.

— Ялтырыйм шул! — диде аңа түфлә, —
Хуҗам минем бик бай — чөнки түрә!
Куштаннары сөртеп кенә тора,
Ялагайлар исә ришвәт бирә.

Кая йөгерә идең әле бая,
Ике колакчының синең кая?

— Ә минеке ярлы,— диде бүрек,—
Эчеп, баш төзәтеп көнен күрә.
Колакчыннар? Аларны мин сатып,
Бурычын түләп кайтып киләм менә.

## Кайсы җан ничек

Әхмәдинең эте ияртеп кайтты
Ятим көчек — артык кашыкны.
Ә аларга хуҗа кеше зуррак
Оя ясау өчен ашыкты.

Эт көчеккә ояның түрен бирде,
И ялады битен, борынын.
Салкын төннәр килсә ачты аңа
Үзенең кайнар җылы куенын.

...Бала тудыру йорты.
Тәүге тавыш бирә
Нәфис затның йөрәк парәсе.
Бер яшь ана калдырды да китте
Шушы йортта
Яңа тапкан газиз баласын.

## Хәрәкәттә бәрәкәт

Җир әйләнә...
Шуңа күрә әйтәдер ул гавам
Хәрәкәттә, диеп, бәрәкәт.
Туктамасын гына бу хәрәкәт,
Ясамасын кеше һәлакәт.

Кай галимнәр бүген оран сала
Киләчәктә яшәү хакында:
Халык саны үрчи, диләр алар,
Җир туйдыра алмас барсын да.

Хакимнәргә гүя тик шул кирәк,
Бу фаразны итеп коралы,
Сугыш уены уйнап гомер кыя
Кара канга батырып дөньяны.

Борчылмагыз галим, хаким затлар,
Сезнең фикер, ахры, мүкләнгән.
Җир җанлы ул! Аның үз хисабы,
Анда һәр нәрсә дә үлчәнгән.

Кирәк булса артуны да тыяр,
Кирәк кадәр бирер ризыгын.
Туганнарга кирәгенчә генә
Сызып куяр яшәү сызыгын.

Җир әйләнә. Мәңге әйләнсен ул!
Хәрәкәттә, диләр, бәрәкәт.
Кабынмасын гына җиһан сугышы,
Килмәсен лә соңгы һәлакәт.

## *Онытмагыз*

Күкрәп, яшьнәп яңгыр болыты килсә,
Оеп кала бөтен басу-кыр.
Туган якта күкләр күкрәве дә,
Яшен яшьнәве дә үзе җыр.

Туган җир ул китаплардан гына,
Әкиятләрдән генә түгел лә,
Сабый чактан ана сөте белән
Кереп кала һәрбер күңелгә.

Исеңдәме минем балачагым,
И Урайның йомшак җилләре!
Гомерем салкыннары читтә булса,
Монда калды җылы көннәре.

Шул көннәрдә бераз яшим, диеп
Кайттым менә, зифа талларым!
Ах, кая соң сездә керәшәләр,
Инешемнең текә ярлары?

Кыекларга кунмый карлыгачлар,
Сыерчыклар кайтмый ояга,
Сукаланган хәтфә болыннар да.—
Кемнәр шулай мәрхәмәтсез булган
Малай чагым калган дөньяга?

## Могҗиза идең

Һаваларда нурлар,
Нурга коена урман,
Үләннәре билдән киң алан.
Хуш исләрен сулап чәчәкләрнең
Каерып-каерып печән мин чабам.

Кинәт пәйда булдың. Ах, син нинди
Күзне алалмаслык сөйкемле,
Бар чәчәкнең матурлыгын җыйган
Гүзәллекнең үзе шикелле!

Горур гына яннан үтеп киттең,
Бер алдыңа төштем, артыңа.
Тәүге күрүдә үк тезләндергән
Утлы мәхәббәтем хакына.

Күтәрелеп хәтта карамыйсың,
Җиләк сайлавыңны беләсең:
Елмаюлы чигенү...
Ихлас хисләремнең
Ялкыннары өтте, күрәсең.

Һаваларда нурлар,
Иңдә синең куллар,
Хисләремә Ул, дим, Ул риза!..
...Еллар аша безне яшәртә күк
Искә төшеп шушы могҗиза.

## Чорлар алышынганда

Җирдә ыгы-зыгы, шау-шу бара —
Яңа чорга күчү заманы.
Һәр яңа чор үзенә искене дә
Ала, тудырганда яңаны.

Узган меңьеллыкның күкрәгенә
Кылыч тотып басса кешелек,
Монысына әнә кереп бара
Ракеталарына төренеп.

Һәрбер чорның була үз мәсләге,
Үзенең рухы, әхлак, әдәбе.
Кайчак кеше үзе аңлый алмый
Чор әхлаксызлыгы сәбәбен.

...Ни булмасын, һәр чор — яңалык ул!
Дәверләрне алып эченә,
Иркен адымында таяна да
Кешеләрнең тиңсез көченә, —

Алгарышка таба атлап бара
Вакыт белән ярышып бу җирдә.
Гамәлләре ошый, ошамыймы,
Аны туктаталмый беркем дә.

Һәрбер чорның була үз тавышы,
Һәрбер чорның була үз моңы.
Һәрбер чорның армас йөрәгеннән
Алгы көнгә яңгырый үз җыры,
Җырлый аны гавам, ил кыры...

...Син дә
Нинди генә язмыш кичерсәң дә,
Киләчәктә яшә, и җырым!

## *Буран моңы*

Тыныч идем. Тагын тәрәзәмдә
Моңлы итеп улый бураннар.
Бар җирдә моң! Гүя моң эчендә
Йөзеп йөри төнге урамнар.

Буранланып кердең тормышыма
Тезләндерә торган наз булып...
Хәзер, белмим, кайда, кемнәр өчен
Көләсеңдер ялган яз булып.

Ә урамда бүген кабат буран,
Ах, моңсу ла аның тавышы.
Яхшы беләм: буран булып кайтып,
Тәрәзәмә бәрә сагышың.

## Зәхмәт

*(Шаяру)*

Өйләнеп җибәрде Фәрит,
Кыз менә дигән иде.
Гаиләне алып барырга
Бар яктан килгән иде.
Дөнья шундый: юк хәсрәтне
Эзләтә дә таптыра.
Бер-береңне йә хатыннан,
Йә үзеңнән «чактыра».
Алар да шулай булдылар,
Бозылды тормышлары.
Сүрәнләнә барды көннәр,
Хисләрнең агышлары.
Ничә китеп, ничә кайтты,
Юк, тарта өйгә күңел.
Әйтерсең лә шул чәчбисез
Яшәве мөмкин түгел.
Әйттеләр: — Нишләп йөрисең,
Кимсетеп ир-ат затын?
Тот та өйлән башкага,
Беткәнме сиңа хатын?
— Аңламыйсыз,— диде Фәрит,—
Шулаен шулай да, тик...
Ул зәхмәт хатын түгелдер,
Гүя ул бер наркотик.

## Рәхмәтле булыйк

Бу дөньяга нигә тудым, диләр,
Уфтаналар...
Мин дә тудым. Болай ярады,
Тумасам, дөньяны күрмәс идем,
Күпне белде гомерем дәвамы.
Иң мөһиме, Яктылыкны күрдем,
Яшәешнең таҗын — Кояшны,
Ямьле Җирне. Алар җылысында
Гамәлләргә җиктем бу башны.
Матурлыкны күрдем. Матурларның
Кылганнарын кыю батырлык.

Матурлыктан башка кешеләр юк,
Кешеләрдән башка Матурлык.
Гүзәллекнең бер тукымасы кеше
Галәм хәтле чиксез галәмдә...
Белдем бик күп затлы, зыялыны
Һәм очрадым затсыз адәмгә.
Кешелекне күрдем, шәфкатьлене,
Миһербанлыларны, гамьсезне.
Саф йөрәкне, изге күңеллене,
Мәкерлене, шактый мәнсезне.
Шау чәчәкле язлар каршыладым,
Катнашылды
Ил-халыкка кирәк эшләрдә.
Мәхәббәтнең үзе нәрсә тора!
Нигә яшерергә,
Аны тәтедем зәңгәр кичләрдә...
Туу, яшәү җирдә зур бәхет ул,
Нигә уфтанырга ди аңа.
Галәм-Җирнең сөйгән уртасы без,
Рәхмәтле булыйк дөньяга.

## Ничек аңларга

Бу күзләрең мине эзләп тапты,
Бу иреннәр мине үптеләр.
Шушы күзләр, шул ук иреннәрең
Яшьлегемнән мәхрүм иттеләр.

Бу кулларың, хисеңә мана-мана,
Йөздерделәр татлы дулкында.
Аннан күпме төшереп, күпме алды
Тормыш төбендәге упкыннан.

Бу йөрәгең ялкынына урап,
Ничә үтереп, ничә терелтте.
Иреннәрең кабат үптеләр дә,
Берни булмагандай үз иттең.

Бу сынавың нигә кирәк булды?
Дөнья мине изде болай да...
Хатын-кызны ничек аңларга соң? —
Моңа җавап бары Ходайда.

## *Ачык хат*

Шигырьдә күк, юк эзләмим сине
Офыклардан, томан, таулардан.
Тавышыңның да көтмим ишетелүен
Урман арты — әллә кайлардан.
Юксынулар аша әйткән чакта,
Мин үзеңне синең көтәмен.
Көтү хисе татлы бер сагыш ул —
Ләззәтләнеп сагыш сүтәмен.
Шаулап үсә безнең бөдрә каен,
Төпләрендә синең эзләр бар.
Ул эзләрне саклап кадерләүче
Минем кебек, белмим, кемнәр бар.
Бер мин генә сагынмыймдыр сине,
Сагыналар инеш таллары.
Син киткәннән бирле алар моңсу,
Талларның да бар бит җаннары.
Сагыналар сине суын эчкән,
Җырлап аккан көмеш чишмәләр.
Алар җырлавыннан туктар иде,
Әгәр син оныткан, дисәләр.
Минем дә юк шөбһәм онытуыңа,
Фәрхат белән Ширин шикелле
Арадагы уртак яратулар
Безне тоташ бер җан иттерде.
Үпкәләрең ташла уйнак җилгә,
Мәхәббәттә юктыр кирәге...
Сине көн дә каударланып көтә
Миндә калган ярты йөрәгең.

## *Тылсымлы*

И рәхмәтлемен, язмышым:
Карады күзләремә!
Карады да, басып киттем
Ялкынлы эзләренә.

Ул бара да борылып карый,
Ихтыярсыз мин барам.
Әллә йөрәге кояшмы —
Нурыннан дөрләп янам.

Нур җелегемне эретеп,
Ләззәт бирә җаныма.
О, Күкләр! Нинди сөюне
Салдыгыз сез каныма!

Нинди утлар өстәдегез
Дулаган хисләремә...
Ялкынлы сукмак китерде
Ятаклы кичләренә.

Ә тормыш кырыс хөкемдар,
Кайнап тора казаны.
Шундый тәмуг казанында
Мәхәббәтнең азаны!

## *Төштә генә*

Кичә генә ак төшемә кердең —
Чәчләремнән сыйпап яраттың.
Юксынуның үзәк өзүләрен
Иркәләвең белән тараттың.

Мин яшәдем сихри бер дөньяда —
Ул яз иле, утлы наз иле!
Анда Сөю, анда ләззәти көч,
Тагын әллә ниләр бар иде.

Каурый болыт йөртеп канатында
Кабат безне җиргә төшерде.
Сак белән Сок төсле икебезне
Таһир белән Зөһрә иттерде.

Бу дөньяның киңлегендә гүя
Тик без иң бәхетле икәнбез...
Уяндым да...
Тормыш баскычының салкынында
Юксынуым белән икәү без.

## Халәт

Күктә давыл,
Урамнарда буран,
Ә күңелдә якты — гел аяз.
Тышта буран котырынган чакта
Йөрәк түрләрендә нинди яз?

Күкрәгемә сыймас төсле булып
Ургый, ташый гына кайнар хис.
Хисләрнең соң нинди яшеннәре?
Табигатьтә әле кышлар ич.

Күктә давыл,
Урамнарда буран,
Халәтемдә язлар ни өчен?..
И аппагым!
Яшьлегебез кайтып китте бугай
Без боеккан айлы бу кичен.

## Идеал

О, идеал дигән тарту көче —
Кешеләрнең өмете, яшәве!
Тик никтер ул, аңа барган саен,
Офыкларга чигенә, каһәре.
Үзе тарта, үзе ераклаша,
Мавыктыргыч утлар шикелле.
Ул бу җирдә күпме ихлас җанны
Үзенең фанатлары иттерде.
Без дә фанат идек. Ничә еллар
«Якты киләчәк» дип котырдык.
Матур ялган икәнен дә белдек,
Ләкин һаман аңа омтылдык.
Чөнки өмет — идеалыбыз иде,
Ялган булуындамыни эш.
Идеал булса, авыр юл да җиңел,
Өмет булса, татлы ул тормыш.
Хәзер әнә ансыз гына калдык,
Елар чакта, килә көләсе.
Ил чайкала, йөзә кай яккадыр,
Гүя Нух пәйгамбәр көймәсе.

Бүгенге көн белән яши бар да,
Иртәгене — шайтан, кем белә.
Идеалсыз, рухсыз мал куганы
Илгә бөҗәк төсле сибелә...
Заманалар алышынып тора,
Һәрберсендә төрле уй, хыял.
Әмма кешедә Чын Кешечә яшәү! —
Менә нәрсә булсын идеал.

## *Тартылу*

Тартылалар күкнең җисемнәре,
Галәм төзек, галәм түгәрәк.
Шушы төзеклекнең чылбырында
Түгәрәк Җир йөри тәгәрәп.

Ул да үзенә тарта балаларын,
Сибеп-коеп очмый Җир-ана.
Галәмнең бу физик тарту көчен
Мин үземчә тоям дөньяда:

Тарта мине бөтен матурлыклар,
Кече күңеллелек, игелек...
Игелек итү күбрәк булган саен,
Шәфкатьлерәк була кешелек.

Тарта язда ал чәчәкләр шавы,
Ләйсән яңгыр, күкләр күкрәве.
Сары диңгез төсле тук башаклар
Үскән басу-кырлар күкрәге.

Тартып тора саф йөрәкле җаннар,
Мәрхәмәтле, изге хисләләр.
Соңгы бәхетен кешегә өләшүче
Чын иманның үзе төсләләр...

Тартылалар күкнең җисемнәре,
Галәм төзек, галәм түгәрәк.
Кешеләр дә шулай тартылсыннар
Һәм бер-берсенә
Өйсен иде шатлык күбәләп!

## Нәрсә әйтим

*(Җыр)*

Күңелеңне кайчак тыңлап кара,
Сизәсеңме, салкыная ара.
Талкый булса кирәк сине миннән
Җылы сүзләр көткән хаксыз яраң.

Язның чәчәкле таҗ кигән чагы,
Йөрәгемдә тынмас хисләр давы.
Син дә минем шундый бер таҗым бит, —
Нәрсә әйтим сиңа шуннан ары.

Мин дә көтәм синнән кайнар сүзләр,
Күзләреңә төбәлгәннәр күзләр.
Син янар хис, мәхәббәтем хөкемдары, —
Шуннан артык нәрсә әйтим тагы.

## Утлы мизгелләрдә

*Мөхәммәт Мәһдиевне уйлаганда*

Кемнәр генә килми бу дөньяга,
Кемнәр генә китеп бармыйдыр.
Киткәннәрне йә дөньясы алдый,
Йә аларны үлем алдыйдыр.

Аждаһадай йота гына тора
Дусларымны шомлы зиратлар.
Үз кадерен белмәүчеләр кала,
Кадерлеләр сүнә чиратлап.

Чәчәк күзләрендә көмеш чыклар,
Бәлки, чыклар алар яшедер.
Үлемнең дә берәр сере бардыр —
Бәлки, үлгәч кеше яшидер?

Галәм гел мәңгелек булган кебек,
Бәлки, мәңгелектер кеше дә...
Шуңадыр ул Күкләр киткәннәрне
Оныттырмый — искә төшерә.

## Кәсепчеләр

Дөнья матур, дөнья көлеп тора,
Кояш җиргә нурын сибеп тора,
Кәсепчеләр тулы илнең көне
Алар кәсебенә эленеп тора.

Мәскәү яктан капчык-капчык әйбер
Базарларга ташый кәсепчеләр.
Ул әйберне биш-ун бәясенә
Сатып ала эшле-хәерчеләр.

Завод-фабрикасы бөлеп тора,
Үзенә эшче куллар көтеп тора.
Кәсепчеләр анда барамы соң! —
Хәрам акча килмәгәнен белеп тора.

Арзан рекламада халык артистлары
«Зәңгәр экран»нардан көлеп тора.
Алары да әллә кәсепчеме?
Юк, фәкыйрьләр! Акча эшли —
күренеп тора.

Дөнья матур, дөнья көлеп тора,
Бу тамаша бәгыремне өтеп тора.

## Кирәклеләр китә

*Илдар Юзеев*
*вафатыннан соң*

Китә кеше... Җаның сызлап кала,
Язмышка без бик зур үпкәдә.
Ни аяныч, кирәклеләр китә,
Алар кирәк, ахры, Күктә дә.

Пәйгамбәрдәй затлы җаннар сүнә,
Ачынудан йөзләр саргая.
Әллә инде Тәңре тирәсендә
Пәйгамбәрләреме азая.

Иртә сүнә шагыйрь, әдипләре,
Намус, вөҗданлысы сыкрап.
Шундый исәненең үкчәсенә
Заман басып килә җан сорап.

Кала бирә вәхши, миһербансыз —
Тормаганы хәтта чүпкә дә.
Андый кавем кирәк түгелдер ул
Җирдә генә түгел, Күккә дә...

Китә кеше... Яхшылары китә,
Гүя йөрәк тамырын актарып.
Кирәкленең гомерен озайт, Аллам,
Сүнгәч, булмый Аны кайтарып.

## Төрек каешлары

*(Экспромт)*

Һай, бу төрек каешлары —
Чалбарның дәрәҗәсе!
Ләкин шактый кимсетә ул
Татарның шәҗәрәсен.
...Бабайлар мал асыраган,
Караганнар атын да.
Күн-каеш эзләп бармаган
Мәмләкәтләр катына.
Тиресен дә иләгәннәр,
Теккәннәр кәвеш-читек.
Шуның белән көн күргәннәр
Җирдә бер дигән итеп.
Ясаган каешлары да
Алып торган күз явын...
Бүген каеш эзләп йөрим —
Бу нәрсә бу, Ходаем?!
Айкап чыгам базарларны,
Күн-каешлар читнеке.
Аптырыйм: ил хәтле илдә
Кая соң, дим, безнеке?
Ни гаҗәп: маллар азайган,
Кыдырылган атлар да.
Шуңадыр күн мал артыннан
Барабыздыр ятларга.
...Һай, бу чит ил каешлары —
Чалбарның дәрәҗәсе!
Рәнҗидер Ил, Бабайларның
Тарихи шәҗәрәсе.

## Заман киңлегендә

Менә бу киңлек, ичмасам!
Күренеп тора бар да:
Кешеләр ярлыга, байга
Бүленеп ята анда.

Әниле ятимнәр тулган
Тормыш урамына.
Ач-ялангач кереп бара
Дөнья буранына.

Кулын сузган карчык тора
Чатта, туңып-өшеп.
Заман сыны булып баскан
Тарихтан ул төшеп.

Шаулый базар, гөрли базар,
Гөрли алыпсатар.
Алдау кәсебе үзләштерә
Монда «яңа татар».

Бер-берсенең җанын кыя —
Кемнәр кемгә үчле.
Әкиятләрдән күчеп килгән
Аждаһалар төсле...

Бу киңлектә, көзгедә күк,
Бар да күренеп тора.
Кояш күктә, ярым борылып,
Йөзен чытып тора.

## Ыруг

Шәҗәрәмнең агачыннан
Сорау бирә бабам:
Нәселеңдә ничә бабаң,
Беләсеңме, балам?
Син туган нигездә алар
Тормыш итеп киткән.
Сиңа көч биргән кырларда
Күпме иген иккән,
Илен ашлы иткән.

Шәҗәрәңне белү өчен
Бик күп зиһен китми.
Нәселенә илтифатсыз —
Үзен хөрмәт итми,
Динен хөрмәт итми,
Җирен хөрмәт итми!..
Җавап бирә алмадым мин,
Өйрәнмәгән — нишлим?!
Тарих буйлап
Урыс кенәзләрен беләм,
Бабамнарны белмим.
Хәтта патша, юлбашчылар
Өйрәтелгән: истә!
Минә ыруым затлары
Соралмаган һич тә.
Шундый барлык ырулардан
Тора бит ул милләт!
Мәгарифтә аңламаган
Шуны күпме имгәк.

## Башкала

*Казанның*
*1000 еллыгына*

И Казаным! Янар яшьлегемә
Зур капкасын ачкан Башкала!
Милләт өчен бөтен игелекле эш
Кайнар йөрәгеңнән башлана.
...Даның күмү өчен, чал тарихта
Килде сиңа Иван*, чехлар да.
Яралардан телгәләнеп беткән
Күкрәгеңне тотты тупларга.
Көл-күмердән чыктың күтәрелеп,
Каһәр, ләгънәт орып Иванга.
Халкың сине чорлар аша нурлы,
Пайтәхетле итте җиһанда.
Бүген менә матур уйлар килә:
Кирәк очкыч, «кара алтын»ы.
Ят тарафта илсез-җирсез йөргән
Милләттәшкә күңелең ялкыны.

* Иван — Иван Грозный.

Иман, әхлак, рухи азык эзләп
Ашыга сиңа Хода бәндәсе,
И дөньяның татар өммәтенә
Иң кадерле, изге Мәккәсе!
Үсәсең син күккә,
Үсәсең син киңлекләргә —
Урман, сулар, кырлар ягына.
Кешеләрнең хезмәт тулы, таза,
Көләч тормышлары хакына.
И Казаным! Янар яшьлегемә
Туры юл күрсәткән Башкала!
Милләтемнең имин киләчәге
Шанлы гамәлеңнән башлана.

## Бәйрәм

*(Шаяру катыш)*

Чирмеш Иван дус бар иде
Мари авылында.
Утырырга туры килде
Бик еш табынында.
Бу якта халык кунакчыл,
Хет көн саен әйлән.
Мәҗүсилек гадәтенчә
Атна саен бәйрәм:
Яфрак коелу бәйрәме,
Бәйрәм — беренче кар.
Табигатьтә күп күренешнең
Үзенең бәйрәме бар…
Иван дустым белән икәү
«Җиффәрәбез» генә.
Алдыбызда күз яшедәй
Көмешкәсе көлә.
Ай буена салмыш йөрим,
Иван — еллар буе.
Чөнки авылда гөр итә
Бәйрәмнәрнең «туе».
Җитәр, дидем, бервакытны
(Мине көчсез димә!),
Туктаттым бу сәрхушлекне,
Яшисе бит кинә!

Ә ул һәрбер бәйрәм саен
Дәвам итте шулай.
Һәр кеше дә гомер сөрә
Үзенә ничек кулай.
Тәңре акыл шәрифләрен
Кемгә күпме язган...
Иван күптән ахирәттә,
Ә мин җырлар язам.

## Бурыч

Тормыш булгач, сүз юк,
бер-берсеннән
Кеше ала-бирә бурычны.
Ләкин менә нәрсә өчен икән
Без гел илебезгә бурычлы?

Киң кырларда тозлы тир түгәбез,
Ватан өчен икмәк игәбез.
Юк-бар эш хакыннан күпме салым,
Ул яшәсен диеп бирәбез.

Яклыйбыз да аны, саклыйбыз да,
Эретәбез тимер-корычны...
Амбарына безнең байлык тулган,
Ә без һаман аңа бурычлы.

«Ил алдында бурычыңны үтә!» —
Шушы иске җырны яңартып,
Яши кеше бар тапканын бүлешеп,
Казна кесәләрен кабартып...

Җилләр миңа нигә усал карый,
Ошамыймы фикер сөрешем?
Бүген менә илгә соңгы «бурыч» —
Үлем белән түләп килешем.

# Ак болытларга карап

Публицистика

## *Ак болытларга карап...*

Чалгы яный чишмәлектә,
Кем булсын — әткәй җаным...
Әнкәй судан кайтып килә,
Талир тәңкәсен тагып.

Чалт аяз күктә бөдрәләнеп йөзгән ак болытларны күрсәм, иң беренче чиратта әткәй белән әнкәй исемә килеп төшә. Изге җаннар ак болытка әйләнә, диләр ич! Кеше өчен әтисе белән әнисеннән изгерәк кем бар?!

Уйларымда балачак, яшьлек елларыма кире кайтып, хатирәләргә чумсам, әткәй белән әнкәй күз алдымнан китми.

Безнең яшьлек нидән башланды?
Ирләр утка киткән дәвердән.
Ятимнәргә назлы җылы биргән
Әнкәемнең мамык шәленнән.
Бәлкем, башлангандыр әткәй булып
Колхоз кырын сөргән таңнардан.
Унҗидедә чишмә буйларында
Сөю бүләк иткән язлардан.

*(«Безнең яшьлек*
*нидән башланды?»)*

Туган авылым Яншыкка кайтсам, беренче чиратта зиратка ашыгам. Анда — җиде буын бабамның, кардәшләремнең каберләре. Шулар өстендәге яшел үләннәрне, чәчәкләрне сыйпап, серләшеп алсам, борчуларым таралып китә. Үзем дә мәңгелеккә шушы зират куенына күчәрмен — каберем шунда булыр. Ташына язарга инде шигырем дә әзер:

Килер бер көн:
Зиратка килеп керсәң, әй, якташым!
Туктап кал да укып кара
Кабер ташын!
Туган җирне сагынып кайтып,
Тән иңдерер
Саф күңелле, шагыйрь җанлы
Авылдашың.





Мансур Шиһаповның әнисе Нәфисә (сулда) һәм әтисе Әхмәт (уңда) Шиһаповлар



Энесе Миннәхмәт Шиһапов. 1949



Бертуган Шиһаповлар — алда уңнан — Рәшит, Мансур, Миннәхмәт, артта — Хуҗаәхмәт, Равил. 1945

Туган авыл... Күпме хатирәләр бәйле аның белән, күпме җырларым аңа багышланган! Күңелдә кайнаган хисләрне шигырь язып дөньяга чыгару әмәлен дә авылда таптым. Сара апа Садыйкованың киңәшен тотып, Яншыктагы күпер астында су агышын, җилләр сөйләшкәнне тыңлап, тулган айны күзәтеп төн кичкән заманнан башлап миннән хисләр шигырь шәкелендә чыга.

Җил белән серләшкән каеннар,
Яңарта яшьлегем хисләрен.
Шомыртлар ак шәлен ябынса,
Сагынам авылым кичләрен.
Сагынам, сагынам өзелеп,
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

*(«Яшьлегем эзләре»)*

Хатирәләр, хатирәләр... Ярый әле, кеше күңелендә хатирәләр яши. Туган як, әти-әни, дус-кардәшләр турындагы истәлекләр һәрчак йөрәк түрендә. Аларның кайберләре хәтергә шуның кадәр уелып кала ки, дистәләгән еллар узып китсә дә, ул хәлләр төссезләнми, тоныкланмый, кичә генә булгандай, өр-яңа көе күңелдә саклана.

Безнең әткәй, сугыш кырларын айкап, яралар алып өйгә кайткан иде. Шул җәрәхәтләре аны якты дөньядан алып киттеләр. Шигъриятемдә сугыш тематикасына зур урын бирүемә әлеге хәл төп сәбәп булып тора.

Мәңгелек ут сөйли,
Сүзсез сөйли тарих ялкыны:
Исән калды микән,
Дөрләп янды микән
Ап-ак шәлен япкан яу кызы?

*(«Мәңгелек ут»)*

Әткәй үлгәч, җиде бала белән әнкәй берүзе хәерчелек, ачлык, ялангачлык чорналышында калды, һәрберебезгә тормыш дигән мәшәкатьле диңгезгә бик иртә чумарга туры килде. Шул ерак елларның кайбер хатирәләре кабат-кабат искә төшә. Менә шуларның берсе.

Ун яшьләремдә булганмындыр. Әнкәй мине, бер йомарлам акмай салынган төенчек тоттырып, Балык Бистәсе базарына җибәрде. Шуны сатып, акчасын әнигә кайтарып бирергә тиешле идем. Ә аның үз исәбе: май саткан акча белән налогны каплап булмасмы! Әнкәйнең шундый зур эшне ышанып тапшыруына горурланып, эчке бер шатлык белән җәйге юлдан атлыйм. Юл читендәге бил тиңентен булып үскән үләннәргә кулымдагы таяк белән ара-тирә селтәнгәләп, тизтиз барам. Онытылып китеп, кулны артыграк болгап җи-

бәрдемме, әллә майның эсседә йомшаруы җиткән идеме — ни булса да булды — йомарлам маем төенчектән шап итеп тузанлы юлга килеп төште. Кулыма алганда, аңа калын катлам булып туфрак ябышкан иде. Чарасызлыктан гаҗиз калдым. Инде нишләргә? Кире борылып кайтыргамы, әллә юлны дәвам итәргәме? Өметсез — шайтан, диләр бит. Бәлки, майны шушы килеш алучы да булыр иде әле, кем белә. Кара төскә кергән йомарламны кире төенчеккә салып, алга атладым.

Базарга килеп җиткәндә, андагы халык кызып-кызып сату-алу итә иде инде. Сәүдә рәтенең бер чатынарак басып, мин дә үземнең сатып алучымны көтә башладым. Җир төсендәге маема сәерсенеп карап китүчеләр хәтсез булды, әмма шуларның берсе дә бәя сорап тукталмады, мин зарыгып көткән «алам» дигән сүзне әйтмәде. Бервакыт базар тарала да башлады. Сатучылар да, сатып алучылар да кайсы кая китеп югалдылар. Миңа да китәргә вакыт иде. Ләкин әни алдына нинди йөз белән кайтып керергә кирәк?! Мин моны күз алдына китерә дә, уйлый да, үземне акларлык сүзләр дә таба алмый идем. Шул минутларда бөтен Җир шарында миндәгедәй зур хәсрәтле берәү дә юк кебек тоелды. Базар капкасына сөялеп, үтеп-сүтеп йөрүче кешеләрне күзәтә-күзәтә, аларның үземнекедәй зур кайгылары булмауга кызыгып, озак утырдым. Утырган саен бер фикерем ныгый барды: бу көенчә авылга кайтырга ярамый. Хурлык. Нәфисә малае җебеп, маен сата алмыйча кайткан, әнисен налог түләр акчасыннан мәхрүм иткән, дип сөйләрләр инде. Шул мизгелне ерагайтасым килеп, өйгә кайтмаска булдым. Ул хәерчелек заманында нәни башымда нинди планнар кайнагандыр инде, хәзер анык кына хәтерләмим. Бары үлгән әтине сагынып, елап-елап алганым гына исемдә. Утырган урынымнан мин кичкә кадәр кузгалмадым. Әлеге хәлемне күреп, авылдашлардан берәрсе әнигә кайтып әйткәнме, озак торуыма борчылып, ул үзе юлга чыкканмы — нәрсә булса да булган — базардан мине әни килеп алды. Өлкәнрәк абыйларымнан берәрсен җибәрә дә алган булыр иде ул, әлбәттә. Йорт башының, шуның өстенә әле тол хатынның фәлән чакрымдагы Балык Бистәсенә җәяүләп килеп йөрмәсә дә эше муеннан. Әмма гарьчел табигатемне белгәнгә, минем хәлемә кереп, сабый иңнәремә төшкән зур хәсрәтемне бергәләп күтәрергә дип, үзе килгән иде әни.

Яшәү көче биргән әнкәм,
Җан җылысын өрә-өрә,
Ак күлмәктән, ак чәчәктән
Пакь җан булып төшкә керә.

*(«Бәхилләшмим —*
*саубуллашам...»)*

Әле хәзер дә ак болытларга карасам, әткәй, әнкәй белән бәйле хатирәләр күңелгә килә. Изге җаннар ак болытларга әйләнә, диләр шул!

Ак болытлар. Туган як һавасы. Туган туфрак. Туган җир. Якыннарым, туганнарым. Шулар миңа яшәү көче бирүчеләр, иҗатка илһамландыручылар. Туган җиргә, туган туфракка меңнәрчә җепләр белән берегеп үскән кеше авыл турында җырламыйча булдыра алмый. Чөнки аның тамырлары шунда.

Ямьле авыл таңын,
Каеннарның шавын,
Май кояшы нурын юксынам.
Мин кырларга гашыйк,
Авылым сагынам шашып,
Туган җирсез яшәү юк сыман.

*(«Туган җирсез яшәү юк сыман»)*

*1998*

## Барыбер сагынам

«Татарстан яшьләре» газетасының 11 гыйнвар санында якташым Миңнегөл Нәҗмиеваның «Хәзер авыл сагынырлык түгел, Мансур абый» дигән мәкаләсен укыгач уйлана калдым әле.

Беренчедән, якташымнан хат алу бик сөендерде. Ни дисәң дә, туган яктан хәбәр бит. Ул миңа ачык хат язган. Зөфәр Хәйретдинов көенә җырлана торган «Сагыныр өчен» дигән җырымны тыңлагач язган. Анда «Авылдан киттем, авылны шашып сагыныр өчен» дигән юллар бар. Ни хәл итмәк кирәк, Миңнегөл якташ, ничек кенә булмасын, туган як сагындыра ул. Сезнеке кебек минем дә балачак баллы прәннек ашап үтмәде. Унике яшьтән ат көттем, хезмәт өчен бер тиен акча алмадым. Бер мин генәмени соң? Безнең авылда Нәҗип абый дигән кеше бар иде. Аның җиде баласы. Болар колхозда җидәүләп эшлиләр. Елына сигезәр йөз хезмәт көне чыга боларның. Шул хезмәт көннәренә ипи дә, акча да түләмиләр иде. Әмма ләкин ел йомгакларында сәхнәдә кукраеп басып торуларын, хезмәтләре белән горурлануларын күрсәң аларның!

Син менә, Миңнегөл туган: «Колхоз бер центнер икмәкне 160 сумга, фураж онын 250 шәр сумнан сатып бирә. Печәнен дә колхоздан сатып алабыз. Аның өстенә газ өчен түлисе бар», — дип зарланасың. Ә без соң? Арык җилкәләрдә ерак урманнан сыртка салып кайткан чыбык-чабыкны

сөйләмим дә инде. Бервакытны шулай Шәмгъсумов абый, колхоз рәисе, сыерларга дип чүп үләне җыеп кайтып килгәндә тотып алды. Капчыгымны ертып ташлады, үлән-печәнемне арбасына бушаттырды. Икенче юлы, башак җыйганда тотып алып, районга ук алып китте. Ләкин болар берсе дә минем күңелне катырмады, һаман да әле авылдашлар белән бергәләшеп тир түгеп бушка эшләгән елларны сагынам.

Үсә төшкәч, тәгәрмәчле тракторда сезнең авылның Элдерт Миннәхмәте белән тракторчы ярдәмчесе булып эшләгән идем. Шул тәгәрмәчле трактор белән күпме җирләр сукаладык. Сука бетүгә, носилкалар алып, теге сез әйткән карьердан таш ташыдык. Йөрү өчен бик тә уңайсыз дигән шул таш юлны без салганбыздыр инде аны. Сабантуй үтүгә, бер ай буена олыбыз-кечебез Кама аръягына печән чабарга чыгып китә торган идек. Аннан кайтып төшүгә, урак башлана. Безнең әниләр урак белән көненә 25 әр сутый урак ура торганнар иде. Урак бетүгә, ындыр табагындагы ашлыкны чабагач белән сугарга керешәбез. Ноябрьгә кадәр шулай.

Авылның мәшәкатьле эшләрен мин җилкәмдә татыган кеше. Чөнки бит авылдан чыгып киткәндә миңа инде 17 яшь иде. Чыгып китү кадәресенең дә үз хикәяте бар. Белемгә — укырга ашкыну. Укырга кереп кайтканнан соң да әле паспорт ала алмыйча йөрелде. Казан белән авыл арасын дүрт тапкыр җәяүләп үттем мин паспорт артыннан йөргәндә. Ник дисәң, яңгыр астында кайта-кайта «укырга керде» дип, шәмәхә мөһер сугылган кәгаземдә, кара җәелеп, язуларын укып булмаслык хәлгә килгән иде. Казанны «алганчы»га кадәр әле без Олы Солтан мәктәбенә 20 чакрым җәяү йөреп укыдык. Әни мәрхүмә атна саен бер стакан ярма, бер ипи, ярты чиләк бәрәңге биреп җибәрә торган иде. Йомшак ипине барган көнне ук ашап бетерә язабыз да атнаның калган көннәрен ачлы-туклы үткәрәбез. Ләкин уку дәрте зур иде. Тырыштык, укыдык. Без дә җиде бала идек бит. Әти сугыштан ярым исән кайткан кеше. Шул Әхмәт малае булуым белән бик тә горурланам бит мин, Миңнегөл якташ.

Тормыш дигәнең анысы беркайда да җиңел түгел икән. Әле күптән түгел фин татарлары янында булып кайттым. Мул тормышта яшәү өчен көненә дүрт кенә сәгать йоклыйбыз, диләр алар. Шулай шул, муллык көн-төн эшләсәң генә була. Шәһәр кешесенең дә хәлен чамалап карыйк. Иң тыйнак ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шәһәр кешесе иртәнге җидедән кичке җидегә кадәр эштә йөри. Шәһәр транспортында көн дә изелә, аңа карап суыткычлары муллыктан тулып тормый. Базарга барып, ул, тиеннәрен саный-саный, шул сез үстергән бәрәңгене, кишерне сатып ала. Бик сирәк кенә каймак алырга йөрәксенә. Чамалап кына итен ала. Ярый,

болары авыл ризыгы, сыйфаты шикләндерми. Ә сез менә шәһәр урамының газдан куерган һавасын иснәп бер генә килеп китәсез, авылга кайтканда башыгыз әйләнә. Безнең кран суыннан кайнаган чәйне, «абау, суыгыз тәмсез» дип, күбегез эчми дә әле. Әйе, шул пычрак суны фильтрлап, хлор белән чистартып кына краннарга җибәргән эчәр суның тәнгә сихәте юк. Тук тормышлы кешенең дә шунлыктан кәефе начар, исәнлеге чамалы. Хәер, боларын газеталардан укып, үзегез дә беләсез.

Сез әйткәнчә, җәйге ялларны авылга кайтып үткәрүләр, Шынгый буйларын әйләнүләр, елгада балык тотулар бик тәтеми шул. Шуңа күрә авылны гел сагынам.

Мин авылның моңлы кошы идем,
Кунып сайрар таллар тапмадым.
Чит җирләрдә буш аланга басып,
Туган якны сагынып сайрадым.

Әкренләп тормыш рәтләнә бит, Миңнегөл якташ. Хәзер әнә авылда электр яна, газы кергән. Иншалла, әйбәт юллар да булыр.

*2000*

## Кадерлеләр генә хәтердә

Бәлки, үзләре кеше хәтерен хаклый белгәннәр кадерле ул, дип әйтсәм, дөрес булырдыр. Гариф Ахунов минем өчен гаять тә кадерле кеше иде. Нәкъ менә кеше хакын хаклаганы, кеше кадерен белгәне өчен хәтердә ул минем. Шәһидә апа: «Мансур энем, Гариф абыең сине бик ярата иде. Аның турындагы истәлекләр китабында истәлегең белән катнашсаң, Гариф абыеңның рухы шат булыр иде», — дип әйткәч, сөенеп куйдым. Кем кем турында, әмма Гариф абый турында истәлекләр дә, әйтер сүзләр дә, ямьле хатирәләр дә бетәсе түгел.

Иң беренче очрашуым моннан утыз еллар элек булды. Мин ул вакытта СССР Язучылар берлегенең Татарстан бүлеге каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшли идем. Пропагандалау булгач, язучылардан иҗат төркемнәре төзеп, районнарга, халык белән очрашуларга чыга торган идек. Андый очрашуларда Гариф Ахунов бик еш катнаша иде. Башта ул Әлмәттән килеп йөрде. Аннары, «Казан утлары»нда эшли башлагач, язучылар партоешмасының секретаре итеп тә сайладылар аны. Иҗат төркемнәре белән



Гариф Ахунов Мансур Шиһаповны 60 яшьлек юбилее белән котлый

йөреп кайтканнан соң, мин, Гариф Ахунов янына кереп, авыл халкының тормышы, язучыларның хәле хакында сөйләшеп утыра торган идем.

Шушы сөйләшеп утырулар, очрашулар бервакытны бигрәк тә эшлекле төс алды. Гариф Ахуновның нефтьчеләр тормышыннан алып язылган «Хәзинә», «Хуҗалар» романнарын халык бик ярата. Мин инде бу вакытта Күчмә театрга директор итеп билгеләнгән идем. Катлаулы юллар үтеп, Күчмә театрга Драма һәм комедия театры дигән статус бирдерүгә дә ирешкән идек. Сөйләшеп утыруларның берсендә мин Гариф Ахуновка аның «Хәзинә» романы буенча спектакль куяр өчен сценарий язарга теләгем барлыгын әйттем. «Әй, энем, «каты чикләвек» булып чыкты ул «Хәзинә». Романы шәбен шәп тә бит, сценарий өчен баш бирми әле ул. Юмагулов та язып карады (ул елларда Г.Камал исемендәге театрда Башкорстаннан килеп ирле-хатынлы Юмагуловлар эшләп киткән иде). Аяз дустым да алынып карады (Аяз Гыйләҗевне ул Аяз дустым дип йөртә торган иде). Ошатмадым мин ул сценарийларны», — диде. Мин алай да сценарийны үзем аңлаганча эшләдем дә Гариф абыйга күрсәттем. Бик игътибар белән укып чыкты. Аннары болай диде: «Бу бит бик зур әсәр. Син шуның умыртка сөяген тапкансың.

Барлык эшче каһарманнарны бер учак тирәсенә, чишмә буена җыйгансың. Чишмәсе — «Туй күлмәге» җыры».

Мин «Хәзинә» романы буенча сценарийны өч вариантта язып карадым. Язган бер вариантны Гариф абыйга күрсәтә барам. Ул аларны ипләп кенә, үзалдына сыза-боза, төзәтә. Мин ул язмаларны алып китеп тагын эшлим. «Булды бу, Мансур!» — дигәнче эшләдем. «Кошның да үз оясы була» дигән исем белән спектакль премьерасы уйналды. Күчмә театрның үз бинасы юк иде бит әле. Әлеге спектакль премьерасы өчен Г. Камал театры бинасын алуга ирештек. Гариф абыйның беренче рәттә дулкынланып, сөенеп Мөнәвәрә-Ләлә Миңнуллина уенын яратып карап утыруларын хәтерлим әле. Аннары әлеге спектакльне Свердловскида уздырылган конкурска да алып бардык. «Сәхнәдә эшчеләр темасы» дигән конкурс иде ул. Диплом алып кайттык.

Гариф Ахуновка үзенең чәчмә әсәрен җанландырып сәхнәдә күрү, артистлар белән аралашу кызык иде. Аның җор тел белән, мәгънәле итеп сөйләшүе, шаяртулары артистларның күңелен күтәрә иде. Гариф Ахунов өчен бернинди вактөяк булмый торган иде. Әйтик, «Кошның да үз оясы була» дигән спектакльдәге «Туй күлмәге» җырының көен кемнән яздыру кадәресе белән дә ул бик кызыксынып торды. Аның киңәше белән җырны композитор Мәсгут Имашевтан яздырттык. Әлеге пьесаны Гариф абый соңыннан улы Рәшиттән урысчага да тәрҗемә иттерде әле.

Дөнья булгач, кеше дигәнең төрле көтелмәгән хәлләрдә кала. Тәкъдир минем белән дә усал уеннар уйнады. Елдан артык суд тикшерүләре барды. Миңа карата 29 томлык эш ачылды. Шактый гына гаепләүләр тупланган иде анда. Ниһаять, суд. Шушы судка мин җитәкләгән сиксән кешелек коллективтан килеп, гадел сүз әйтүче, дөреслекнең күзенә караучы табылмады. Бердәнбер кеше — Гариф абый — республиканың гына түгел, ул вакыттагы Советлар Союзының абруйлы кешесе, юк вакытын бар итеп судка килде. Гариф Ахунов ул вакытта төрле бүләкләр иясе, СССР Югары Советы депутаты, Язучылар берлеге рәисе иде. Гариф абыйны күргәч, судья аңа сорау бирде:

— Сез кем буласыз?

— Язучы Гариф Ахунов мин.

— Андый язучыны белмим.

— Язучы Гариф Ахуновны да белмәгәч, энем (судьяга ул энем дип эндәште), син нишләп судья булып торасың да, татарның Мансур Шиһапов кебек булдыклы улларына хөкем чыгарып утырасың?

Шунда суд башланды. Театрдан килгән бер егет белән кыз (исемнәрен әйтеп тормыйм), «Кошның да үз оясы була»

дигән спектакльнең сценариен без яздык, дип баралар. Шунда Гариф абый дипломатыннан сценарийның мин язган, үзе сызгалап-бозгалап бетергән вариантларын тартып чыгарды да: «Менә моны күрәсезме?! Без бу сценарийны Мансур Шиһапов белән икәү яздык. Хәрефләре очып-очып киткән язу Шиһаповныкы булыр», — диде.

Судья әйтә: «Минем янга ике метрдан якынрак килергә ярамый, артка чигенегез», — ди. Гариф абый исә үзенекен куәтли: «Энем, син еррактан укый алмыйсың, шуңа күрә якын килдем», — ди. Судья текстны алмакчы була, Гариф абый исә: «Энем, мин бу язуларны әле Мәскәүгә дә алып барам», — дип, кулындагы кәгазьләрне киредән дипломатына салып куя. Шул арада миңа да дәрт өстәргә ара таба. Янәсе, кайгырма, бер сине генә түгел, Шолоховны да плагиатлыкта гаепләп маташканнар.

Судта ул әле тагын ике сәгатькә якын сөйләде. Аның бөтен сөйләгәненнән әнә шул мине Шолохов белән тиңләве хәтеремдә уелып калган. Ул миңа яшәү дәрте өстәде. Аннары Гариф Ахунов минем хәлне белергә дә гел килеп йөрде. Бер ул гына түгел, Мөхәммәт Мәһдиев тә, артистлар Равил Шәрәфиев, Вафирә Гыйззәтуллина, Габдулла Рәхимкулов, Сафьян Ибраһимов та киләләр иде. Очрашуга рәсми рөхсәт алу өчен, бу килүләрне тоткыннарга мәдәни хезмәт күрсәтү итеп рәсмиләштерә торганнар иде. Тоткыннар Гариф абыйны гаять тә яраттылар. Чөнки ул алар белән иң беренче очрашуда ук сүзне: «Сезгә «иптәшләр» диярге ярамый, диделәр миңа. Ләкин мин сезгә барыбер «иптәшләр» дип әйтермен, иптәш булмый сез кем буласыз ди тагын?» — дип башлады.

Мин унике елны дүрт елда тутырып кайттым. Кайтуга ук төрле яктан әйбәт-әйбәт эш урыннары тәкъдим итә башладылар. Шиһапов булдыра ул, дигән исемем, яхшы даным эшлекле даирәләрдә таралып өлгергән, күрәсең. Монда да Гариф Ахуновның кулы уйнамады микән? Гариф абый тәкъдиме белән мине Ринат Мөхәммәдиев Язучылар берлеге рәисе урынбасары итеп эшкә кабул итте. Шул сәбәпле Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев белән бәйләнешләрем тагын да ныгыды, теге еллардагы кебек итеп халык арасына чыгып, очрашулар үткәрүләрне кабаттан тергезеп җибәрдек. Иң беренче очрашуларның берсе Балык Бистәсе районының Балыклы Чүкәй авылында булган иде. Шунда баргач, Гариф абыйның өйдән өйгә кереп минем якташларымның аш-суны тәмле әзерләүләренә, чисталык-пөхтәлек ратуларына сокланып йөргәнен хәтерлим. 1995 елның маенда туган авылым Яншыкка да бергә кайттык әле без. Клубка җыелган халыкның мине алкышлавына сөенеп, ул болай дигән иде:

«Менә шулай, Мансур энем, чит илдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул» дигән мәкаль бар. Күрәмсең, син үз илеңдә дә солтан». Аннары авылның мәчетенә кереп чыктык, чишмә буена төштек. Сиреньнәр чәчәк аткан вакыт иде. «Синең җырларың шушы чишмә буенда язылганнар инде, җыр чишмәсенең серләрен син менә шушында ачкансыңдыр», — дип, һәр нәрсәгә сокланып, хозурланып йөргән иде ул. Аннары сентябрь аенда республика халкы Гариф Ахуновның 70 яшьлеген зурлап бәйрәм итте. Үз бәйрәмен бөтен кеше өчен дә күңелле итә белә иде ул. Г.Камал исемендәге Академия театрында аны зурларга җыелган халыкның һәрберсенә ул үз исеме язылган ручкалар, блокнотлар тараткан иде. Туган авылы Өчилегә кайтып, Шәһидә апа белән парлашып җигүле атка утырып әйләнгәннәр иде. Болар хәзер бөтенесе хатирә генә булып калды.

*2000*

## Еллар аша дәшәм

Якташым Кадыйр Сибгатуллин турында уйлана башладыммы, хәтердә аның шигырь юллары яңара:

Кама буйларыннан эзлим сине,
Дулкын өсләрендә күләгәң.
Мәхәббәтне юк диюче булса,
Андый кеше сине күрмәгән.

Кадыйр шигърияткә шаулап-гөрләп керде, дип әйтү дөресме икән, әллә кистереп кенә ул беренче шигырьләреннән үк үзен шагыйрь итеп танытты, дисәк хаклы булырбызмы? Мин, нечкә хисле кеше буларак, Кадыйр Сибгатуллинның мәхәббәт лирикасын күңелдә йөртәм инде. Ә менә минем остазым һәм дустым Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев Кадыйр Сибгатуллин иҗатында публицистиканы хөрмәт итә иде. Минем архивымда Кадыйрның «Чит илдән хат» дигән шигыре саклана. «К.Сибгатуллин миңа моны почта аша салган иде. Мин бу шигырьләрне ничә еллар буе очрашуларда сәхнәдә укып йөрдем. М.Мәһдиев. 20. 06. 1994». Мин үзем шигырь язылган кәгазь битен М.Мәһдиевтән 1995 елның 29 маенда кабул итеп алдым. Ягъни Мөхәммәт ага үләренә бик аз гына вакыт калган арада.

Очрашуларда халыкка әйтер сүзе һәрвакыт булган олуг язучының ни өчен Кадыйр Сибгатуллин шигырен укып йөрүен аңларга тырышыйк әле. Шул максаттан әлеге шигырьне тулаем китерәм.

Әллә нигә күңелем борчулы,
Авыллар тынычмы, иминме?
Гомерем үтте инде, Габдулла,
Күрергә тилмереп илемне.

Кайтам дип канат та
Кагындым,
Борылдым вокзалга җиткәндә.
Туган як каргышы төшкәндер,
Ял итеп читләргә киткәндә.

Зур итеп күчтәнәч салгансың,
Дару күк тотабыз каз итен.
Көненә өчәр кат кулга алам
Коштеле төрелгән гәзитен.

Үзең бер кунакка килеп кит,
Монда да була тук яшәргә.
Тик менә ямансу, бик моңсу,
Кеше юк безнеңчә дәшәргә.

Балалар телләрен онытты,
Без дәшсәк аңламый көләләр...
...Күп гомер калмады, Габдулла,
Монда да каядыр күмәрләр...

Авылның зираты ни хәлдә?
Терлектән таптата күрмәгез.
Картайган көнемдә кайталсам,
Мине дә кәфенләп күмәрсез.

Әйе, җәсәден минем киңәш буенча туган авылы зиратына куйдырткан Мөхәммәт Мәһдиев бу шигырьне укый-укый татар язмышын гына түгел, үз язмышын да уйлагандыр. Без бит барыбыз да авыл балалары. Кадыйр Сибгатуллин белән мин Балык Бистәсеннән. Мин — Яңшыктан, Кадыйр безнең колхозга керә торган бәләкәй генә Укмас авылыннан. Атаклы шагыйрь Укмасый туган авылдан. Алар авылы безнекенә ике генә чакрым. Укмас балалары дүрт классны тәмам итүгә, җидееллык белем алу өчен, Яңшыкка киләләр. Укмаска үзем дә бара идем. Тау итәгендәге җыйнак кына, 30 — 40 морҗалы авыл. Кадыйрның әтисе сугышта үлгән иде, әнисеннән дә яшьли ятим калды. Аны сыендырган абыйсы колхоз парторгы. Ә минем абый мәктәп директоры. Шулай итеп, аның Вахит абыйсы белән минем Хуҗиәхмәт абый «Жданов» колхозының йөген бергәләп тарталар. Чөнки парторг Вахит абыйның белем ягы чамалы, шуңа күрә бөтен документны минем Хуҗиәхмәт абый тутыра.

Шулай да Вахит абыйлар йортында китап күп, газета-

журнал да алдыралар. Чөнки җиңгәсе укытучы. Ул заманнардагы авыл мәктәпләрендә белемгә сусаган кешеләр эшли иде. Ә болар барысы да Казанда — Кабан буендагы педучилищеда укып кайткан кешеләр. Кадыйр Яншык мәктәбендә җиде классны укыды. Укыганда бер ягы белән дә аерылып тормады кебек. Хәтта ки концертларда, спорт түгәрәкләрендә дә катнашып йөрми торган, гел күләгәдә калырга тырыша торган боек бала иде. Мин Кадыйрның шигырь язганын да белмим. Ә без инде Яншыкта укыганда ук район газетасына шигырьләр җибәрә торган идек.

Урта мәктәптә укырга дип Олы Солтанга киттек. Иртәнтүк Балыклы Чүкәй авылында тирә-як авылларның бала-чагасы җыела. Иске Арыштан Роберт Әхмәтҗанов белән Давыт Котыпов, Укмастан Кадыйр Сибгатуллин килә. Җыйнаулашып Олы Солтанга китәбез. Олы Солтан мәктәбендә Равил Шәрәфиев тә, Хәлим Җәләлов та, Мидхәт Миншин белән Вакыйф Нуруллиннар да укыды. Бу кешеләрне санавым ул замандагы әдәби рухны тоемларга да ярдәм итәдер. Без барыбыз да шагыйрь идек. Шигырь язмаганнарыбыз башкалар язганнарны сәхнәләрдән укый. Мин үзем дә 1957 елда, оста шигырь сөйләп, Казанга кадәр уздым. Ул вакытта да Кадыйрның теге яки бу яктан аерылып торганы сизелмәде. Чү! Бер яктан аерылып торган икән...

Олы Солтаннан атнага бер тапкыр авылларыбызга таралышабыз. Атналык ризык алып килергә бит инде. Егерме чакрым араны җәяүләп кайтабыз да, үләбез дигән җирдән, калган аш ашап терелеп китеп, клубка чыгабыз. Безнең авыл клубына кадәр Кадыйрга тагын өч чакрым үтеп киләсе бит әле. Ул шуны үтә. Безнең авылның бер чибәр кызын әләктереп алган бит. Шул кыз — Ләлә белән мин дә бергә уйнап үстем. Әле уртак яр сөюебез турында шигырем дә бар.

Нәкъ шул чишмә буйларында,
Без кызлар сагаладык.
Бөрнәки очы сылуы —
Йөрәкне телгәләдең дә,
Гомерлеккә яр булалмый,
Күңелне яраладың.

Менә шушы минем дә күңелне яралаган кыз Кадыйрның аруларын оныттыра иде. Кадыйр яратса бик нык ярата торган иде. Аннары ул минем классташыма — Ырга авылы кызына өйләнде.

Унны бетергәч, Кадыйр район газетасына эшкә урнашты. Менә шул чагында аның шагыйрьлеген ишетә башладык. Минем авылдагы абый әйтә торган иде: «Укып кара, наным, Кадыйр зур шагыйрь бит». Шулай булып чыкты

да. Ә мин ул вакытта Татарстан Язучылар берлегенең пропаганда бүлегендә эшли идем. Казан университетының журналистика факультетына читтән торып укырга да кердем. Шул елларда Кадыйр минем янга ешлады. Без анда Кадыйр, Мөсәгыйт Хәбибуллин белән бергәләп озаклап сөйләшеп утыра торган идек.

Кадыйр шигырьләрен безгә укытып кына карый да Хәсән Туфан янына йөгерә. Килгән-килгән, Мөхәммәт Мәһдиев белән дә күрешеп китә. Язучылар арасында, Кадыйр китап чыгарырга җыена, дигән сүзләр таралды. Китап чыкты. Шул китабы белән ул Язучылар берлегенә кабул ителде. Мәхмүт Хөсәен белән Рәисә Ишморатларны дистәләгән китаплары белән дә кабул итми йөргән еллар иде бит бу.

Пропаганда бүлегендә эшләгәндә, Балык Бистәсенә мин язучыларны еш алып кайттым. Кадыйрның анда булуы миңа таяныч иде. Һәрвакыт әйбәтләп каршы ала. Район газетасында кунакка килгән язучыларны матур итеп пропагандалый. Аннары, мин инде Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшләгәндә (Кадыйр Чаллыда яши башлагач), аның үзен Балык Бистәсенә кунак итеп дәшә торган идем.

Кадыйр Чаллыда яшәсә дә, элекке дусларын гел сагынды. Үләренә дүрт көн кала ул минем китабыма бәяләмә язып китергән иде. Ул беркайда да басылмады. Әлеге язмасында ул мин югарыда әйтеп киткән безнең яшьлек елларына да туктала.

«Нишләтәсең, безнең буынның балачагы да, яшьлеге дә бик шартлы гына булды. Бу сүзләрне авыз тутырып әйтергә дә уңайсызрак. Шуңадыр, үзеңә тулаем кичерергә насыйп булмагач, ничек кенә сәер булмасын, ул әле алдадыр сыман». Игътибар итегез, үләренә бер атналап вакыт кала яза бит ул бу сүзләрне! Ләкин ни хәл итәсең? Шул ук мәкаләдәге тагы бер өзекне китерәм: «Әгәр кешенең үз язмышы үз кулында гына булса, «язмыш» дигән сүз гомумән булмас иде. Йөртә ул язмыш, кайчакларда синнән сорап тормый, гомереңне дә, җаныңны да туздырып ата. Чыда гына». Ни бу? Алдан тоемлау, үлем сулышын сизүме, әллә философлыкмы?

Менә шулай. Кадыйр дустым белән мин еллар аша ул язып калдырган мәкалә ярдәмендә сөйләшәм. Гомеренең соңгы көне дә хәтердә. Татарстан язучыларының корылтаена килгәч, мин аны әйбәт кунакханәгә урнаштырган идем. Инде киткәндә кунакханә ишегеннән чыгып бер сүз дә әйтми генә автобуска кереп утырды. Юлда да дәшмәгән. Дәшәрлек хәле булмаган. Дәшкән булса иде, ярдәм сораса иде, бәлки, мин бүген үкенечле сүзләрне язмас идем.

*2002*

## *Казан кичләре*

Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсеннән өченче кабат тын гына, моң гына җыр агыла:

Ак булып, саф булып истә калсын
Казанның кадерле кичләре.

Өченче кабат инде театр залы халкыбызның яраткан композиторы, җырчысы, Татарстанның атказанган артисткасы Сара Садыйкованың иҗат кичәсенә багышланган концертка килүче халыкны сыйдыра алмый.

Ә яңа җыр алкышларга күмелеп дәвам итә:

Иделгә сузылган айлы юлдан
Тын гына, моң гына җыр ага.
Сагынырбыз, дуслар, бу кичләрне
Чәчләргә чал кергән чорда да.

Әйтерсең лә өлкән буын әдибебез Хәсән Туфан, бу сүзләрне язганда, нәкъ менә залга моң чишмәсе булып агылган көйнең авторы композитор Сара ханымның үзен күз алдында тоткан. Әйтерсең лә бу моң белән композитор биш яшеннән кулына тальян алып, халык авызыннан үз аһәңе, үз моңы белән йөрәгеннән эшкәртеп, үзенчәлекле итеп кырык биш ел буе көйгә салган татар кызының бәхетле иҗат гомерен чагылдырган.

Менә шуңа да тамашачылар композиторның үзен дә, «Казан кичләре» дип аталган бу яңа җырны башкаручы РСФСРның халык артисты Фәхри Насретдиновны да озакка сузылган алкышларга күмәләр.

Сара Садыйкованың иҗат гомере дә, карап баксаң, җырга тиң. «Яшьтән музыкага булган мәхәббәтем Мәскәү консерваториясенә алып килде»,— ди ул. Тиздән ул Мәскәүдә ачылган Татар опера студиясе студенткасы була. Ниһаять, 1939 елны студия тәмамлана. Композитор Нәҗип Җиһановның «Качкын» исемле операсы сәхнәгә куела. Сара Садыйкова бу операда Рәйханә ролен башкара. Янып торган күз карашлы, матур тавышлы, сәләтле артистка ул вакытта ук сәнгать белгечләре тарафыннан югары бәя ала. Аның үзендә дә көйләр иҗат итү сәләте туа. Нәтиҗәдә дистәләгән әсәр барлыкка килә. Алар арасында «Актаныш таңнары», «Солдатым» (М.Ногман сүзләре), «Беренче мәхәббәт» (Ә.Рәшитов сүзләре), «Кайтыгыз, торналар» (И.Ганиева сүзләре) кебек халык күңеленең түрендә урнашып калган җырлар күп. Республикабызның Опера һәм балет театры С.Садыйкованың «Мәхәббәт җыры», «Кияүләр» (Хәй Вахит либрет-

толары) музыкаль әсәрләрен сәхнәгә куйды. Татар дәүләт академия театрында куелган «Күк капусы ачылса» (Х.Вахит пьесасы), Татар дәүләт күчмә театрындагы «Бөркетләр кыяга оялый» (И.Юзеев пьесасы) спектакльләренә дә музыка Сара ханым Садыйкова тарафыннан иҗат ителде.

Кичәне алып баручы нәфис сүз остасы, Татарстанның атказанган артисты Ф.Юсуповның шаяртуы хаклы. «Сара ханымның көйләрен сузсак, Арчадан Актанышка кадәр булыр иде, ә сузасы тагын да күп, йомгагы кулында», — ди ул. Кичәдә «сузыласы йомгак» — киләчәк иҗат планнары белән Сара ханым Садыйкова үзе чыгыш ясый. Әлбәттә, композиторга гашыйк тамашачы, язылганына һәм язылачагына рәхмәт йөзеннән, залны алкышларга күмә.

Республикабызның сәнгать осталары Ф.Насретдинов, А.Аббасов, И.Шакиров, Ф.Тимерова, Р.Билалова, Х.Гыйниятова, Р.Нуриева, Н.Теркулова бик уңышлы чыгыш ясадылар. Композиторның үзе аккомпаниатор булуы кичәгә ямь өстәде. Композиторның Ә.Ерикәй сүзләренә язган «Язгы сулар акканда» дигән җыры әйтерсең Рәисә Билалова тавышына махсус язылган. Зал артистканы кат-кат сәхнәгә чакырды. Кичәдә «Әйләнеп кайталар» (Х.Туфан сүзләре), «Ачуланма» (Ә.Баян сүзләре) кебек композиторның яңа җырларын Татарстанның халык артисты И.Шакиров башкарды.

Акрын гына пәрдә төшә. Композитор Сара Садыйкованың иҗат кичәсе тамашачыларның озакка сузылган кул чабулары белән тәмамлана. Йөрәккә кергән җыр моң булып халык йөрәгендә яши, халык күңелендә дәвам итә.

Ак гөлләр сибегез безнең юлга,
Иделнең иртәнге җилләре.
Гомергә, мәңгегә истә калсын
Казанның кадерле кичләре.

*1974*

## Без дә чаң сукмасак

Һәр оешма үзенчә тыныч кына иҗат итә, мактана, шапырына, чөнки хәзер сөйләгән буш сүзләр өчен беркем алдында да җавап бирәсе юк. Замана шундый, рәхәт замана.

Кинәт җөмһүриятебез тынлыгын бозып, былтыр газеталарда Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевкә «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе хезмәткәрләренең «Ачык хат»ы басылды. Хаттан күренгәнчә, коллектив өчкә бүленгән икән. Шөкер, Президентыбыз ашыгыч чаралар кулланып ташламады, һәрвакыттагыча, салкын кан бе-

лән тирән фикер йөртеп, мәсьәләне өйрәнү белән мәшгуль булды.

Без, әдәбият-сәнгать әһелләре дә, бу җәһәттән фикерләребезне әйтергә тиеш. Без дә чаң сукмасак, кем сугар? Ләкин чаң сугуның асылын аңлаган кешеләр булсын иде. Шул очракта гына Президентыбыз безнең тавышка колак салыр, ә без, үз чиратыбызда, алтын урталыкны табуга өлеш кертербез. Юкса соңгы вакытта популизм белән шөгыльләнүче, һәр мәсьәләне «остазлардан да оста белүче» зыялылар күбәйде. Муса Җәлил исемен йөрткән Опера һәм балет театрының исеме җисеменә туры килмәве турында сүз гел куерып тора. Катлаулы бу театрның механизмын белми торып, андагы серле сәнгатьнең нигезен өйрәнмичә, шул өлкәдә һөнәр иясе булмыйча, өстән-өстән генә фикер йөртү эшнең нәтиҗәсен үзгәртми.

Сүз кузгалгач, әйтим инде. Опера һәм балет театрында бер түбә астында биш татар театрындагы кадәр коллектив — опера, балет, хор, оркестр, техник состав эшләде. Минем кырык еллык иҗат дәверендә, башка театрларда директорлар еш алышынган бер заманда, Опера һәм балет театрында бары тик ике директор: М.Ф.Боголюбов — 25 ел һәм Р.С.Мөхәммәтҗанов 15 ел эшли. Практика күрсәткәнчә, бу юлы да югарыдагы җитәкчеләр ашыгыч кына нәтиҗә ясаудан баш тарталар һәм дөрес итәләр дә.

Татарстан туфрагы талантларга бай. Әгәр дә без Аллага табынган кебек опера җырчысының талантына табынабыз, аны күкләргә чөябез икән, әйдәгез, объектив булыйк: артистка Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты дигән мактаулы исемнәр алуда ярдәм иткән театр коллективын һәм коллективны җитәкләгән директорын да ихтирам итик. Директорларны бер югары уку йорты да әзерләми, ул да адәм баласы, Татарстан туфрагы биргән талант. Укучыда фикер туар: ат дагалаганда, бака ботын кыстыра дигәндәй, бу Шиһапов ни өчен театр дөньясы белән женләнә, диярләр. Моның сәбәбе — иҗат коллективларында туган үзара тарткалашу чире. Бу чир Опера һәм балет театрында инде ничә еллар буе бара. Аның республикабызның башка коллективларына да йогу ихтималы бар.

Безнең көннәр идеологиясе — капиталистик мөнәсәбәтләргә күчү чоры идеологиясе — дингә нык таяна. Безнең дин — саф, пакь, чиста, иманлы, кешелекле дин. Шушы сыйфатлар яшь буынга мәчетләр аша бирелергә тиеш. Ләкин, пәри — башка, жен — башка дигәндәй, урак өстендә атнаның өч көнен «мунча кирәсе бар» дип, ә калган өч көнен «мунча кердем» дип, битен генә юган авыл малаен тәүлегенә биш

тапкыр тәһарәт алдырып, биш тапкыр намаз укыту бик авыр нәрсә. Минем күңел Корбан гаетендә мәчеткә баруны кабул итә, ә атнага бер була торган «Җомга көн кич белән» тапшыруының утыз минутының унысында тыңлатылган хәзрәт вәгазен кабул итә алмый. Бу вәгазь тапшыруны баетмый, читкә алып китә. Мода артыннан куып, дин әһелләре белән экраннарыбызны бизәү — зур гөнаһ, һәр изге эшнең урыны бар.

Казан телевидение тапшыруларының күпчелегендә хөкем сөргән идеясезлек, кыйбла булмау тапшырулар сериясен берсен башлау, икенчесен ташлау кебек күренешләрдән килә. Бу хакта Р.Ягъфәров та язып чыккан иде. (Ватаным Татарстан.— 1996.— 3 май.)

Телевидение һәм радио өлкәсендә җанны борчып, йөрәкне тырнап торучы тагын бер мәсьәлә — ул да булса дикторлар мәсьәләсе. Бүгенге дикторлар белән 60—70 нче еллардагы дикторларны чагыштырып карасак, җир белән күк аермасы. Элекке дикторларыбыз, бик җентекле, абруйлы конкурслар аша сайлап алынып, туктаусыз үз өсләрендә эшләп үсәләр иде. Ул еллардагы осталар актерлар әзерли торган вузларны тәмамлаган кешеләр иде. Телевидениедә — Айрат Арсланов, Абдулла Дубин, Иркә Сакаева, Әминә Сафиуллина, радиода Фатыйх Колбарисов, Фатыйх Шәрәфиев, Фоат Галимуллин кебек дикторларны искә төшереп үтү дә җитә.

Телевидение журналистына куелырга тиешле беренче иң төп таләп — сөйләм культурасы. Алик Зыятдиновның авыл хуҗалыгына багышланган тапшыруын карасам, минем ике көн йөрәгем авырта. Үзем авыл җиреннән чыккан кеше булганга шулайдыр инде ул. Чөнки мин авылның сыер койрыгы белән алай-болай селтәнгән фонында Алик биргән сорауларга «ие», «юк» дип җавап биреп торган хатын яисә комбайн ышыгына бастырылып, һәр сүзен көч-хәл белән генә этеп чыгаручы мужик кыяфәтендә генә күрсәтелүенә җаным-тәнем белән каршы. Ә бит Алик безгә күрсәткән шул хезмәт картиналары аша авыл кешесенең рухи байлыгы ачылырга тиеш. Дөресен әйтергә кирәк, бу тапшырулар сюжеты ягыннан да, техник эшләнеше ягыннан да, режиссура ягыннан да, тел-культура ягыннан да бернигә яраксыз. Россия телевидениесенең авыл хуҗалыгына багышланган тапшыруларын карап шаккатам мин: савымчысы булсын, механизаторы булсын, чатнатып сөйли. Әллә ниләр кырган кешеләр диярсең. Мич башында утырып, киез ката кигән аякларын берсе өстенә икенчесен атландырып, татуировкалы бармаклары белән гармунда көй чыгаручы, артык аек та булмаган бер мужиктан әллә нинди талант иясе, әллә нинди философ, әллә нинди шәхес ясый Мәскәү редактор-журналистлары, режиссерлары. Ә бездә бер сыер савучы эшләгән эше ту-

рында «ие инде» дип сөйли башласа, әллә нишләп кызарып утырасың. Авыл кешесе, татар авылы кешесе эшли белә, сөйли белми. Кем гаепле моңа? Бу хәлдә шул ук Алик Зыятдинов шикелле редактор-дикторларның да гаебе бар. Аликның бер сюжеты хәтердә калган: бер авылда шигырь язучы, шуларга үзе үк көйләр дә чыгаручы бер хатынны тапкан бу. Аның тормышы турында бераз сөйләгәч, мондыйрак реплика ишетәбез Зыятдинов авызыннан: «Көен җырлап бирә алмассың инде, хәтә бы шигырен булса да сөйләп бир инде». Менә сиңа «хәтә бы», менә сиңа авыл кешесен культура дөньясына тартырга тиешле кешенең сөйләме!

Алик Зыятдиновның сөйләм стиленә күчеп, минем дә: «Рәзе тәк мужны, рәзе тәк ярый», — дип сөйлисе килеп китте.

Күптән түгел экраннарыбызда Эльмира Вәлиева дигән диктор пәйда булды. Русчасын түгел, татарчасын да көч-хәл белән сөйли кебек тоелды ул миңа. Ул нинди конкурс нигезендә сайлап алынды икән дә аның эшен кемнәр күзәтә икән? «Башкалары булмагач, болары да ярап торыр», — дигән аклану кабул ителми. Юк икән, булдырырга кирәк ул кадрларны. Эзләргә, табарга, үстерергә кирәк. Элегрәк дикторлар белән махсус эшләүче кешеләр бар иде телевидениедә. Мәсәлән, РСФСРның атказанган артисты Гали Хөсәенов, бу оешмада баш редактор вазифасын үтәгәндә, дикторлар өчен дәресләр уздыра иде. Үзенә дә, кул астында эшләүчеләргә карата да таләпчән кеше иде ул. Бу җәһәттән миңа Диләрә Даутованың «Сөембикә»дә басылган язмасы бик гыйбрәтле тоелды. Бала чакта шигырьләр сөйләү белән мавыккан Диләрәне әтисе Әнәс Камал радиодан чыгыш ясатмакчы булган. Шунда редактор булып эшләүче Әдип Маликов, Әнәс Камалның якын дусты, Диләрәнең «һ» авазы урынына «х» әйтүен ошатмыйча, бәләкәй кызның шигырь сөйләвен эфирга чыгармаган. Менә ул эшкә җитди караш, менә ул таләпчәнлек!

Дикторлар мәсьәләсендә тагын бер аңлашылып бетми торган хәл: элек аерым бер диктор бары татар телендә генә сөйли иде. Хәзер исә бер үк диктор русча да, татарча да сөйләргә азаплана. Ике телне дә камил белгән, сүзләрне, авазларны дөрес әйтүчеләр юк бит. Шулай булгач, бу хәлне ничек тә үзгәртергә иде. Юк, хәзергә кадәр телевидение җитәкчелеге бу хәлгә күз салмый.

Татарстан телевидениесенең һәм аеруча татар телендә баручы тапшыруларның техник җәһәтеннән дә, фикер ягыннан да түбән сыйфатлы булуы хакында берничә сүз. Бу турыда күптән матбугатта, радио-телевидениедә зур сөйләшү ачарга вакыт. Югыйсә татар тапшыруларын карауга чит милләт вәкилләрен тартасы урынга, үзебезнең татарларны да өркетеп бетердек. Телевидение тапшырулары тиешле сәнгати

югарылыкта булсын өчен, тапшыруларны әзерләгәндә төп рольне белгечләр — режиссерлар уйнавы зарур. Яхшы режиссер булу өчен белем генә түгел, мөһим шартка җавап бирүче шәхесләр безнең телевидениедә юк дәрәҗәсендә. Әлеге өлкәдә төп урынны редакторлар тота. Ә редактор бит ул гап-гади журналист. Шуңа да карамастан бүгенге телевидениедә аның вазифалары баштан ашкан: ул режиссер да, монтажлаучы да, ул үзе әзерләгән тапшыруларны алып баручы да. Чын сәнгать турында биредә ничек сүз алып барырга мөмкин?

Бүгенге татар телевидениесенең бар җәһәттән дә аяныч хәлдә калуын бу өлкәдә эшләүчеләр үзләре дә яхшы күрәләр булса кирәк. Әмма ләкин, асыл сәбәпләрне ачасы урынга, алар, кемнәрнедер гаепләргә маташып, ачлык игълан итәләр. Шул акциягә катнашучы егерме кеше арасында телевидениенең элеккеге баш режиссеры Камил Зәйнуллин да бар иде. Бер генә сорау туа: баш режиссер урынын биләгәндә, чын сәнгать тудырырга аңа кем комачаулаган? Ачлык игълан итеп, ул нинди протест белдерә? Камилгә, әйтеп киткәнемчә, режиссер буларак үзен күрсәтергә мөмкинлек бирелгән иде. Әмма ул һәм идея, һәм техник, һәм режиссерлык осталыгы ягыннан чиле-пешле «Уятмакчы булсаң халык күңелләрен» исемле тапшыру оештырудан уза алмады.

Телевидениедә икенче бер җитди проблема — әдәбият һәм музыка бүлекләренең эше тиешле дәрәҗәдә булмау.

Заманында әдәбият бүлегендә, күңелләрне рәхәтләндереп, «Җомга көн кич белән» дигән тапшыру әзерләнә һәм экраннардан күрсәтелә башлады. Башлангычы матур һәм кызыклы иде. Әмма ничә ел элек булды инде бу хәл? Вакыт узган саен, һәр нәрсә үзгәрергә, сыйфат ягыннан яхшырырга тиешле. Ә бу тапшыру, һаман шул башлангыч шаблоннарны җиңеп, алга атлый алмый азаплана. Телевидение дикторы, тапшыруларны алып барганда, үзен иркен тотарга, гомумән, һәр сөйләүнең, һәр эш-хәрәкәтнең җаны булырга тиеш. Тамашачы аның үзе үк күтәргән проблема-мәсьәләләргә битарафлыгын, салкынлыгын һич кенә дә тоемларга тиеш түгел. Шулай булмаганда, тапшыру, үз максатына ирешәсе урынга, тискәре нәтиҗә бирәчәк.

Музыка бүлегендә дә җанны борчый торган күп кенә кимчелекләр бар. Биредәге кайбер шәхесләр, эш урыннары мөмкинлекләреннән файдаланып, бөтен көчләрен үзләрен пропагандалауга бирәләр. Мәсәлән, шушы бүлекнең мөдире Наилә Яхина үз өстенә әллә нинди зур талантлар да үти алмаслык вазифалар алган. Узган елгы Җиңү бәйрәменә багышланган концерт мисалында да күрергә була моны. Яхина үзе шушы концертның авторы да, алып баручысы да. Алай гына

түгел, Яхина әле җырлый да белә бит. Дөресен әйтергә кирәк, берәр мәҗлестә, дуслар табынында аныкы кебек тавыш белән җырлау күңелгә хуш килерлек. Әмма телевидениегә Венера Ганиевалар, Зилә Сөнгатуллиналар, Зәйнәп Фәрхетдиновалар белән беррәттән чыгарлык җырчымы соң Яхина? Чама белергә кирәк. Ләкин бу сүзләрнең авырлыгы аңа гына төшмәсен иде. Чөнки андыйлар тагын да бар.

Музыкаль бүлектә эшчәнлеге булган җырчыларыбыз, җырлау куәтләре чамалы булса да, экраннарыбызда бик еш күренәләр. Репертуарга килгәндә дә эшләр мактанырлык түгел. Хәзерге көндә радиода эшләүче авторитетлы художество советы турында телевидениедә бүген хыялланырга гына кала.

Телевидениедә эшләүчеләр бүген үз эшләренә шактый салкын карыйлар кебек. Концертлардан, кичәләрдән трансляцияләр ясаганда, теләсә нинди кыскартулар, өзүләр булгалый. Мәсәлән, минем Тинчурин исемендәге театрда уздырылган иҗат кичәм тамашачылар тарафыннан бик җылы кабул ителде. Ничек кирәк алай, урысча әйткәндә, «бездарно» кисүләр, кыскартулар аркасында бу кичәнең телевидениедән трансляциясе бернигә яраксыз килеп чыкты.

Мәкаләмнең ахырын үземә китереп терәгәч, әһә, Шиһапов шәхси үпкәсен эшкә җиккән, диючеләре бар. Ләкин бу җәһәттән үпкәле кешеләр, ихлас әйтәм, мин генә түгел.

Зурдан сүз кузгатуымның сәбәбен минем шәхестән түгел, һәр кич саен өйгә кунак кебек көтеп алган татарча телетапшыруларның сыйфатыннан эзләвегезне үтенәм. Үпкәләргә ашыкканчы, бер сабыр гына уйлашыйк әле. Берәү әйтмешли, без яшәдек инде, балалар бар бит.

*1997*

## Тәгәрмәчләр җыры[1]

Әле анда, әле монда буй калкыткан кылганнар, талгын җирнең риясыз иркенә буйсынып, битараф кына чайкалалар. Офыктан кызарып кояш чыгып килә; ул, тереклекнең бөек падишасы, әйтерсең иртәнге чыкларда коенган да сафланып, яшәреп киткән.

Мөхәммәт ага вагон тәрәзәсеннән иртәнге хозурлыкка сокланып бара. Мең кат күреп тә, күңелне, хыялны ялыктырмас гүзәллек булыр икән! Мондый чакта йоклап яту оят, валлаһи, оят!

---

[1] Бу очерк Әхмәт Рәшит белән бергә язылды.

Татар дәүләт драма һәм комедия театрының (элекке күчмә театр) баш режиссеры Равил Тумашев белән



Аның әтисе Әхмәткәрим абзый: «Иртән йоклаганның бәхете булмас, кояш белән бергә торырга кирәк», — дип әйтә торган иде. Бердәнбер арык ат белән җир erткалап көн күргән ярлы мужикларның бәхетләре булгандырмы, юктырмы, әмма Мөхәммәт ага күңелендә мондый мизгелләрдә сөенеч-шатлык ташып тора, башта берсеннән-берсе матуррак уйлар туа — җырлыйсы килә башлый.

Гастрольләр менә тагын артта калды. Республика күчмә театры артистларын Казакъстанның һәр каласында алкышлап каршыладылар, һәр спектакльдән соң аларны чәчәкләргә күмделәр, хәерле юл теләп, бәхет теләп озатып калдылар. Әйе, чит җирдә яшәүче туганнарыбыз Казан якларыннан килгән спектакльләрне, концертларны, китапларны зарыгып көтеп ала шул! Көтеп ала һәм шуннан туган тәэсирләрен, хәтерендә изге бер хатирә итеп, кадерләп саклый.

Соңгы елларда коллектив Идел буе өлкәләрен иңләп йөрде, аннары Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан шәһәрләре һәм авылларында булды. Әгәр аның маршрутын картага төшерсәк, без анда Ульяновск, Сызрань, Саратов, Әстерхан, Волгоград, Баку, Караганда, Алма-Ата, Дүшәнбе, Семипалатинск, Свердловск, Пермь, Чусовая, Березники кебек эре һәм вак калаларның исемнәрен укыр идек.

Менә хәзер дә алар ерак сәфәрдән — Целиноград өлкәсеннән кайтып киләләр. Мөхәммәт ага Хәмзин җитәкчелегендәге труппа бу якларда тамашачыларга берничә спектакль күрсәтте. Шуларның иң уңышлысы, мөгаен, татар әдәбияты классигы Шәриф Камал әсәре буенча куелган «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакле булгандыр. Үткән заманның кара пәрдәсен күтәреп, иске тормыштагы байларны фаш иткән, хакыйкать һәм ялган, яктылык һәм караңгылык көрәшен чагылдырган бу комедия төрле яштәге һәм төрле эштәге

тамашачыларны көлдерде дә, уйландырды да. Өлкә үзәгендә чыга торган «Коммунизм нуры» газетасында казакъ язучысы Н.Уразов зур гына мәкалә язып чыкты. Анда Татарстанның атказанган артисты Мөхәммәт Хәмзин уены турында шундый юллар да бар иде: «Хәмзиннең сәхнәдәге һәрбер шөгыль-хәрәкәте Хаҗи әфәнденең карикатур кыяфәтен күпсанлы детальләр аша сурәтләүгә юнәлдерелгән. Аның бар килеш-килбәте ачы мыскыллауга дучар. Кырык ел бергә яшәгән хатыны алдында икейөзлеләнгән Хаҗи әфәнденең финалда мәсхәрә булуыннан рәхәтләнеп көләсең».

Мөхәммәт аганың кырык елга сузылган иҗат юлында маяк булып кабынган мондый рольләре аз булмады. Ул тудырган персонажлар галереясына килеп керсәң, заманалар һәм дәверләр, характерлар һәм кичерешләр гаммасы, теләк-омтылышлар һәм фикерләр карурманы арасында адашып калгандай буласың. Кем генә юк биредә! Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасындагы мактанчык һәм тәкәббер Исмәгыйль, Риза Ишморатның «Үлмәс җыр»ындагы Бельгия патриоты Андре Тиммерманс, Л.Митрофановның «Көчлерәк янсын йөрәк» спектаклендәге инженер Юрьев, Н.Хикмәтнең «Сәер кеше» әсәрендә адвокат Әхмәт Риза, Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендәге укытучы Сәлим Гәрәевич...

Драматург Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасы буенча куелган спектакльләр Татарстан тамашачыларына яхшы таныш. Алар төрле театрларда төрле режиссерлар тарафыннан куелдылар. Ләкин Республика дәүләт күчмә театры постановкасы алар арасында аерым игътибарга лаек иде. Бу уңышта, билгеле, М.Хәмзиннең дә өлеше зур булды.

Ул гәүдәләндергән укытучы Сәлим Гәрәевич үз эшен яратып башкара, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ләкин аның күңеленә төер булып утырган авыр үткәне бар. Ул шуңа хафалана, шуңа үз-үзен битәрли. Тамашачы, бу кичерешләрен тулысынча аңлап, аңа ышанып, элекке гамьсезлеген шелтәләү белән бергә, хәзерге фаҗигале хәсрәтен дә уртаклашып утыра, күңеленә үтә якын ала. Артист осталыгы тамашачыга бу хәлнең бөтен драматизмын җиткерә.

Мөхәммәт ага үз язмышын күчмә театр белән моннан 27 ел элек бәйләде. Сугыштан соңгы авыр, киеренке чор иде бу. Коллективның материаль хәле мөшкел, иҗади көчләр җитешми. Режиссер Габдулла ага Юсуповны туктаусыз бер мәсьәлә борчый: коллективны саклап калып булырмы, юкмы? Инде азмы-күпме традициясе булган, үз тамашачыларын тапкан иҗат оешмасы алдына әнә шундый сорау килеп баса.

Сәхнә эшенә чын күңелдән бирелгән җитәкче мәсьәләне бер якка һәм фәкать уңай якка хәл итү өчен көчен дә, вакы-

тын да кызганмый. Шундый авыр вакытта, күктән төшкән бәхет кебек, коллективка Совет Армиясе сафларыннан кайткан Мөхәммәт Хәмзин, Фәридун Юнысов, Әхмәт Әбдерәшитов, Тайфур Кичубаев, Зәйтүнә Хәлиуллина, Зәкия Туишевалар килә. Театр бераз тернәкләнгәндәй була. Репертуарга зур сынаулар кичергән халкыбызның күңел кылларын тибрәтердәй заман темасына язылган әсәрләр сайлап алына. Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры», Г.Насыйриның «Күңел дәфтәре», А.Корнейчукның «Украина далаларында» әсәрләре буенча куелган спектакльләрне авыл тамашачылары хуплап каршылыйлар.

Ләкин көчле оештыручы, коллективның административ җитәкчесе һәм режиссеры булган Габдулла Юсуповның Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә күчүе Күчмә театрны кабат авыр хәлгә куя — аннан соң бер-бер артлы режиссерлар алышына башлый, кайбер артистлар сәхнә белән бөтенләй саубуллашалар. Бу торгынлык берничә елга сузыла.

Ниһаять, хәлне үзгәртү өчен Татарстан Мәдәният министрлыгы ашыгыч чаралар билгели. Театрның директоры итеп Мөхәммәт Хәмзин, ә режиссер итеп сәнгать өлкәсендә зур казанышлары булган Сөләйман әфәнде Вәлиев-Сульва куела. Коллективка эш өчен тиешле шартлар тудырыла: театрга аерым бина бирелә, труппа яңа кадрлар белән тулыландырыла. Моннан тыш театр республикабыз районнарында гына түгел, башка өлкәләрдә яшәүче татар хезмәт ияләре алдында да чыгыш ясау хокукын яулап ала. Театрда репертуарга караш нык үзгәрә. Ул түбән зәвыклы тамашачыларга исәп тотып алынган һәм мәгънәсез эффектка корылган урта кул әсәрләрдән акрынлап арына бара. Театр афишаларын, татар драматурглары тудырган тирән эчтәлекле, заманча яңгырашлы әсәрләр белән беррәттән, башка халыкларның драматургиясе хәзинәсенннән алынган әсәрләр дә бизи башлый Н.Исәнбәтнең «Рәйхан», Р.Ишморатның «Үлмәс җыр», Г.Минскийның «Тапшырылмаган хатлар», Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт», Л.Митрофановның «Көчлерәк янсын йөрәк», Г.Мазинның «Бүген һәм иртәгә», В.Лаврентьевның «Иван Буданцев», Д.Мдиванининың «Тереза туган көн», Д.Юлтыйның «Карагол», Д.Медведенконың «Юлда яткан таш» әсәрләренә нигезләнеп куелган спектакльләр әнә шундыйлардан. Замандашларыбызның тормышын, хезмәтен чагылдырган бу спектакльләр татар матбугатында һәм гастрольләр вакытында башка республика, край, өлкә газеталарында басылган рецензияләрдә уңай бәя алдылар. Күчмә театрның зур казанышлары дип бәяләнделәр.

Әлбәттә, уңышлар җиңел генә бирелмәде. Мөхәммәт

Хәмзингә төн йокыларын сарыф итеп баш ватарга да, төрле оешмаларга йөри-йөри нәрсәдер үтенергә, ялварырга да туры килде. Нишлисең бит, сәнгатькә хезмәт итү мәшәкатьсез булмый. Аның каравы коллектив ныклап аякка басты. Шунысы олы куаныч — хәзер ул тупланган, бердәм көч, олы таләпләр алдында да югалып калмаска сәләтле. Аның бүген горурланып телгә алырдай спектакльләре, үзе тәрбияләп үстергән күренекле мәдәният эшлеклеләре, артистлары бар. РСФСРның атказанган артисткасы Вера Минкина, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашева һәм Татарстанның халык артисткасы Зәкия Туишева, Татарстанның атказанган артисткасы Бибинур Галиуллина, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Сәет Шәкүров, сәхнә ветераннары Газиз Гыйматов, Зәйтүнә Хәлиуллина, Фәридун Юнысов, Мөнирә Шаһидуллина, Фердинанд Фарсин һәм башкаларның чын иҗат эшчәнлеге нәкъ менә шушында, Республика күчмә театрында башланды, дисәк, һич ялгышмабыз. Аларның һәркайсы үзләре белән кулга-кул тотынып эшләгән олы җанлы дусларын — Татарстанның атказанган артисты Мөхәммәт Хәмзинне, аның сокландгыч оештыру сәләтен һәрвакыт олы ихтирам белән искә алалар, аңа киңәш итәләр, аннан ярдәм сорыйлар.

Үзе киң күңелле, тиз аралашучан булгангамы, гомер буе аңа яхшы кешеләр генә очрап торды шикелле. Әле сәнгать дөньясына беренче адымнарын гына атлаганда ук язмыш аны татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре Салих Сәйдәшев, Кәрим Тинчурин, Ситдыйк Айдаров белән таныштырды. Лаеш якларындагы Янтык дигән авылдан Казанга артистлык һөнәрен өйрәнергә килгән иде Мөхәммәт ул вакытта. Академия театры каршындагы студиядә укып йөрде — укытучылары аның моңлы тавышына, музыка коралларын бер тотып караудa ук аннан көй чыгара алуына сокланганнар иде. Ләкин егет, вакыйгалар агышын тизләтергә теләпме, бер елдан соң Уфа сәнгать техникумының турыдан-туры өченче курсына китеп барды. Аны яхшы билгеләренә генә тәмамлап, Хаҗи Бохарский җитәкчелегендәге Авыргазы районы колхоз-совхоз театрында эшләде. Аннан тагын Казан... Бу юлы инде ул музыка училищесын сайлады. Ә 1939 елда аны Идел буе хәрби округының яңа гына оештырылган җыр һәм бию ансамбленә солист итеп алдылар, һәр борылышында сөенече дә, көенече дә сагалап торган авыр һәм мактаулы иҗат юлы әнә шулай башланды.

Авыл малае... студент... җырчы... драма артисты... Республика күчмә театры җитәкчесе. Бу — аның тормыш бас-

кычлары. Аларда никадәр якты хатирәләр, тырыш хезмәт белән үткән онытылмас көннәр. Әнә шуңа күрәдер инде хезмәтенә күрә хөрмәтен дә кызганмадылар Мөхәммәт агадан. Совет сәнгатен үстерүдәге тырышлыгы, хезмәт ияләрен тәрбияләүдә актив катнашканы һәм мәдәният учреждениеләрендә күп еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен ул «Почет билгесе» ордены һәм «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән бүләкләнде. 1960 елда аңа «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Ә иң мөһиме — үзенең якты, кешелекле таланты белән ул күпме тамашачының мәхәббәтен казанды, кешеләрдән рәхмәт сүзе ишетте.

Юк, үз язмышына үпкәли алмый Мөхәммәт ага — башкаларны сөендерә алуы белән генә дә ул үзен бәхетле санарга хаклы. Озын гомер юлы менә хәзер аларга таныш җыр көйләгән чуен юллар сыман тигез, сикәлтәсез булмаса да, мәгънәле үтелгән, матур истәлекләр калдырган...

Купеларның берсе ачылды да коридорга олы яшьләрдәге бер ханым чыкты. Мөхәммәт ага, уйларыннан бүленеп, аңа борылып карады. Ә-ә, Мөнирә Шаһидуллина икән. Әйбәт артистка, театрда иң ихтирам ителгән кешеләрнең берсе. Яшьләр һәрвакыт аңа охшарга тырышалар.

— Нәрсә, Мөхәммәт абый, Казан сагындыра мәллә — иртә таңнан чыгып баскансың?

— Анысы да бардыр инде, Мөнирә... Менә юллар турында уйланып барам әле. Кеше гомерендә күпме юл үтелә бит.

— Әйе... байтак җыйналгандыр шул. Ә алда үтеләселәре әле күпмедер...

Алар, хыялга бирелеп, тәгәрмәчләрнең таныш җырын тыңлап баралар. Кояш офыктан шактый югары күтәрелгән инде.

*1974*

## *Нәфисә Васыйлова*

1966 елның көз көннәре. Радиодан моңарчы ишетелмәгән бер көй яңгырый. Җырның сүзләре дә, көйдәге моң да, башкаручының тавышы да — барысы бергә кушылып, күңелдә гаҗәеп бер ләззәт тудыра. Моңлы җырны ишетеп тын калган һәр кеше җырчының кемлеген белергә тели. Чөнки «Киек казлар» җыры нәкъ менә шул тавышка килешеп тора.

Үзәкләрне өзгеч бу җырны беренче тапкыр Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солист-

касы Нәфисә Васыйлова башкарды. Үзе Саба районының Субаш авылында дәһшәтле сугыш елларында туган ул. Кызның әтисе сугышның соңгы көннәрендә һәлак була. Әнисе биш бала белән тол кала. Нәфисә, төпчек кыз буларак, әнисе кайда эшләсә, шунда йөри. Әнисенең колхоз кырларын яңгыратып сузып-сузып җырлавын ишетә. Олы апасы да җыр яратучан була. Шунлыктан өйдә дә, кырда да, эш вакытында да, ял иткәндә дә гаиләне җыр юата. Биш-алты яшьлек чагында ук Нәфисә дә җырлый башлый, сабантуйларында катнаша, халыкны шатландыра.

Соңыннан, гаиләләре белән Казанга күчеп килгәч тә, Нәфисәнең җырга мәхәббәте кимеми. Радио аша Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова чыгышларын тыңлый ул. Тыңлый-тыңлый да радиога кушылып үзе дә җырлап җибәрә.

Урта мәктәпне тәмамлап, төзелештә эшли башлагач та, кызның күңеле һаман җыр-сәнгать дөньясына тартыла иде. Ул үзлегеннән нота гыйлемен өйрәнде, үзе теләгән җырларны нотага карап җырлый алуга иреште. Үзешчән сәнгать түгәрәгендәге дәресләр, халык алдында чыгыш ясаулар Нәфисәдәге көчне, ышанычны арттырды. Түгәрәк җитәкчесе Любовь Осиповна Гиглавый җырчының сәләтенә соклана.

Озак та үтми, 1965 елда, Нәфисә Васыйлованы ансамбльгә эшкә кабул итәләр. «Киек казлар» җыры Нәфисәнең бу коллективта үзен күрсәтерлек беренче әсәр булып яңгырый.

Аннан соң инде артистканың иҗат биографиясенә күп җырлар өстәлде: «Юллар, юллар...» (Л.Айтуганов көе), халык җыры «Беләзегем-йөзегем», «Үз илемдә» (С.Садыйкова көе), япон халык җыры «Тыныч бул» һәм башка халыкларның җырлары Нәфисәгә яңадан-яңа уңышлар китерә.

Җырчының иҗатын тыңлаучылар гына түгел, белгечләр дә кызыксынып күзәтәләр. Татарстаннан читтәге шәһәрләрдә дә аны сокланып тыңлыйлар. Гастрольләр исә өзлексез дәвам итә. Нәфисә Васыйлованы хәзер Мәскәү, Свердловск, Ленинград, Омск кебек шәһәрләрдә көтеп алалар.

Омскидагы чыгышларыннан соң артистканы чегән җырчысы Михай Шишков үз ансамбльләренә дә чакырган иде. «Сезнең тавыш чегән романслары җырлау өчен коеп куйган, килегез, үкенмәссез!» — диде.

Нәфисә шаярып: «Романслар безнең үзебездә дә җитәрлек!» — дип җавап биргән. Шул сүзләрен тормышка ашыру өчен җырчы хәзер композитор Рөстәм Яхин романсларын өйрәнә. Киләчәктә Нәфисә Васыйлова җырларга теләгән әсәрләр арасында чегән романслары да бар. Көтик, анысын да ишетербез әле.

*1973*

Балалар театры аша һәр яшүсмер сәнгать дөньясына беренче адымын ясый. Шул адым баланы сәнгатьнең күп төрләре — җыр, бию, әдәбият, нәфис сөйләм, музыка, рәссам дөньясы белән беренче таныштыра. Беренче танышудан калган хис аның күңелендә гомер буе саклана һәм киләчәктә формалашуында зур роль уйный. Димәк, зур сәнгатьнең бурычы аны бала күңелендә кызык бер тамаша итеп калдыру түгел, ә дөрес юнәлешле эмоция бирү. Шул дөрес башлангычлы сәнгатьтән калган карашы, фикер йөртүе белән бала чын кеше, хөрмәткә лаек яшь бер гражданин, алмашчы булсын. Мондый олы бурычның иң элек балалар театрларына төшүе дә сер түгел. Димәк, бу коллективларның бурычлары ачык, репертуарлары тәрбияви яктан заман сулышын чагылдырырлык булырга тиеш. Балалар театры ул — зур сәнгатьнең барлык төрләрен тиешле югарылыкта пропагандалау трибунасы.

Күптән түгел Язучылар, Рәссамнар, Композиторлар берлеге вәкилләре, республикабызның сәнгать әһелләре, зур, катлаулы мәсьәләләрне уртага салып, ачыктан-ачык сөйләшү алып бардылар. Аның ярдәме зур булды. Киңәшләр һәм юнәлеш бирелде. Чыннан да, хәл ителәсе проблемалар безгә — балалар театрлары коллективлары өстенә төшә. Бу катлаулы һәм мактаулы хезмәтне башкару безнең төп бурыч. Ләкин бүгенге яшь буынны тәрбияләү, аларга зур сәнгать дөньясын пропагандалау өчен барлык оешмаларга да кулгакул тотынып эшләргә кирәк. Чөнки чишәсе проблема уртак: бүгенге балаларны киләчәктә булачак галимнәр, врачлар, инженерлар, педагоглар, әдәбият-сәнгать һәм төрле хезмәт кешеләрен тәрбияләп үстерү.

Проблемаларның беренчесе булып балалар театры өчен репертуар мәсьәләсе тора. Драма театрының да бу өлкәдә зур кытлык кичерүе, хәтта Академия театры сәхнәсендә дә соңгы өч елда бер балалар постановкасы булмавы да яшерен сер түгел. Димәк, Язучылар берлеге һәм аның каршындагы Балалар әдәбияты секциясе белән кулга-кул тотынып эшләрлек хезмәт бар. Бу сорауга җавап бирер өчен театр репертуарына күз ташлыйк.

1975 — 1976 ел театр сезонында төп репертуарда егерме әсәр уйналган. Шуларның уналтысы Бөтенсоюз сәхнәләрендә бара торган рус язучылары әсәрләре. Татар группасының репертуары дүрт пьесадан — Н.Фәттах, Т.Миңнуллин, Г.Рәхим һәм Н.Дәүли әсәрләреннән тора. Алар республикабызның барлык районнарында да балаларга күрсәтелеп беткән. Бүген сәхнәләштерер өчен яңа әсәр юк. Димәк, ирек-

сездән рус әсәрләрен тәрҗемә итәчәкбез. Җирле драматургиябез өчен бу күңелле факт булмаса да, реаль факт. Балалар драматургиясе секциясе белән эшне киләчәктә нинди юнәлештә алып барырга? Безгә нинди әсәрләр кирәк?

Күз алдына китерегез, без елына 700 мең нәни тамашачыга культура хезмәте күрсәтәбез. Алар өчен репертуар таләбе түбәндәгечә булырга тиеш. Мәктәп яшенә кадәр булган балалар бездән нәрсә көтә? Бу чорга шәһәребезнең балалар бакчаларына йөрүче нәни тамашачыларыбыз керә. Бу яшьтә бала күңелендә тапкырлыкка, гаделлеккә, үзен чорнап алган кешелеккә, хайваннар дөньясына, табигатькә ихтирам уяту, ата-анага мәхәббәт тудыру бик җиңел. Бу өлкәдә театр, халык иҗатыннан тыш, А.Пушкин, Г.Тукай, Һ.Такташ, Ф.Кәрим, М.Җәлил, Г.Кутуй әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, җирле авторлар ярдәмендә дистәләгән еллар репертуардан төшми уйналган көчле пьесалар иҗат итте. Соңгы еллар репертуарына күз салсак, бу яшьтәге балалар өчен ике әсәр — «Чуар тавык» һәм язучы Г.Рәхим тарафыннан Тукай шигыренә эшләнгән «Кәҗә белән Сарык» әкияте сәхнәләштерелгән. Шәһәребездәге өч йөз балалар бакчасы һәм аларга йөрүче дүрт мең баланы тәрбияләүдә, бала күңелендә сәнгатькә мәхәббәт уятуда бу ике әсәр генә зур роль уйный аламы?

Икенче төр һәм башка таләп тәкъдим итүче тамашачы ул — беренче сыйныфтан бишенче сыйныфка кадәр булган укучылар. Чынлыкта элеккеге дүртенче сыйныф программасында үтелгән тигезләмә бүген беренче сыйныф программасына керә. Илебездә техник революция гаҗәп тизлек белән алга бара. Бала аларны үзен чорнап алган тирәлек аша күрә. Болар бар да аның аңының, белеменең үсеш процессын тизләтә. Бу очракта татар группасында уйналган «Кәҗә белән Сарык» әсәре алар таләбен канәгатьләндерә аламы? Балалар секциясе белән театрның художество советы каршында бу сорау иң беренче булып торырга тиеш.

Шулай ук бу яшьтәге тамашачыларда илгә мәхәббәт, дошманга нәфрәт тәрбияләүдә хәрби-патриотик темага язылган әсәрләр зур роль уйный. Театр коллективы бу өлкәдә дә эзләнә. Шуның нәтиҗәсендә А.Гайдарның «Хәрби сер» әсәре буенча язылган, Н.Фәттахның һәм Р.Батулланың «Баһадирлар» әсәре туды һәм зур уңыш белән баралар. Бүген өстәл тартмасында киләчәктә шушы традицияне дәвам итәр өчен бер әсәр булмау безне борчый. Әдәбиятыбызда бу өлкәдә күп көч түккән Г.Әпсәләмов, Ш.Рәкыйпов, С.Шакир, Н.Дәүлиләрнең фашизмның йөзен ачып салган көчле әсәрләре бар. Бергәләп кулга-кул тотынып эшләгәндә, бу әсәрләрдән көчле балалар драматургиясе туар иде.

РСФСР Культура министрлыгы күптән түгел балалар

театрларына кагылышлы махсус карар кабул итте. Анда ачыктан-ачык «Союздаш һәм автономияле республикаларның җирле авторлардан торган драматургияне үстерергә һәм шул авторлар ярдәме белән якындагы биш елга театр репертуарын булдырырга» диелгән. Бу карар Язучылар берлегенең балалар секциясендә игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Без күбрәк күктәге планеталарны пропагандалауга зур игътибар бирәбез. Марс, Венераның барлык нечкәлекләрен радио-телевидение, газета-журналлар, дәреслекләрдәге фантастик әсәрләр аша бала күңеленә сеңдерәбез. Бу яхшы эш. Ләкин күп очракта җирнең матурлыгын, андагы яшәүче кешеләрнең гүзәл тормышын, хайваннар дөньясына, табигатьне саклауга булган мәхәббәтне тудыра торган драматик әсәрләр кирәклеген онытып җибәрәбез.

Алтынчы сыйныфтан сигезенче сыйныфка кадәр булган укучылар өчен без махсус алар яшенә һәм формалашуга адресланган пьесалар тәкъдим итәргә тиеш. Елына йөз мең нәни авыл тамашачысының безнең спектакльләрне каравын искә алсаң, биредә сорау катлаулана бара. Ни өчен? Чөнки бүгенге репертуарда авыл кешесенең тормышын, туган җирне олылауны, андагы хезмәтнең үсешен, авыл культурасын һәм аның интеллигенциясенең яшәвен чагылдырган әсәрләр юк диярлек. Ә бит бүгенге сигезенче сыйныф укучысы киләсе елга алдынгы сыер савучы яисә механизатор булырга тиеш.

Авыл тормышын чагылдырган балалар әдәбиятын иңнәрендә күтәреп баручы язучылар Ә.Маликов, Б.Камалов, Р.Хафизов, Р.Кәрамиевләрнең исеме киң катлау укучыларга таныш. Чынлап тотынганда, балалар драматургиясенә алар зур өлеш кертә алган булыр иде.

Бүгенге сигезенче сыйныф укучыларының илле проценты киләсе елга техник училище укучылары булачак. Татарстанның илле өч техник уку йортларында ике меңгә якын укучы маляр, штукатур, ташчы, слесарь, токарь һ.б. күп кенә һөнәргә өйрәнәләр. Ничә ел инде бөтенсоюз күләмендә иң яхшы эшче образын тудырган әсәрләргә конкурс бара. Ул очракта драматургия ни өчен бер урында таптана һәм һөнәр ияләре тормышын чагылдырган бер генә балалар әсәре дә юк соң?

Быел РСФСРның утыз театры үз өлкәсенең, шәһәренең тарихы турында, аның героик кешеләре һәм барыбыз өчен дә күңелгә якын булган башкаласына багышланган әсәрләр тудыралар. Шул уңай белән төрле буын язучылардан без яңа әсәрләр сорап, аларга мөрәҗәгать иттек. Ләкин бу эш хыял булып кала бирә.

Тугызынчы-унынчы сыйныф укучылары һәм ата-аналар өчен без театр тарихында беренче буларак кичке спектакль-

ләр куя башладык, ә репертуар юк. Комсомол үткән юл, бөек төзелешләр КамАЗ, БАМ тормышын сурәтләгән, ата-анага ихтирам, мәхәббәт уяткан әсәрләргә мохтаҗ бүген без.

Укучыда сорау туарга мөмкин: балалар драматургиясе бер урында таптанамы? Ул очракта балалар театрлары нәрсәгә нигезләнеп эшли? Юк, балалар драматургиясе эзләнү, үсеш чорында. Коллектив һәрвакыт көчле язучылар белән элемтәдә тора, яңа әсәрләр тудыруда кулга-кул тотынып иҗат итә. Без елына алты-җиде яңа әсәр сәхнәләштерәбез һәм бер сезонда мең дүрт йөз спектакль күрсәтәбез. Кырык кешелек иҗат коллективы өчен бу зур хезмәт! Язучыларыбыз да эзләнү юлында. Китап нәшрияты ел саен дистәләгән яңа пьесалар бастырып чыгара, балалар секциясе аңа фатиха бирә. Тик югарыда язылган таләпләргә җавап бирерлек әсәрләр азлыктан, коллектив алардан файдалана алмый. Хәтта үзешчәннәр түгәрәкләре дә яңа пьесаларны бездән соратып алалар. Безнең теләк — Язучылар берлегенең балалар секциясе, язучылар балалар театрлары коллективлары белән кулга-кул тотышып эшләсеннәр иде. Чөнки таләп тә, бурыч та бер — яшь алмашны дөрес тәрбияләү.

Бала күңелендә калдырырга теләгән уңай сыйфатлар музыка, сынлы сәнгать аша җиңелрәк бирелә. Бала йөрәге алар аша театр әйтергә теләгән фикерне тизрәк кабул итә. Шуңа да безнең репертуарда төп урынны музыкаль әсәрләр алып тора. Көчле музыкаль мультфильмнар туган бу чорда такмаклар, кайчандыр язылган музыканы сайлап алу, әсәргә яраклаштыру заманы артта калды. Шул җаваплылыкны сизеп, без күп кенә композиторлар: С.Садыйкова, М.Яруллин, Ф.Әхмәтов, Р.Бикбулатовлар белән кулга-кул тотынышып эшлибез. Ләкин күз алдына китерегез: шәһәребезнең 55 балалар музыка мәктәбен, 45 музыка түгәрәген, Чайковскийның, Глинканың, Рахманиновның, Бетховенның, Моцартның, Хачатурян, Җиһанов, Мозаффаров һ.б. күп кенә композиторларның әсәрләрен күңелдән өйрәнгән меңләгән нәни тамашачылар таләбен алар иҗаты гына канәгатьләндерә аламы? Республикадагы балалар музыкасын үстерүгә зур өлеш керткән З.Хәбибуллин, Ә.Бакиров, А.Монасыйпов, Б.Мөлеков, яшьләрдән Л.Хәйретдинов, Р.Билалова, И.Якупов кебек композиторлар бар. Ни өчендер алар үзләренең иҗатларын балаларга фортепьяно өчен һәм инструменталь пьесалар язу дип кенә саныйлар. Безнең сәнгать ни өчендер аларга түбән тоела. Чынлыкта бала күңелендә чын музыкага мәхәббәт уятмый торып, музыка әлифбасын өйрәнмичә, пьесаларга һәм операларга күчүе авыр икәне ачык. Алар китап киштәләрендә ауный бирәләр. Музыканың нигезен балалар театрларында башларга кирәк. Чөнки опера театрларына да

тамашачыны без хәзерлибез. Менә ни өчен Композиторлар берлеге белән балалар театрларының тыгыз элемтәдә иҗат итүе шарт.

Сынлы сәнгать тә бала өчен һава кебек кирәк. Ул, күзен ачып дөньяга караш ташлауга, төсләр аера башлый. Укый белә башлаганчы ук төсләр аша бала тирәлек белән аралаша. Үсү процессында рәсем сәнгате аша ул хәреф белән таныша. Курчак сәнгатенең төп көче — сәнгатьнең бу төрен бала күңелендә сәхнәдә уйналган әсәрнең оформлениесе, декорациясе, курчаклар аша мәңгегә сакланырлык итеп калдыру. Бүгенге залда шәһәребезнең заманча җиһазландырылган һәм мөмкинчелекләр тудырылган 11 балалар художество мәктәпләреннән килгән меңнәрчә нәни таләпчән тамашачы утыра. Алар зәвыгын канәгатьләндерү өчен безнең театрда Э.Гельмс, А.Сперанский, Я.Насыйров, В.Губская кебек балалар рәссамнары зур хезмәт башкара. Валентина Губская иҗат иткән курчак-образлар бөтенсоюз күләмендә беренче дәрәҗә дипломга лаек булдылар. Театр фойесында бу яшь рәссамның иҗат күргәзмәсе быел балаларда зур кызыксыну тудырды. Күргәзмәдә катнашкан балаларга без спектакльдәге образлар буенча конкурс игълан иттек. Театрга килгән йөзләгән рәсемнәр балаларның бу төр сәнгатькә зур кызыксынуын раслый. Сүз уңаеннан шуны әйтәсе килә, Рәссамнар берлеге бу өлкәдә безнең белән элемтәдә торса, яхшы булыр иде. Без алар иҗатын пропагандалауга әзер торабыз. Театр фойесында айга бер күргәзмә оештырганда, меңләгән балалар аларның кыйммәтле хезмәтләре белән таныша алган булыр иде. Бер мисал китерәм. Сынлы сәнгать музеенда ел да унике мең чамасы бала була. Ә бездә Яңа ел кампаниясендә генә дә унбиш көн эчендә егерме җиде мең бала республикабыз талантларының иң яхшы әсәрләре белән таныша алган булырлар иде.

Пропаганда ул — зур сәнгатьне вакытында бәяләү. Яшь буынны тәрбияләүдә аның роле зур. Шуның өчен танылган һәм яшь буын язучыларының, рәссамнарының, композиторларының спектакльләр алдыннан балалар алдында чыгышларын оештырырга кирәк. Күптән түгел бер кызыклы очрашу булды. «Җиде кат җир астында» спектакленең авторы язучы Н.Дәүли 250 бала утырган зал каршында әсәрнең язылу тарихын, үзенең алдагы планнары турында сөйләде. Соңыннан тутырган анкетада 25 баланың язучы булу теләге барлыгы беленде. Димәк, булачак кадрларда теге яки бу һөнәргә мәхәббәт уятуда да пропаганданың роле зур. Язучылар берлеге каршындагы пропаганда бюросы белән без шуңа да тыгыз элемтәдә торабыз. Ә рәссамнар, композиторлар шундый кызыклы очрашуга рәхим итсәләр, аннан ике

як та отар гына иде. Бездә балалар алдында еш кына төрле һөнәр ияләре, хезмәт батырлары, хәтта авыл хуҗалыгы алдынгылары чыгыш ясыйлар, балалар күңелендә теге яки бу һөнәргә мәхәббәт уяталар.

Радио-телевидение, газета-журналлар аша балаларга сәнгатьнең зур әһәмияткә ия булуын пропагандаларга кирәк. Күп кенә оешмалар аны театр эше дип кенә карый. Театрның ролен, актерларның үсешен, тамашачының таләбен билгерткән, балаларның театрда үз-үзләрен тотышына багышланган матур тапшырулар ишетәсе килә. Елына җиде яңа спектакль чыгарган коллективның уңышын, кимчелекләрен ачкан бер генә рецензия күренмәү нык борчый безне. Республикабызда балалар тормышын чагылдырган, хезмәте белән мактауга лаек махсус газеталар һәм журналлар чыга. Ләкин 1976 — 1977 елгы театр сезонында бер мәкалә чыкмау, театрда кунакта бер газета хезмәткәре булмау аяныч хәл. Театр тәнкыйтенә игътибарны юнәлтергә күптән вакыт. Шәһәребездә 153 язучыны һәм 650 журналистны берләштергән ике зур оешма бар. Аларга Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында хезмәт итүче дистәләгән сәнгать белгечләрен кушсак, елына бер спектакльгә рецензия чыкмау очрагын ничек аңлатырга? Балалар театры буенча бер белгеч хәзерләүне күптән көн тәртибенә куярга кирәк.

Минемчә, балаларны тәрбияләүдә, алар сәнгатен пропагандалауда җәмәгатьчелеккә, мәгариф органнарына, мәктәпләргә, театрларга, ата-аналарга бергәләп кулга-кул тотынып эшләр вакыт җитте. Күп кенә мәктәпләр бу хезмәтне театр эше дип кенә карыйлар. Без быел балаларны театр көче белән заманча җиһазландырылган яңа автобусларда барып алабыз, спектакльдән соң илтеп куябыз. Шуңа карамастан «сезнең хезмәтне башкарабыз» дигән үпкә сүзләрен күп кенә укытучылардан ишетергә туры килә.

Тәрбия һәм сәнгатьнең әһәмиятен пропагандалауда гаиләнең, ата-ананың роле зур. Биш яки җиде яшьлек бала театрга бару теләген ата-анага үзе белдерә алмаска мөмкин. Димәк, балалар сәнгатенең ролен ата-анага пропагандалаудан баш тартмаска кирәк. Менә ни өчен без быелгы сезонда рус һәм татар телләрендә зурлар өчен дүрт яңа спектакль куячакбыз һәм иң яхшы постановкалардан декада уздырачакбыз. Ләкин еш кына театр залында бу тәрбияче ата-аналарның үзләрен тәрбияләргә туры килә. Спектакль вакытында үзләрен тота белмәү, буфетта, кием тапшырганда көчләрен күрсәтү; спектакль бетмәс борын баласы киемен алырга залдан чыгып чабу очракларын еш очратырга мөмкин. Ә балалар бу күренешләрне күзәтеп тора, тискәре күренеш аңа

тиз йогынты ясый. Бу төр сәнгатьне киң халык массасына пропагандалауда үзешчән коллективлар зур роль уйный алырлар иде. Республикада зурлар өчен утыз биш халык театры, ике йөзләп драмтүгәрәкләр эшли. Ә балалар өчен шәһәребезнең өч-дүрт мәдәният йортында безнең актерлар көче белән уздырыла торган курчак сәнгате түгәрәкләре бу зәвыкны канәгатьләндерә алмый. Мамадыш районының Ошма, Чүпрәле районының Саплык авыл яшьләре оештырган түгәрәкләргә үзешчәннәр рәхәтләнеп йөри. Республикабыз районнарында күренгән бу ике коллектив, әлбәттә, Кабан күленә бер стакан су салу белән бер.

Заман алга бара, кешелек бер урында таптанмый, һәрхәлдә, яңа үрләр яулый. Без дә бердәм көч белән Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәмендә бөтен мөмкинчелекләрдән чыгып эзләнү чорын кичерәбез, иҗат итәбез. Татар яшьләр театры булмау сәбәпле, Г.Камал исемендәге Академия, Опера һәм балет театрына тамашачы әзерләү дә безнең өскә төшә. Зур теләк булганда да коллектив республикабызның барлык авылларына ел саен мәдәният хезмәте күрсәтә алмый. Бу физик яктан мөмкин түгел. Якындагы елларда Әлмәт — КамАЗ зонасында курчак театрының филиалын булдыру бурычы тора. Куйбышев, Ульяновск, Свердловск өлкәләрендә профессиональ театр эшләү сер түгел.

Шәһәребездә йөзләгән заманча җиһазландырылган яңа мәктәпләр үсеп чыкты. Мәдәният сарайлары, яңа сәнгать йортларыннан безгә кунакка балалар агыла. Театр бусагасын атлап керүгә, баланың беренче күзе төшкән һәр деталь аның күңелендә мәңгегә саклана. Бүгенге театр бинасының бу таләпләрне канәгатьләндерә алмавы да безне борчырга тиеш.

Чын иҗат йортлары, чын сәнгать рәссамы халык массасы өчен зур авторитет ул. Кешеләр эстетик сәнгатебез белән горурлана һәм безнең иҗатыбыз аша үзләренең шәхси, социаль тормышларын чагылдырган сорауларга җавап эзлиләр. Моның өчен безгә, иҗат коллективларына, концерт заллары, сәхнә, нәшрият кебек зур трибуналар бирелгән. Шул трибунаның көче — бердәмлектә. Курчак театры шул бердәм коллективның аерылмас бер өлеше.

«Әгәр дә театрдагы йөзләгән җансыз курчаклар тамашачы йөрәгенә җылы бирмәсә, алар Союздагы барлык театрлар иңенә һәм зур сәнгать дөньясына төшкән йөкне күтәрә алмаса, мин курчак сәнгате белән шөгыльләнмәгән булыр идем», — диде УНИМА президенты, Социалистик Хезмәт Герое, ССРның халык артисты С.Образцов. Бу акыллы сүзләр безнең барыбыз өчен дә девиз булып яңгырарга тиеш.

*1977*

## Таләпчәнлекне киметмәскә

Республикабыз театрларында яңа сезон ачылуга, меңләгән тамашачылар яңа премьераларны көтеп алдылар, һәр иҗат коллективы тамашачыларның ышанычын акларга, аларны чын сәнгатьчә эшләнгән спектакльләр белән сөендерергә омтыла.

Республикабызның башка театрлары кебек үк, Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективы да хезмәт ияләренең ялын оештыруда зур роль уйный, тамашачыларны көн кадагына суккан яңадан-яңа сәхнә әсәрләре белән таныштырып тора. Без үткән ел планын бер айга алдан үтәдек. Татар академия театры бинасында, Ташкент шәһәре тамашачылары алдында иҗат отчетлары тоттык. Традициябезгә тугрылыклы буларак, авыл хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтүдән дә читкә тайпылмадык. Үзара ярышта РСФСР Мәдәният министрлыгы һәм профсоюзлар үзәк комитетының дипломнары белән бүләкләнүебез — моның ачык дәлиле.

Әмма тормыш һәм тамашачы бездән тагын да зуррак җаваплылык таләп итә. Һәр иҗат коллективы кебек үк,ирешелгән уңышлар безне үткән юлга борылып карарга, СССР төзелүгә 60 ел тулуны лаеклы каршылау өчен, барлык мөмкинлекләрдән файдаланып, яңа иҗат мөмкинлекләренә өнди. Әмма бездә әлегә проблемалар һәм хәл ителмәгән мәсьәләләр дә шактый. Ул проблемаларның беренчесе — театрның репертуар политикасы. Тамашачылар республикабыз театрларының репертуарларыннан канәгать түгелләр, дип әйтәсе килми, әлбәттә. Әгәр дә безнең театр афишаларына гына күз салсак та, Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», М.Гафуриның «Кара йөзләр», Т.Миңнуллинның «Кырларым, тугайларым», А.Макаенокның «Хыянәтче», И.Юзеевнең «Онытылмас бәет», А.Гыйләҗевнең «Шикәрем син, балым син» һәм башка драматургларның әсәрләре буенча куелган спектакльләрне күрербез.

Ләкин репертуарыбыздагы әсәрләрнең яртысында диярлек башлыча тормыш-көнкүрешнең вак мәсьәләләрен чагылдырган, заман сулышыннан ерак торган проблемалар өстенлек итүе дә сер түгел. Күпчелек әсәрләр теге яки бу формада гаилә драмасын чагылдырудан узмыйлар. Ә бит бүгенге тамашачы көндәлек проблемалар белән һәр көн йөзгә-йөз очрашып тора һәм бүгенге драматурглардан шул проблемаларны игътибар үзәгенә куюны таләп итә. Әйтик, башкалабыз Казан — вузлар шәһәре. Ә ни өчен студент яшьләр тормышын чагылдырган драма әсәрләре сәхнәдә куелмый?

Республикабызның йөзләгән профессиональ-техник училищеларында меңләгән яшьләр төрле һөнәр ияләре булырга



Театр ветераннары белән очрашу вакытында



имтихан тоталар. Аларның эшче булып кына түгел, ә чын кеше һәм шуның өстәвенә киләчәктә театр залларын тутырачак тамашачы булып та формалашкан чаклары. Ә безнең хәзерге драматургиябездә яшүсмерне илһамландырырлык сәхнә әсәрләре юк дәрәҗәсендә.

Без узган сезонда колхоз председателенең авыр табигать шартларында икмәк өчен көрәшен чагылдырган «Кырларым, тугайларым» әсәрен куйган идек. Бу спектакль авыл тамашачыларының күңеленә бик тә хуш килде. Ул 300 тапкырдан артык уйналды, аны 15 меңгә якын тамашачы карады. Апас районы үзәгендә авыл хуҗалыгы җитәкчеләре белән бу спектакль буенча уздырылган тамашачылар конференциясендә әйтелгән фикерләр безне бүген дә уйландыра. Бүгенге авыл кешеләре — колхоз производствосының төп тармакларын әйдәп баручы белгечләр — механизаторлар, агрономнар, зоотехниклар, экономистлар гади колхозчыларның җырларга тиң хезмәтен чагылдырган сәхнә әсәрләре көтәләр. Бу ихтыяҗ театр җитәкчеләрен генә түгел, бәлки драматургларыбызны да уйландырырга тиештер.

Быел «Драматургиядә һәм театрда эшчеләр сыйныфы образы» дигән темага Бөтенроссия театр фестивале үткәрелә. Кызганычка каршы, театрларыбызның бүгенге репертуарында бу фестивальдә күрсәтерлек сәхнә әсәрләре юк дәрәҗәсендә. Театрлар драматургларыбызның эшче, төзүче, нефтьче һ.б.ларның образларын сәхнәгә менгерүләрен көтәләр.

Хәрби-патриотик темага багышланган, бабаларыбызның рухи дөньясын ачкан, батырлыкка өндәгән драма әсәрләренә дә ихтыяҗ зур.

Соңгы ике елда безнең театр коллективы ике проза (Г.Ахуновның «Хәзинә», М.Гафуриның «Кара йөзләр») әсәрен сәхнәләштерде. Бу — табигый хәл. Чөнки проза әсәрләре, бигрәк тә роман һәм повесть жанрлары, матур әдәбиятта мөһим урын алды. Шуңа күрә театрлар да аларны читләтеп үтә алмый. Бүгенге көндә Г.Әпсәләмов, Г.Бәширов, Ш.Маннур, Ә.Еники һ.б. язучыларның әдәбиятыбызның алтын фондына кертерлек повестьлары һәм романнары сәхнә көтеп яталар. Бәлки, бу мактаулы эш белән драматургларыбызга да шөгыльләнергә кирәктер?

Югарыда күтәрелгән проблемалар драматургларны гына түгел, иҗат коллективларын да борчырга тиеш, әлбәттә. Моның өчен драматурглар белән театрлар арасында тыгыз элемтә булдыру шарт. Мәсәлән, Татарстан Язучылар берлеге каршындагы драматургия секциясе шактый актив эшли. Ләкин театрларның художество советы белән секция арасында бернинди иҗади элемтә юк. Соңгы биш елда, мәсәлән, безнең театрга бу секция тарафыннан бер генә яңа пьеса да тәкъдим ителмәде.

Театрларда да яңа пьесаның язмышын күбесенчә бер генә кеше — баш режиссер хәл итә. ТАССР Мәдәният министрлыгы каршында драматургка соңгы сүзне әйтергә вәкаләтле

комиссия булдыру турында да уйланырга вакыт җиткәндер, минемчә.

Безнең театрларны борчыган проблемаларның тагын берсе — кадрлар мәсьәләсе. Театрларыбыз бүген вокаль мөмкинлекләре булган герой һәм героиняга мохтаҗ. Бу мохтаҗлыкны Казан театр училищесында булачак артистларны сайлап алу һәм укыту процессындагы зур кимчелекләр дә китереп чыгара. Күпьеллык күзәтүләр күрсәткәнчә, театр училищесы кабул итү имтиханнары чорына ныклы әзерлек белән килми. Гаризалар стихияле төстә генә килеп керә, училищега бернинди сәләте булмаган кешеләр кабул итү очраклары да бар. Ә бит кабул итү имтиханнары алдыннан зур оештыру һәм әзерлек эшләре алып бару кирәк! Әйтик, ел дәвамында кабул итү комиссиясе членнарының, театр җитәкчеләренең район үзешчән сәнгать смотрларында катнашулары, сәләтле яшьләрне ачыклавы, бик күп талантлар биргән төбәкләргә барып чыгуы зарури.

Бүген сүз артист кадрларны профессиональ яктан гына түгел, бәлки артист-гражданин, үз эшенең патриотлары итеп әзерләү турында да барырга тиеш. Юкса училищены тәмамлап безнең театрга килгән яшь артистларның күпчелеге, эш шартларының үзенчәлекләрен күтәрә алмыйча, театр белән бөтенләйгә хушлаша. Димәк, училищедагы педагоглар булачак артистларда сәхнәгә мәхәббәт, сәнгатькә бирелгәнлек сыйфатларын тәрбияли алмаганнар, яшь артистлар үзләренең рухи кыйблаларын тапмаганнар дигән сүз.

Шулай ук булачак артистларны югары уку йортларында әзерләү турында да сүз алып барырга вакыт җиткәндер[1]. Безнең кырык кешелек иҗат труппасы булган театрда, мәсәлән, югары махсус белемле бары тик ике актер бар.

Татар дәүләт академия театры бинасында иҗат отчеты айлыгында безнең спектакльләрнең художество оформлениесе түбән булуы турында тәнкыйть сүзләре ишетелде. Бу хакыйкатьне башка театрлар да икърар итмәс. Минемчә, бу төр сәнгатькә безнең республикада игътибар җитәрлек түгел. Безнең театрның баш художнигы П.Баландин 25 ел эшләве дәверендә үзенең иҗат лабораториясе турында бер генә тәнкыйть сүзе дә ишеткән кеше түгел. Аның югары үрли алмавының төп сәбәбе — театр рәссамнарына игътибар һәм таләпчәнлек булмау. Рәссамнар берлегенең бу зур мәсьәләгә игътибары бөтенләй юк. Театр рәссамнарының

[1] Хәзер бу мәсьәлә хәл ителгән — Казан мәдәният һәм сәнгать университетында андый белгечләр әзерләнә башлады.— *М.Ш.*

күргәзмәләрен ешрак оештырып, аларда тамашачылар конференцияләре, җитди сөйләшүләр уздыру, әлбәттә, иҗади үсеш өчен этәргеч булыр иде. Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге аша рәссамнарны зур театр сәхнәләренә иҗат командировкасына җибәрү практикасы да ни өчендер күренми.

Инде театр тәнкыйте турында. Соңгы вакытта без, башка иҗат оешмалары кебек үк, теге яки бу эшебезне профессиональ югарылыкта анализлаган чын осталар тәнкыйтенә мохтаҗ. Мәсәлән, соңгы ике елда безнең театр коллективы сигез драма әсәрен сәхнәгә куйды. Шуларның алтысына матбугатта рецензияләр бирелде, һәм алтысына да бары тик мактау сүзләре генә ишеттек. Бу зур бер коллективның иҗат эшчәнлеген ялгыш юлга этәрү түгелме? Бу кадәр мактау һәм мондый мәдхия җырлаудан кемгә файда? Безнең уңышларыбызны гына түгел, кимчелекләребезне дә җитди анализлаган, безнең алга проблемалар куйган, уйланырга мәҗбүр иткән рецензияләр күрәсебез килә. Әлегә күп кенә тәнкыйтьчеләребезнең профессиональ яктан әзерлеге җитенкерәми.

Йомгаклап әйткәндә, республикабызда театр сәнгатен тагын да югарырак баскычка күтәрүгә комачаулык итүче проблемалар шактый әле. Аларны уңай якка чишү халкыбызның театр работниклары алдына куйган таләпләренә җавап бирү булыр иде.

*1982*

## *Театр — заман көзгесе*

Татар дәүләт драма һәм комедия театры — республикабыз тамашачыларына, шулай ук башка автономияле республикалар, Урал, Оренбург, Әстерхан өлкәләре, Казакъстан, Азәрбайҗан, Урта Азия союздаш республикалары хезмәт ияләренә яхшы таныш булган, совет театр сәнгатен үстерүгә үзеннән лаеклы өлеш кертүче, үз йөзен булдырган коллектив.

1933 елда Татар дәүләт академия театры каршында күчмә колхоз филиалы оештырыла. Академия театрының төп иҗат көчләре «авыл театры» тудыру инициативасын зур шатлык белән каршылыйлар һәм аның нигезен салуда катнашырга зур теләк белдерәләр. Мәсәлән, филиал дәверендә куелган спектакльләрдә татар сәхнәсенең якты йолдызлары булган Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, шулай ук Колмәмәт, Мәҗит Илдар, Ибраһим Шәһдәлиев, Зариф Закиров актив катнашалар. Ә труппаның төп нигезен Мәскәү татар театрыннан кайткан артистлар тәшкил итә. Режиссер итеп Гали Ильясов билгеләнә. Мәскәү татар театрын оештыруда

актив катнашкан, аның сәхнәсендә озак еллар режиссер һәм актер булып эшләгән, югары театр белеменә ия булган Г.Ильясов Казанда яңа иҗат коллективын туплый.

Театр филиалының ачылу көне Бөек Октябрьнең 16 еллыгы бәйрәменә туры килә. Ул К.Тинчурин белән К.Нәҗминең колхоз төзелешенә багышланган «Булат бабай семьясы» спектакле белән ачыла. Спектакль беренче тапкыр 6 — 7 ноябрьдә Питрәч районының Шәле авылы колхозчыларына күрсәтелә. Шул чакларда, Казанда әле филармония булмаган бервакытта, театр каршында концерт-эстрада группасы оештырырга да мөмкинлек туа...

Коллектив, үзенең иҗади йөзен билгеләп, киң катлам тамашачыларның ихтирамын казанып, яңадан-яңа уңышлар яуларга омтылганда, Бөек Ватан сугышы башланып китә. Артистларның бер өлеше автомат алып фронтка китә. Яшь артистка З.Хәлиуллина, мәсәлән, Кызыл Байраклы зенит артиллериясе полкында хезмәт итә, ирләр белән бер сафта торып сугыша. Талантлы артистлардан Г.Зәйнуллин, Г.Хисаметдинов, Ф.Камал сугыш кырында батырларча һәлак булалар.

Сугышның беренче елларында театрга кечерәк күләмле пьесалар, концертлар куярга туры килә. Тора-бара коллектив зур күләмле әсәрләргә дә мөрәҗәгать итә башлый. Дәһшәтле сугыш елларында Х.Садрыйның «Партизаннар», Р.Ишморатның «Гөлзадә», «Кутуй», Ш.Мәҗитовның «Сөеклеләр» дигән пьесалары сәхнәгә менә.

Иҗат коллективының ялкынлы патриотик хисләре, фидакарь хезмәтләре сугышның иң авыр шартларында театрны таркалудан саклап кала. Әсгать Мәҗитов, Хан Исмәгыйлев, Газиз Гыйматов, Бибинур Галиуллина, Вера Минкина, Сәләх Сәгыйтов, Сафия Хөснетдинова, Асия Әхмәтҗанова һ. б. артистлар хак сүзне халыкка җиткерү, аны җиңүләргә рухландыру өчен бөтен көчләрен куялар. Аларга еш кына декорацияләрне тартып йөрергә, көненә 2 — 3 чыгыш ясарга, суык клубларда, кыр станнарында уйнарга туры килә.

Театрның шөһрәте республикабызның барлык районнарына тарала. Аның килүен һәр җирдә көтеп алалар. Нәтиҗәдә 1944 елның октябрь аеннан ул Татар дәүләт республика күчмә театры дип йөртелә башлый.

Сугыштан соңгы еллар театрның чын мәгънәсендә профессиональ коллективка әверелү еллары булып исәпләнәләр. Бу елларда аның иҗат йөзе тагын да ачыклана, спектакльләрнең сыйфаты күтәрелә. Труппага Совет Армиясеннән кайткан З.Хәлиуллина, З.Туишева, М.Хәмзин, Ф.Юнысов, Т.Кичубаев, Ә.Әбдерәшитов кебек сәләтле артистлар кушыла. М.Шаһидуллина, З.Камалова кебек яңа көчләр килә.

Театр үз репертуарын заманча проблемалар күтәргән әсәрләр белән баетырга тырыша. Мәсәлән, режиссер Г.Юсуповның «Тормыш җыры» (М.Әмир), «Украина далаларында» (А.Корнейчук) әсәрләре буенча куйган спектакльләре коллективның бу еллардагы зур иҗади уңышлары булып торалар. Шушы спектакльләр өчен театрга колхоз-совхоз театрлары смотрында беренче премия бирелә.

50 нче еллар башыннан алып Татар дәүләт республика күчмә театрының иҗаты белән республикадан читтә яшәүче татар тамашачылары да таныша башлый. Театрның гастроль маршрутлары Урал шәһәрләреннән алып Казакъстан далаларындагы чирәм җирләргә кадәр барып җитә.

1955 елны театрга баш режиссер булып Кәшифә Тумашева килә. Югары театр белеменә ия булган, режиссура өлкәсендә бай тәҗрибә туплаган, татар театр сәхнәсенә кадрлар әзерләү буенча үзен танытып өлгергән К.Тумашева коллектив алдына зур иҗади бурычлар куеп эшкә керешә. Бу елларда авторлар белән эшләү системалы төскә керә. Драматурглар Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Г.Насрый, Х.Вахит, Ш.Зәйни, Г.Минский, рәссамнар Ә.Тумашев, Ә.Нагаев, аннары Җ.Фәйзи, Х.Вәлиуллин, С.Садыйкова кебек композиторлар театрның иҗади эшендә актив катнашалар.

50 нче еллар ахырына театр югары профессиональ әзерлекле иҗат көчләре туплаган коллектив буларак танылa. Шунысы характерлы, труппадагы артистларның теоретик белемнәре һәм практик тәҗрибәләре бертигез булмауга карамастан, аларның барысын да актерлык осталыгын камилләштерергә өйрәнү, эзләнү, Станиславский системасына таянып иҗат итү теләге берләштерә.

1962 елдан алып бүгенге көнгә кадәр театрның баш режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Республиканың Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Тумашев төрле милләт халыкларының алтмышка якын әсәрен сәхнәгә куйды. Ул, күчмә театрның үзенчәлекле эш шартларыннан һәм аның иҗади состав мөмкинлекләреннән чыгып, һәрбер спектакльне профессиональ югарылыкта иҗат итәргә омтыла. Озак еллар дәвамында театрның директоры булган Мөхәммәт Хәмзин, 70 нче еллар уртасында аңа алмашка килгән Сәет Шәкүров иптәшләр театрыбызның традицияләрен баетуда, коллективны иҗади үстерүдә уңышлы эшләделәр.

Театр соңгы 10 — 15 елда үз драматургларын тәрбияләп үстерде. Бүгенге көндә киң катлам тамашачыларга танылып өлгергән байтак драматургларның әсәрләре беренче тапкыр безнең театр сәхнәсендә куелды. Аның Т.Миңнуллин,

И.Юзеев, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Р.Хәмид, Ә.Гаффар кебек драматурглары бар. Аларның әсәрләре тормышның үзе кебек чын, геройлары тамашачыны ышандырырлык итеп сурәтләнә. И.Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә» спектаклендәге урманчы Хәмзин образын, мәсәлән, һәр як тамашачысы: «Безнең авыл кешесе турындагы спектакль ич бу!» — дип кабул итте. Т.Миңнуллинның «Нигез ташлары»ндагы Гарифулла образы шулхәтле тормышчан иде ки, ул авторны соңрак Әлмәндәр кебек олы образ тудыруга этәрде.

Бу драматурглар белән театр үзенең иҗади планнарын бәйли. Ул алардан һәр сезонда яңа пьесалар көтеп алуы һәм аларны сәхнәләштерүе белән, бәлки, әлеге авторларны яңа әсәрләр иҗат итүгә рухландырыр. Театр өчен дә, авторлар өчен дә бу, һичшиксез, күңелле хәл. Чыннан да, берберсеңне тирәнтен аңлау, бер үк идеаллар белән рухлану һәркайсыбызның күңелендә зур канәгатьләнү тойгысы тудыра.

1979 елның апрель аеннан, ТАССР Министрлар Советы карары нигезендә, Татар дәүләт республика күчмә театры Татар дәүләт драма һәм комедия театры дип атала башлады. Театр коллективы бу вакыйганы партия һәм хөкүмәтебезнең иҗат кешеләре турында даими кайгыртучанлыгы итеп кабул итте. Бу бер үк вакытта катлаулы иҗат юлы үткән коллектив эшенә бирелгән зур бәя иде. Моңа бәйле рәвештә коллектив алдына яңа бурычлар да килеп басты. Югары идеяле, яхшы сыйфатлы спектакльләр тудыру бурычы иде ул. Һәм соңгы елларда мондый спектакльләрнең саны тагын да артты. Бүген репертуарыбызда заман проблемаларын күтәргән, төрле тема һәм жанрларда язылган егермедән артык әсәр даими уйнала. Алар арасында классика да, бүгенге тәҗрибәле драматургларның, шулай ук яшьләрнең яңа әсәрләре дә бар.

Театр авыл тамашачыларын идея һәм сәяси яктан тәрбияләүдә уңышлы эшләп килә. Ул ярты гасыр буе юлда. Елларның дәһшәтлесе дә, юлларның газаплысы да аны бу изге максатыннан аера алмады. Театр елына 500 — 550 спектакль күрсәтә икән, аның дүрт йөздән артыгы авыл тамашачылары алдында уза. Бу спектакльләрне 176 меңнән артык тамашачы карый. Үз нәүбәтендә авыл тамашачысы театрны, театр белән бергә артистларны үстерде, баетты. Коллективның авыл тамашачысы белән мөгамәләсе дусларча, һаман ныгый бара. Шуның нәтиҗәсендә коллектив республика, РСФСР, Союз театрлары арасында оештырылган социалистик ярышта һәрвакыт призлы урыннарны яулый. 1981 елның икенче яртыеллыгы, 1982 елның беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре буенча Бөтенсоюз социалистик ярышында безнең театрга 3 нче урын

бирелде. Коллективның күп кенә артистлары төрле медальләр, Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Театр үзенең 50 еллык юбилеена әзерләнгән репертуар белән Ташкент, Бохара, Сәмәрканд, Казан тамашачылары алдында иҗат отчетын уңышлы тапшырды. Алар тиздән илебез башкаласы Мәскәүдә уздырылачак гастрольләргә әзерлекнең җитди сынавы булдылар.

Драма һәм комедия театры үзенең илле еллыгына өлгергән, җитлеккән иҗат коллективы буларак килде. Алда аны шул ук җаваплы һәм мактаулы эш — авыл тамашачыларына мәдәният хезмәте күрсәтү эше көтә.

*1983*

## *Кама буе — туган як*

Фәтхерахман Әхмәдиев белән без бер районнан булсак та, яшьтән таныш түгел идек. Чөнки без хәзерге Балык Бистәсе районының ике чигендә туып үстек. Ә моңлы җырларын ишетеп белә идем инде. Хәер, бөтен Татарстан ул вакытта Фәтхерахман Әхмәдиев җырларын җырлый иде. «Кама буе — туган як», «Җәйнең матур аяз таңнарында», «Чистай вальсы», «Җырлыйм әнием турында», «Солдатлар», «Ромашкалар» дигән җырлар тиз арада популярлашып китте. Җыр сүзләренең авторлары да кемнәр бит — Хәсән Туфан, Роберт Әхмәтҗанов, Гөлшат Зәйнашева. Ә менә «Чистай вальсы» ның сүзләрен дә ул үзе язган булган икән. Клубларда шушы көйләргә вальс әйләнеп, җырлап үскәнгәме, Казандагы беренче очрашуда ук мин аны яратып, аңа тартылып калдым.

Фәтхерахман Әхмәдиев бигрәк тә шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов белән дус иде. Мин килгәнче дуслашып өлгергәннәр. Мин исә Казанга 1957 елда театр училищесында укырга дип килеп кердем. Торырга Бауман урамындагы бер әбигә урнаштык. И ул әбинең биек түшәмле, иркен бүлмәсендә очрашулар. Бөтен сәнгать дөньясы шунда җыела торган иде. Шагыйрь Рәшит Гәрәй, режиссер Рифкать Бикчәнтәев, артистлар Вәкил Закиров белән Фатыйх Колбарисовлар килә торган иде. Уртага 2 сум 87 тиенлек «тел ачкычы» куела. Мария түтәй бәрәңге пешереп бирә. Авылдан без китереп куйган иң зур байлык шул инде — капчык-капчык бәрәңге. Тыйнак табын янында әдәбият-сәнгать турында сөйләшеп, серләшеп туймый идек.

Беренче елны мин аларга бик катнашмадым. Шигырь язуымны да сиздермәдем. Бервакыт безнең янга кич утырырга, кыскарак буйлы, кара чәчле, таман гәүдәле бер егетне ияртеп, Ләбиб Айтуганов килеп керде. Чәчләре вакыт-вакыт

Такташныкы кебек сибелеп китә торган егет Фәтхерахман икән. Без якташлар булгач, бик тиз уртак тел таптык. Ул мине Сара Садыйкова җитәкчелегендәге хорга йөрергә күндерде. Фәтхерахман инде күпмедер вакыт музыка училищесында укып йөргән егет, ноталарны да белә. Шул түгәрәккә йөргәндә, ул минем шигырьгә «Минем өчен син генә» дигән җыр язып бирде. Шуны да нык кисәтте: «Флера Сөләймановага бир! Ул минем җырларны җырлый. Башкалар һәвәскәр композитор җырларын җырларга бик алынмыйлар», — диде.

Аннары тагын бер очрашу бик нык истә калган. Күпмедер еллар узгач инде бу. Минем теге «тел ачкычы»н авызга алмаганга 35 ел бит инде. Ул вакытта ук капмый башлаган идем. Җырчы Габдулла Рәхимкулов бригадасы белән Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылына барып төштек. Безнең белән баянчылар Гали Җәмлиханов, Мостафа Сәлахетдинов бар. Клуб янында безне Фәтхерахман Әхмәдиев каршы алды. Янында шахтадан кайткан абыйсы. Фәтхерахманның авызы ерык: «Әйдәгез сыйлыйм. Абыйның акчасы күп», — ди бу. Без җыйнаулашып елга буена төшеп утырдык. Аннары өйләренә мендек. Әнисе бик күркәм, иманлы карчык иде. Улының эчүенә эче пошып утырганы хәтердә.

Кичен концерт буласы. Фәтхерахман бәйләнде генә бит: «Мине дә җырлатыгыз», — ди. Габдулла Рәхимкулов курка. Казанга кайткач, тәртип бозган өчен кирәкне бирерләр, дип уйлый инде. Бигрәк тә художество җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗановтан шүрли. Мин исә Фәтхерахманны җырлату ягында. Тәки трико кигән, башына кепкасын кайтарып салган Фәтхерахман сәхнәгә чыгып басты. Кулында хромка гармун. Зал шыгрым тулы. Баянда уйный белсә дә, баян тотмый иде. Бер генә җыр җырлар да дәртен басар дип көтәбез. Юк бит, бер җырлый башлагач туктатып булмый гына бит Фәтхерахманны. Ул җырлый, халык елый, Рәхимкулов сәхнә артында тузына. Фәтхерахман: «Менә абыйга багышланган җырны гына җырлыйм да...» — дип әйтә дә яңа җырын җырлый башлый.

Халыкның аны үлеп ятканын шунда аңладым.

— Җырласын, төн озын бит! — дип кычкыралар...

Фәтхерахман зур сәнгатькә ныклап кереп китә алмады. «Берсут» ял йортына барып баянчы булып эшләп йөрде. Аннары Мәдәният министрлыгындагы Исмәгыйлев дигән кеше тырышлыгы белән яңа фатирлы булды. Әмма үзешчән композитор дигән ярлыктан котыла алмады.

*1995*

## Узган гомер — калган хәтер

Алтмышынчы еллар ахыры. Минем яңа гына мәктәпне тәмамлаган чаклар. Якты хыялларга омтылган яшьтәшләрем, укуларын дәвам итеп, педагогия училищесына керергә җыеналар. Мин, сыйныфташларымнан аермалы буларак, бераз каләм дә тибрәткәлим. Район газетасында «әсәрләрем» дә басылып чыга. Күрше Иске Арыш авылы егете Роберт Әхмәтҗановтан көнләшә-көнләшә мин дә каләм чарлыйм. Хыялым Казан университетына яки педагогия институтына укырга керү. Татар бүлегенә. Казанга килеп документларны нинди уку йортына тапшырырга икән дип йөргәндә, кинәт урамдагы бер игъланга күзем төште. В.И.Качалов исемендәге Дәүләт зур академия театры каршында яңа студия ачыла һәм шуның татар төркеменә яшь артистлар кабул ителәләр икән. Күңелемнең әллә кайсы бер почмагы тетрәнеп куйды. Сәхнә дигән серле дөнья миңа чит-ят түгел иде. Сабакташым Хәлим Җәләй белән сәхнә тузанында аз аунамадык. Хәтта 1957 елда район үзәгендә үткәрелгән үзешчән сәнгатьтә катнашучылар бәйгесендә җиңеп чыгып, Казанда да чыгыш ясаган идек. Шулай итеп, бәхетне сынап карарга булдым. Дустым Наил Шакиров белән училищега юл тоттык. Өстә ак күлмәк, модный вельвет чалбар.

Беренче имтихан тапшырасы көн. Хал-ы-ык! Татар төркеменә конкурс: бер урынга 20 кеше икән. Киң балаклы чалбарын җилфердәтеп, диңгез флоты тельняшкасын кигән озын буйлы чибәр Ирек Баһманов йөри. Зур ап-ак бантикларын таккан Наилә Гәрәева ут борчасы кебек баскан җирендә бии. Коеп куйган артистка инде менә. Укытып та торасы юк үзен. Тик мин аны баштарак нишләптер, бәләкәйрәк буйлы булгангадырмы, берәрсенең ияреп килгән кызы түгелме икән, дип уйлаган идем. Вадим Кешнер бик эшлекле кыяфәт белән имтиханга керүчеләргә ишек ачып тора. «Ялагайлануыдыр инде. Болай булса, кабул итәрләр үзен»,— дип уйлап куйдым эчемнән генә.

Тирә-якта кайнап торган ыгы-зыгыга карап тордым-тордым да, авыр көрсенеп, Наилгә ишарәләдем:

— Әйдә, Наил, киттек! Безгә монда делать нечего!

Шулай да теләк зур булу үзенекен итә икән ул. Мин дә, дустым Наил дә театр студиясе студентлары булып киттек. Унике егет һәм кыз кабул ителде татар төркеменә.

Менә шуннан соң 40 ел гомер узган да киткән. Шул чор эчендә тормыш сәхнәсе һәркемне үз күчәрендә әйләндерде: кемнәрнедер күкләргә чөйде, кемнәрдер үз язмышлары белән ризалашты.

Һәркем үз язмышына үзе юл салган. Әлмәт егете Ирек



М.Шиһапов — театр студиясе шәкерте. 1957

Баһманов арабызда иң өлкәне, укырга кергәндә аңа инде 26 яшь иде. Ул башта Әлмәттә нефтьче, механик була һәм Казанда танк училищесында эшли. Армия хезмәтен үтә. «Яше шактый олы, алыргамы, юкмы?» дигән сөйләшү дә булып алган кабул итү комиссиясе әгъзалары арасында. Ләкин озын буйлы чибәр егетне кабул итми булдыра алмаганнар. Өстәвенә өздереп гармунда да уйный, җырлый да. Киләчәктә Татарстанның халык артисты, Г. Камал театры йөзек кашларының берсе буласына ялгышмаганнар икән.

Рәсим Сәлахов та, Ирек кебек үк, шактый тормыш тәҗрибәсе туплап килде студиягә. Ул Казандагы С.П.Горбунов исемендәге заводта эшли. Әлеге заводта оештырылган, Рифкать Бикчәнтәев җитәкләгән халык театрына йөри. Инде студия-



Сабакташлар (язма шулар хакында)



Беренче спектакль, беренче рольләр...

гә керү имтиханнары тапшырылып бетүгә карамастан, Р.Бикчәнтәев аны Г.Камал театрына алып килә. Театрның режиссеры Хәким Сәлимҗановка күрсәтеп карый егетне. Актер осталыгы буенча гына имтихан тотарга туры килә аңа.

Казанда рус мәктәбен тәмамлаган Наилә Гәрәева, нишләсен, башта рус төркеменә укырга керергә ниятли. Студиянең сәнгать җитәкчесе Ширияздан ага Сарымсаков театр дөньясына бөтен җаны-тәне белән бирелгән, күбәләктәй талпынган талантлы татар кызын күреп ала да аның милли кылларына кагыла. Наилә Ширияздан ага белән ризалашмыйча булдыра алмый. Аның өйрәнчеклек чоры булмады да кебек. Ул сәхнәгә тиз аяк басты. Инде икенче курста укыганда ук, Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендә Рәхилә образын тудырып, тамашачыларның мәхәббәтен яулады, үзен өметле артистка итеп танытты. Чөнки театрның яшь артистларга кытлык кичергән чаклары иде. Щепкинчылар әле Мәскәүдә. Аларның көчле ташкын булып кайтып төшеп, театрны буйсындырасыларына шактый вакыт бар. Шуңа күрә Наилә Гәрәева, щепкинчылар кайтканчы, үзен күрсәтергә өлгергән иде. Ул Республикабызның Г.Тукай бүләген дә бик яшьли — 1967 елда Чыңгыз Айтматов әсәре буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә Әсәл образын тудырганы өчен алды. Күпме генә

гыйшык тотып йөрсәм дә, Наилә кабатланмас талант иясе булган Р.Бикчәнтәевне сайлады.

Наиләгә күпме генә гашыйк булсам да, үземнең шигъри юлларымны нишләптер Гөлшат Байбичевага багышлаганмын:

Экзаменда күрдем, сәлам бирдең,
Якын итте сине йөрәгем.
Ә бүген мин синең белән бергә
Хыял диңгезендә йөзәмен...

Икенче курста укыганда язылган әлеге шигырьне Гөлшат гомере буе кадерләп саклаган. Күптән түгел ул аны Актерлар йортында булган очрашуга алып килгән иде. Гөлшатның әтисе Ибраһим Байбичев заманында күчмә театрда актер, режиссер булып эшли. Гөлшат та, Наилә кебек үк, татар телендә иркен сөйләшә алмагач, башта рус төркеменә укырга керергә уйлый. Соңыннан барыбер татар төркеме студенты



Язучылар арасында



Сабакташлар 40 ел узгач... 1997

булу бәхетенә иреште. Шулай да аңа татар театрында эшләргә насыйп булмады. Ул гомере буе Сахалин драма театрында эшләде. РСФСРның атказанган артисты исеменә лаек булды. Күптән түгел гаиләсе белән бөтенләйгә туган Казанына әйләнеп кайтты.

Бүтәннәр, шул исәптән мин дә, актер булып китмәдек. Нишлисең, язмыш дигән кырыс хөкемдарга каршы барып буламы соң?! Ләкин, ни генә булмасын, без татар мәдәниятенә хезмәт итүдән читкә тайпылмадык. Флера Әхмәтшина (хәзер Бикмурзина), мәсәлән, телевидение юлын сайлады, бүген «Татарстан» телекомпаниясендә режиссер хезмәтен башкара, Татарстанның халык артисты, Россиянең сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.

Әле дә бер вакыйга хәтеремдә. Флера үзе дә бу хакта еш искә ала. Кабул итү имтиханнарын тапшырып йөрибез. Флера — авыл кызы. Сабыр. Итагатьле. Тыйнак кына киенгән. Шунда бер түрә кызы Флерага көлемсерәп карады да: «Һе, шушы музей экспонаты да артистка булырга килгән», — дип әйтеп ташлады.

Шунысы кызык: Флераны студиягә кабул иттеләр, ә теге кызыкай күз яшьләренә буылып кайтып китәргә мәҗбүр

булды. Казан университетының юридик факультетына укырга керәм дип йөргән кызның язмышы көтмәгәндә театр студиясе белән бәйләнде. Флерага сәхнә тормышында зур өметләр баглыйлар иде. Ул инде студент елларында ук сәхнәдә шактый гына образлар тудырырга өлгерде. Хәтта СССРның халык артистлары Хәлил Әбҗәлилов һәм Шәүкәт Биктимеров белән бер сәхнәдә уйнады. Телевидениегә эшкә китеп берничә ай үткәч тә түзмәде, яңадан театрга әйләнеп кайтты. Ләкин... Флераның үз сүзләре белән әйтсәк, театр шаулы дулкыннар гына булса, телевидение көчле океан ул. Әнә шушы мәгърур океан аны үз кочагына суырып алды.

Студияне тәмамлагач, Диләрә Ильясованы, Наил Шакировны, Рәүф Зәйнуллинны һәм мине күчмә театрга билгеләделәр. Күчмә театрның тәгәрмәчләр өстендә гомер кичергән чаклары. Артист тормышы бал да май гына түгел икән шул.

Д.Ильясова белән Н.Шакиров бүтән юлны сайладылар — нәфис сүз осталары булып киттеләр. Д.Ильясова студиягә Минзәлә, Әлмәт театрларында эшләп килгән иде. Укыганда ук М.Кәримнең «Кыз урлау» әсәрендә — Мөнирә, Ф. Әмирханның «Яшьләр» спектаклендә Зөһрә рольләрен иҗат итте. Диләрә гомере буе сәхнәдән аерылмады — филармониядә нәфис сүз остасы булып эшләде. Иң мәртәбәле җырчыларның концерт программаларын алып барды. Сәхнәдән талантлы язучыларның әсәрләрен укып, халыкның зәвыгын тәрбияләде.

Студияне тәмамлагач та күбебез укуны дәвам иттек: югары уку йортларында белем алдык. Гөлшат Бикмурзина белән Эсфира Булатова педагогия институтының чит телләр факультетында укысалар, Диләрә Ильясова белән Луиза Яруллина университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамладылар. Ә мин — журналистика факультетын. Эсфира Булатова дигәннән, ул М.Җәлилнең көрәштәше Фоат Булатовның кызы, бүген Польшада — Варшава университетында инглиз теле укыта.

Луиза Яруллина озак еллар «Социалистик Татарстан» газетасының хатлар бүлегендә эшләде, соңрак мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытты. Композитор Мирсәет Яруллинга кияүгә чыгу, күрәсең, аның башын тәмам әйләндергән — хәтта язмыш елгасын да бүтән юлга алып кереп киткән.

Мин үзем дә сәнгать дөньясыннан китмәдем. Гомерем буе җитәкче урыннарда эшләдем. Җаным кушканга, йөрәгем сораганга шигырьләр яздым. Композиторлар белән берлектә иллегә якын җыр иҗат иттек.

Без шуның белән горурланабыз: Шириаздан Сарымсаков, Хөсәен Уразиков, Празат Исәнбәт, Габдулла Шамуков кебек гаҗәеп талантлы һәм олы җанлы шәхесләр укытты безне.

Студиянең нәкъ менә Качалов театры каршында оештырылуы безнең өчен зур бәхет булды. Чөнки без бер үк вакытта рус театры традициясендә дә, татар театры гадәтләрендә дә тәрбияләндек. Сабакташларыбыз, бүген В.И.Качалов театрында эшләүче Ю.Федотов, В.Кешнер, И.Черновина, Е.Кузин, Ю.Маклакова кебек актерлар белән бергә укуыбыз гомер юлыбызда якты сәхифәләр калдырды. Кем ышаныр, әгәр шушы мәртәбәле актерлар кайчандыр имтиханнар вакытында безгә, авылдан килгән татар егет һәм кызларына, кушаяклап шпаргалка кертәләр иде, дисәк...

Узган гомер — калган хәтер. Бүген инде арабыздан вакытсыз киткән Рәүф Зәйнуллин белән Флера Мәрдәнованы сагынып кына искә алабыз.

*2001*

## Мин шуңа сөенәм...

Без, сугыш алдыннан туган балалар, бик күп нәрсәдән мәхрүм булып үстек. Ачлыкны да, ялангачлыкны да татыдык. Бик яшьли «тәртә арасына» кереп, зурлар белән тиң эшләп үсәргә дә туры килде безгә. Шул ук вакытта бик гыйбрәтле, сугыштан соңгы рухи бер күтәрелеш чорына да туры килгәнбез икән ләбаса. Зурлар да, кечеләр дә олы бер дәрт белән яшәргә омтылган чак иде ул. Өметләр зурдан, хыяллар чиксез... Әйе, сугыш дәвере авырлыклары әкренләп артта калган, тормыш көннән-көн яхшыра барган чак. Шәһәр тормышын бик үк белмим, әмма авылда ниндидер бер күтәренке рухи халәт тоемлана иде. Авыл клублары гөрләп эшләп тора, авыл халкы эштән соң шунда җыела иде. Рухланып төрле уеннар уйный, җырлый торганнар иде. Казаннан концерт бригадалары килә, театр коллективлары да күренгәләп китә иде. Шул арада авыл яшьләре үзләре дә, театр уеннары уйнап, тамаша ясап алалар.

Илленче еллар урталарыннан мин Балык Бистәсе районының данлы Олы Солтан авылы урта мәктәбендә укыдым. Мәктәптә һәм авыл клубында укытучыларыбыз оештырган «һәвәскәр артистлар» арасына безне, өлкән класс укучыларын да «тартып» кертәләр иде. Сәнгатькә, театрга карата булган мәхәббәтебез шул елларда бөреләнде. Олы Солтан

мәктәбендә бер чордарак укыган иптәшләремнән Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләлев кырык елдан артыграк гомерләрен театр сәнгатенә багышладылар. Аларның Татарстанның халык артисты дигән дәрәҗәле исемне алуларына да байтак вакыт үткән инде.

Мин дә артист булу хыялы белән В.И.Качалов исемендәге Зур драма театры студиясенә укырга кердем. Театр училищелары программасы нигезендә укыттылар безне. Ирек Баһманов, Наилә Гәрәева, Рәсим Сәлахов — сабакташларым. Мин 1961 елда аны тәмамлап, Республика дәүләт күчмә театрында эшли башладым. Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт», Габдрахман Минский инсценировкасында куелган «Тапшырылмаган хатлар», Әсгать Мирзаһитовның «Әниемнең чал чәчләре» һ.б. пьесаларда уйнау бәхетенә ирештем.

Нәкъ шул илленче еллар урталарында драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе Кәрим Тинчурин исеме халыкка кире кайтарылды. Театрларда аның пьесалары кабат уйнала башлады. Академия театрында бер-бер артлы аның «Зәңгәр шәл», «Американ», «Казан сөлгесе», «Җилкәнсезләр», «Сүнгән йолдызлар» кебек халкыбызның тормыш-көнкүрешен төрле яклап чагылдырган үлмәс әсәрләре куелды. Безнең Күчмә театрда аның «Сакла, шартламасын!» исемле кызыклы пьесасы 1956 елда куелган иде. Кәрим Тинчурин исеме шул еллардан бирле безгә якын. Академия театрының шул еллардан бирле яңа сезонны күренекле авторның мәшһүр «Зәңгәр шәл»е белән ачу традициясе дә ул якынлык хисен көчәйтә генә иде.

Үземнең яшьлек елларыма бәйле булган Күчмә театрның оешкан дәвердә үк иң беренче нәүбәттә Кәрим Тинчурин белән Кави Нәҗми тарафыннан иҗат ителгән «Булат бабай семьясы» пьесасына мөрәҗәгать иткән булуы да күңелемә бик якын. Шул театрның директоры булып эшләгән сиксәненче елларда миңа театрның илле еллык юбилей тантанасын оештырырга туры килгән иде. 1983 елда шул юбилейга багышлап матур гына китапчык та чыгардык. Шул китапның «Фотоларда — театрның тарихы» бүлеге Кәрим Тинчурин һәм Кави Нәҗми портретлары һәм «Булат бабай семьясы» пьесасы афишасы белән ачыла (ул әсәрне сәхнәләштерүче режиссер Гали Ильясов була).

Күчмә театрга җитәкче итеп билгеләнүемнең беренче көннәреннән үк мин аның категориясен күтәрү мәсьәләсен кузгаттым. 1979 елның апрель башында ул ТАССР Министр-

лар Советы карары белән Татар дәүләт драма һәм комедия театры дип үзгәртелде. Шул үзгәреш алдыннан мин кайбер җитәкчеләребез алдында театрга Кәрим Тинчурин исемен бирү турында да сүз кузгаткан идем. «Яңа алынган дәрәҗәңне акла әле, киләчәктә күз күрер», — дигәнрәк җавап алган идем. Шөкер, театрга ул исем беркадәр соңлабрак булса да бирелде. Шуңа мин бик сөенәм.

*2002*

## Яңа йортта яңа хуҗа

Җәй башында шаулатып-гөрләтеп, зур сөенечләр, олы өметләр белән консерваториянең Концерт залы дигән гүзәл бинаның ачылуын бәйрәм иткән идек. Атна буе концертлар барган иде. Залда затлы музыка яңгыраганда, кулуарларда шом катышкан бер хәбәр шуышып йөрде:

— Алалар икән бу залны консерваториядән, Казан мэры күз салган, ди.

— Ә нигә, бизнес әйләндерү өчен бөтен шартлар бар монда.

— Алай булса, чабаталы халык бу залга аяк баса алмас инде. Үтә затлы бит.

Чышын-пышын сөйләшкән сүзләр йомгагы ни дәрәҗәдә зураеп китәр иде — анысын юрамыйк. Иң мөһиме — нокта куелды. Татарстан Министрлар Кабинетының 1996 елның 10 июль карары белән консерваториянең яңадан торгызылган концерт залы базасында Татарстан Республикасының Дәүләт Зур концерт залы булдырылды. Яңа залның директоры итеп танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Мансур Әхмәт улы Шиһапов билгеләнде.

Мөстәкыйльлек алган яңа залның яңа хуҗасы белән очрашып сөйләштек.

— *Язучылар берлегендә әйбәт кенә эшләгән җирдән яңа урынга күчеп утыруның сәбәбе ни?*

— Без куган җирдән кит, чакырган җиргә бар, дип тәрбияләнгән буын. Минем кайда күбрәк файда китерә алуымны белүчеләр бар икән. Бу юлы хөкүмәт ихтыяҗы белән минем теләк тәңгәл килде. Бу күз алмасыдай кадерле залны, бу гүзәллекне саклап тотар өчен яңа коллектив туплап, яңа эшләр башлап җибәрү өчен театрлар белән эшләү тәҗрибәсе булган кеше кирәклеге мәгълүм бит инде. Мин шундый кеше. 16 яшемнән сәхнәдәмен. Курчак театрын, Күчмә театрны җитәкләдем заманында.



Мансур Шиһапов

— *Дәүләт Зур концерт залы, дип әйтү бик горур яңгырый. Турыдан-туры Президентка буйсынуны аңлатамы әллә бу?*

— Безнең бу зал Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагында һәм аның үз мөстәкыйль балансы бар. Зал юридик зат хокукларына ия. Хөкүмәт бу Концерт залына тернәкләнеп китү өчен мөмкинлекләр тудырды. Әйтик, 1996—1997 елларга без һәртөрле салымнардан һәм республика бюджетына өлеш кертүләрдән азат. Җирле бюджетка салымнардан да баштагы чорда азат булырбыз.

— *Алаен алай да. Зур тантаналар үткәч кенә бу залны консерваториядән «тартып алуны» ничек аңлыйк икән?*

— Тартып алу, дип кистереп әйтү дөрес булыр микән? Консерватория студентлары бу залга дәресләргә йөриләр. 1 сентябрь көнне аларны ишек төбенә чыгып мин үзем каршы алдым, залга кадәр озатып куйдым. Киләчәктә дә хадимнәр студентларны каршылап, озатып торачак. Сентябрьдән, студентлар хакына дип, ике сменалы эшкә күчтек, һәртөрле концертлар, зур исемле башкаручылар килгәндә, студентлар өчен бушлай урыннар калдырылачак.

Ә Зур концерт залының административ һәм финанс мөстәкыйльлеге бик кирәк нәрсә. Беренчедән, Татарстан хөкү-

мәте шушы мәһабәт сәнгать сараен бина кылу өчен гаять зур сумма сарыф итте. Казан мэры Камил Исхаков та биредә һәр көнне планеркалар үткәрә иде. Хөкүмәт җитәкчеләре дә игътибардан ташламады. Инде шундый зур тырышлык белән салынган бинаны тәгаен бер хуҗасыз калдыру хафасызлык булыр иде. Студентларны беләсез бит, затлы мәрмәр диварга «Валя + Петя» дип язып кую алар өчен берни тормый. Иясез калдырсаң, мондагы затлы җиһаз бик тиз таралып бетәр. Күрегез бу урындыкларны гына! Мин аларга үзем дә утырырга куркып йөрим әле.

Финанс ягы да бар. Ни дисәң дә, Рәсәй бюджетындагы консерватория 80 мең тәңкәгә эшләп йөри, ә безгә 230 мең билгеләнде. Дәүләт күләмендә әһәмиятле Концерт залын хөкүмәтебез тиешенчә финанслый алыр дип ышанам. Аннары бит Татарстан хөкүмәтенең килгән кунакларны тиешле дәрәҗәдә кабул итү урыны булу һич тә начар түгел.

— *Штат зур булыр кебек.*

— 150 кешедән торган коллектив, махсус службалар булачак. Әйтик, җиде инженер-механик кына бар. Махсус сак егетләре залны һәм тамашачыны саклаячак, милли киемле кызлар кунакларны залга үткәреп, каршылап торачак.

— *Тагын нинди хикмәтләр?*

— Татар халкында күркәм гадәт бар — килгән кунакны чәкчәк белән каршылыйбыз. Безнең Концерт залының үз «чәкчәге» булыр. Җыр-музыкамы, ядкарь-бүләкме, ни буласы әлегә сер. Алмаш аяк киеме белән йөрүне мәҗбүри итмәгәек әле. Чәчәк кибете эшләп торыр. Телефон-автоматларны бушлай итәбез. Кыскасы, тамашачы бу залда үзен иркә кунак итеп тояр. Әнә, әле үк күрәсездер, без җыештыруюуны урамнан ук башлыйбыз. Чит илдәгечә.

— *Бәлки, татардагыча дию дөресрәктер. Кунаклар сыйфатында күбрәк кемне күзаллыйсыз? Элитанымы?*

— Тамашачы кунак — музыка яраткан һәр кеше. Элита да йөрсә, шулай ук начар булмас. Артист, музыкант кунакларны исә бөтен илдән һәм чит илләрдән көтәбез.

— *Гастролерлар гына кабул итәргә ниятләүме бу?*

— Юк, туган. Беренче нәүбәттә мин монда шушы Казан консерваториясен тәмамлап, сәнгатьтә казанышларга ирешкән башкаручыларны тыңларбыз дип уйлыйм. Ләкин менә репертуар классик сәнгать әсәрләренә нигезләнер. Шушы залда татар сәнгате елгасы дөнья сәнгате диңгезенә кушылыр.

*— Киресенчә, дөнья сәнгате, музыкасы, ишек шакып кына, татарның нечкә зәвыклы моң дөньясына керергә омтылыш ясап карасын иде ул. Татарстан дәүләт симфоник оркестрының бу залда «штатта калуы» да сөендерә. Ринат Халитовның дөньякүләм шөһрәт казанган, халкыбыз исә бик тә ярата торган ансамбле дә хуҗалар исемлегенә керер дип өметләник.*

— Шутиков оркестры да бездә. Яңа орган куячакбыз. Иске орган Чаллыга китәчәк. Хыяллар күп. Иң мөһиме — үз йөзебезне табу.

*— Бу залда чыгыш ясарга теләүчеләрдән заявкалар килә башлаган икән. «Музыка академиясе» концертлары өчен билетлар сатыла. Димәк, стартка баскансыз.*

— Татарстан Республикасы Зур концерт залын рәсми тәкъдим итү декабрьгә билгеләнгән. Концерт сезонын исә 13 сентябрьдә Татарстан симфоник оркестры ачып җибәрәчәк. Дөресрәге, оркестр үз сезонын безнең залда башлый.

*Әңгәмәдәш — Асия Юнысова*
*1996*

## Башкалабызның сәнгать йөрәге

Башкалабызның Ирек мәйданы сәяси ыгы-зыгылар кайнаган урын гына түгел, ә зур сәнгать йөрәге типкән үзәк тә. Чөнки биредә урнашкан Татар дәүләт опера һәм балет академия театры һәм Зур концерт залы Россиянең һәм дөньяның мәшһүр сәнгать осталары туктала торган йолдызлыкны хәтерләтә. Бүгенге сүзебез Зур концерт залы турында. Казан түрендәге сәнгать таҗының ачылуына күптән түгел биш ел тулды. Зур концерт залы директоры — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрь Мансур Шиһапов белән әңгәмәбез әлеге мәдәният учагының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшүдән башланды.

— Башкалабызда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы ачылу республикабыз тормышында олы вакыйга булды,— дип сүзен башлады Мансур Әхмәт улы.— Шул дәвердә ул республиканың мәдәни тормышындагы нинди генә күренекле вакыйгаларның шаһиты булмады: опера йолдызлары концертлары, мәшһүр дирижерлар, виртуозлар чыгышлары, конкурслар, фестивальләр, атаклы композиторларыбызның юбилей тантаналары. Зур концерт залы хәтта иҗтима-

гый-сәяси тормышыбызның үзәгенә әверелде. Икенче Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Президенты инагурациясе, хатын-кызлар арасында дөнья беренчелегенә шахмат чемпионаты, җәмәгатьчелекнең В.Путин белән очрашуы кебек әһәмиятле тантаналар барысы да биредә үткәрелде.

Ул үзенең затлылыгы, тамашачыларны кабул итү өчен бөтен уңайлыклар тудырылуы белән хәтта Россия күләмендә беренчеләрдән санала. Биредә чыгыш ясаган чит ил һәм Россиянең атаклы сәнгать осталары тарафыннан теләкләр-тәкъдимнәр кенәгәсенә язып калдырган фикерләр әнә шул хакта сөйли.

Биш ел гомер... Тарих өчен ул әллә ни вакыт аралыгы да түгел. Ләкин шундый абруйлы залның аякка басып, үзенең эшчәнлеген башлап җибәрүе өчен зур сынау чоры булды ул.

— *Мансур әфәнде, бер мәгълүм шагыйрь сүзләре белән әйтсәк, әйдәгез, Зур концерт залының тарихына ераккарак китеп карыйк әле. Мөгаен, татарның аны бөтен тарихы буенча бәхетсез иткән гомерлек бәласедер: нинди генә эшкә алынмасын, Крылов мәсәлендәге кебек, үзара тарткалашу, бүлешү башлана. Зур концерт залы белән дә шулай булды кебек...*

— Мәгълүм булганча, ул элек Казан дәүләт консерваториясе карамагындагы актлар залы корылмасы нигезендә төзелде. Шуңа күрә әлеге уку йортының җитәкчелеге аны үз канаты астына алырга теләде. Бу хакта хәтта республика җитәкчелегенә мөрәҗәгать белән дә чыктылар. Янәсе, залны Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагына күчереп зур хата эшлиләр. Янәсе, аның белән югары сәнгатьне, академик концерт залы функцияләрен аңлаудан ерак торган очраклы кешеләр идарә итә. Янәсе, ул, эшләр шулай барса, тиздән нindидер бер өяз шәһәренең клубына әйләнәчәк, данлыклы Опера һәм балет театры кебек үк шоу-программалар, узгынчы эстрада артистлары концертларын үткәрү өчен файдаланылачак.

Еллар узды. Бүген инде вакыт әлеге низагларның, борчу-мәшәкатьләрнең урынсыз икәнен тагын бер кат раслады. Президентыбыз М.Ш.Шәймиевнең, шулай ук мәдәният министры И.Г.Тархановның тоткан кыйбласы дөрес һәм тотрыклы булып чыкты.

Барлык югары уку йортлары кебек үк, консерватория Россия бюджетыннан финанслана. Ул бүген хәтта үзен дә

тиешенчә тәэмин итә алмый. Әнә күрегез, анда инде ничә еллардан бирле ремонт эшләре дә үткәрелмәгән. Ә Зур концерт залы елдан-ел үзенең барлыгын ныграк сиздерә бара.

Зал бик кыска вакыт эчендә — ел ярым дәвамында файдалануга тапшырылды. Ул, гүзәл архитектура истәлеге буларак, Ирек мәйданының ансамблен тагын да баетып, бизәп, камилләштереп җибәрде.

*— Сез шагыйрь. Халыкка үзегезнең популяр җырларыгыз аша яхшы таныш. Шулай ук сезне республикада сәләтле оештыручы, уңган хуҗа буларак та хөрмәт итәләр. Шуңа күрә хөкүмәт җитәкчеләре Зур концерт залы директоры вазифасын сезгә ышанып тапшырдылар.*

— Ходай кушкандыр, хуҗалык эшләрен белгән һәм сәнгатькә якын кеше буларак, шундый абруйлы мәдәният учагының беренче директоры «йөгәнен кию» миңа насыйп булды. Мин аңарчы Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары вазифасын башкардым. Минем өчен Зур концерт залы ул иң элек тынгысыз хуҗалык хезмәте. Заманында төзелеш кирәк-яраклары, җиһазлар барысы да Англиядән кайтарылган иде. Корылманы ашыгып тапшыру аркасында күп кенә ремонт эшләрен кабат яңартырга, хәтта түбәнең күп өлешен яңадан ябарга туры килде. Чит илдән кайтарылган парогенераторлар да тиз сафтан чыга иде. Уйлаштык та аларны үзебездәге авиация заводында җитештерергә булдык.

Залның берьюлы ике «хуҗа»га буйсынуы күп кенә эшгамәлләрне башкарганда кулны бәйли. Чөнки бүгенгәчә, Министрлар Кабинетының махсус карары булуга карамастан, күп кенә җиһазлар консерватория балансында хисаплана.

*— Бүген күп кенә мәдәният учаклары бушап калды. Икътисади кыенлыклар тамашачыларга иркенләп хезмәт күрсәтү мөмкинлеге бирми. Сезгә мондый куркыныч янамый бугай?*

— Татар дәүләт филармониясе үзенең концерт залын ачкач, күпләрне зал бушап калыр дигән шикле уйлар биләп алган иде. Ләкин мондый сагаюлар артта калды. Бездә ай саен 30—34 концерт үткәрелә. Филармония дә иң әһәмиятле концертлары өчен Зур концерт залын сайлый. Ә бинадан файдаланган өчен түләү чагыштырмача очсыз. Бюджет оешмалары өчен ул бары тик биш мең сум гына тәшкил итә. Әлбәттә, яшел ут бары тик зур сәнгать осталарына гына.

*— Мансур әфәнде, шундый мәртәбәле сәнгать учагының үз иҗат төркеме булмау сезне борчымыймы? Күп ке-*

*нә республика концерт залларының андый иҗат төркемнәре бар бит.*

— Сез нәкъ мине борчыган мәсьәләгә кагылдыгыз. Моңарчы бездә өч ел дәвамында филармониянең халык музыка уен кораллары оркестры шөгыльләнде. Филармониянең концерт залы ачылгач, алар биредән китәргә булдылар. Минемчә, шундый мәртәбәле концерт залының үз иҗат төркеме булырга тиеш. Якын киләчәктә үзенең солистлары белән Президент оркестры оештырылса, бу Зур концерт залы өчен генә түгел, ә бөтен татар мәдәнияте өчен олуг вакыйга булыр иде.

*— Заманында консерваториянең ректоры Рубин Абдуллин, студентлар биредә шөгыльләнүдән мәхрүм калачаклар, дип, тирән борчылуын белдергән иде...*

— Алдарак әйткән идем инде, Рубин әфәнденең шик-шөбһәләре урынсыз булып чыкты. Консерватория студентлары бөтен мөмкинлекләре тудырылган залда көннәр буена шөгыльләнә, югары музыка серләренә өйрәнә, башкалабыз тамашачыларына ай саен дистәгә якын концерт программасын тәкъдим итә. Әлбәттә, барысы да түләүсез.

*— Казан түрендәге сәнгать таҗы булган Концерт залында горурланып телгә алырдай нинди мәшһүр сәнгать осталары чыгыш ясады?*

— Республикабызның мәдәни тормышында мөһим урын тоткан, милли рух белән өртелгән бу залда нинди генә мәшһүр сәнгать осталары чыгыш ясамады?! Казан тамашачылары биредә нинди генә югары сәнгать әсәрләрен тыңлап ләззәтләнмәде: Владимир Спиваков, Михаил Плетнев, Олег Лундстрем, Татьяна Шмыга, Ольга Янченко, Владимир Третьяков, Николай Петров, Зураб Соткилава, Мөслим Могомаев...

*— Мансур әфәнде, мең төрле киртәләр, борчу-мәшәкатьләр, иҗади эзләнүләр белән үткән биш ел гомер артта калды. Биш ел, ни булса да, кечкенә генә бер юбилей ул. Үзегезнең шатлык-куанычларыгызны тамашачылар белән дә уртаклашырга теләмисезме?*

— Әйе, андый ниятебез бар. Тиздән, 23 ноябрь көнне, әлеге вакыйганы билгеләп үтәргә җыенабыз. Анда республикабызның сәнгать осталары белән беррәттән Европа сәхнәләрен яулаган Любовь Казарновская, Важа Чачава кебек сәнгать осталары да катнашыр дип көтелә.

*Әңгәмәне Рәмис Аймәт үткәрде*
*2001*

## *Казаным, Казаным...*

Мин Казанның 1000 еллыгын ничек күрергә телим? Мин Казанга 1957 елны килдем. Казан театр училищесына имтиханнар тотып, сынауны үтүгә, башкала белән якыннан танышып чыгарга булдым. Казан минем күңелдә ничек сакланган?

Башкала, иске йортлардан торса да, гел яшеллеккә күмелгән иде. Казан җиренә беренче тапкыр аяк басуга, вокзал каршындагы бакчага кереп югалдым. Ул гүзәл бакча бал исе аңкытып торган мәһабәт биек юкәләрдән гыйбарәт иде. Авылымны сагынган малай күңелендә ул миңа безнең якның Урай авылын хәтерләтте. Кечкенә генә бакчага кереп китсәң, югалып калырлык иде. Вокзал бинасы өстендә кызыл байрак җилферди. Җил белән серләшә. Бакча уртасындагы һәйкәл төбенә утырып, юкә исенә кушылып, моңзарларга, сагышларга чумып, хәтта кечкенә генә шигырь дә яздым. Ул «Казанның тарихи вокзалы» дип атала иде.

Җидегән йолдыз күк җемелдәп,
Нур сибә чал шәһәр байрагы.
Тукайча дәртле син, нурлы син,
Казанның тарихи вокзалы.

Вокзалдан мин пляжга керә торган юл белән Идел ярына чыктым. Идел яры буйлап тезелеп киткән исең китәрлек яшеллек миңа тагын каләм алырга ярдәм итте.

Толларның күз яшен яшергән,
Сагышлы Иделнең чал яры.
Җиңүләр маршына кушылып
Җырлыйлар Кремль чаңнары.
Кемнәрне юксынып елыйсың,
Казанның тарихи вокзалы?
Бәхетле яшьлекне яшьнәткән,
Әй гүзәл башкалам таңнары.
Яңарган азаннар милләтнең
Үткәнен, иманын саклавы.
Баһадир халкымның көзгесе
Казанның тарихи вокзалы.

Югарыда язылган хисләремә сәбәпче булып вокзал тирәсендәге гүзәллек, яшеллек һәм гөр килеп мыжлап торган Казан вокзалы иде.

Идел янәшәсендәге вокзалдан Тукай урамы почмагына кадәр җәяүләп кайттым. Урамнарда яшеллек. Өченче бала

табу йорты каршындагы бакчага кереп китсәң адашырсың. Татарстан урамы үзәгендәге агачлар арасыннан трамвайлар күренми, йөз яшьлек имәннәр аларны сыйпап, озатып кала. Әйтәсе килгән сүземне укучы аңлагандыр. Мин шәһәребезне 1000 еллык бәйрәме уңаеннан яшеллеккә күмәр идем. Ул Германия шәһәрләре, Чехиянең Прагасындагы кебек йортларны күмеп киткән гөлбакча булсын иде. Хәзер Бауман урамын яшьләр урамы итеп төзеделәр. Анда арлы-бирле утырткан бер метрлы юкәләр сыра шешәләре арасында күмелеп калган. Көчле итеп кычкырып торган радиоалгычлар тавышыннан колагың чукраклана. Сыра шешәсе тотып, мәгънәсез каңгылдашкан кызларны күргәч, җаның сыкрый. Бу урамга икенче киләсе килми. Ләкин яшьләр килә бит, диярсез. Аларның бит башка барыр урыны юк. Ни өчен Кабан күле буйлатып, Г.Камал театрыннан алып, дамба ясап, аны яшеллеккә күмеп, ул дамбаны Вахитов, Павлюхин, Спартак урамнары чатына кадәр дәвам итеп, яшьләргә юл ачмаска?!

1. Аккошлар кебек парлашып, Кабан күлен әйләнсен яшьләр. Менә каян агылыр иде татар моңы. Бүгенге Бауман урамындагы сүгенү сүзләрен алыштырсын иде сафлык, пакьлек, татар кызларының гүзәл карашлары. Күлдә, аккошлар кебек, йөзләгән көймәләрдә яшь парлар серләшеп мәхәббәт учагында гөрләп янсыннар иде. Шундый ук дамбаны хәзерге Матбугат йорты тукталышыннан понтон күпере аша Горький исемендәге парк астына, аннан Милли-мәдәни үзәккә кадәр Казансу тирәли дә ясар идем. Яшьләр дамбасын Ерак Кабанда һәм Киров районындагы табигать биргән су буйларыннан җибәрер идем, әйләнсен-тулгансын яшьләр, дип, үземнең хәер-фатихамны бирер идем.

2. Казаныбызда тарихи кешеләребез бик күп. Шуларның яртысы диярлек хатын-кызлар. Кая соң ул бөек хатын-кызларыбыз исеменә бирелгән урамнар? Әлбәттә, мин кешелекнең иң гүзәл яртысы — милли хатын-кызларыбыз хакында сүз алып барам. Очучы Сыртлановадан тыш, татар хатын-кызларыбыз хөрмәтенә бирелгән берәр урам исемен атый аласызмы? Ни өчен мәшһүр композиторыбыз, калфаклы сандугач Сара Садыйкова исемендәге урам юк? Һәйкәл турында сүз дә алып бармыйм. Мондый данлыклы исемнәр укытучылардан, төзүчеләрдән, табиблардан һәм башка һөнәр ияләреннән бардыр. Мәшһүр артистларыбыз яисә җәмәгать

әһелләре дә андый хөрмәткә лаек лабаса. Зурлыйк, күтәрик аларны Казанның 1000 еллыгы белән бергә.

3. Безнең күп кенә язучыларыбызга, данлыклы кешеләребезгә вак-вак кечкенә музейлар ачылган. Мәсәлән, Казанда Шәриф Камал, Баратынский, Сәйдәш музейлары бар. Ә республиканың төрле районнарында урнашканнары күпме? Рәхмәт ул район җитәкчеләренә, хәзерге авыр заманда андый йортларны төзетеп, музейлар ачканнары өчен. Мәсәлән, Арча районында гына да 3 — 4 музей бар. Тукай музееннан тыш, башкаларына йөрүче юк диярлек. Арча районы үзәгендәге музейда Гариф Ахуновка, Гомәр Бәшировка да берәр өстәл-стенд бирелгән. Ләкин аларның иҗат юлы, әдәби байлыгы, республикага калдырган хезмәте бу өстәлләргә генә сыймый. Ватан сугышында катнашкан кырыклап язучының әдәби мирасы Берләштерелгән дәүләт музее бүлеп биргән подвал бүлмәләрендә саклана. Саба районында ачылган Ф. Хөсни музеена Казаннан, аның иҗатын сөючеләрдән берәү дә кайтмый.

Әйтәсе килгән сүзем шул. Казан үзәгендә, барлык вак музейларны берләштереп, республика күләмендә олпат әдәбият-сәнгать музее төзергә кирәк. Саклансын шунда Кәрим Тинчурин, Сара Садыйкова, Габдулла Кариев, Нәҗип Җиһанов, Хәлил Әбҗәлилов кебек шәхесләрнең даны. Марсель Сәлимҗановның Алтын битлегенең дә урыны шунда. Шушыларга өстәп мин тагын әллә нинди тәкъдимнәр ясар идем, алар файдасыз булып калыр. Ләкин бәйрәм үткәрүчеләргә тәкъдимем шул: Казанның барлык шәхесләреннән фикер җыеп, аларны барлап, эшлисен эшләп, туристлар шәһәре ясар идем. Агылсын бөтен дөнья халкы Казанга. Менә кайда ул бюджетка акча, менә шунда була зур байлык.

*2002*

## Уңай эшкә балта чапмыйк

Шушы елның 29 февраленнән алып һәр атнаның якшәмбе көнендә, ике сәгать дәвамында, Татарстанның «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе «Мәдәният дөньясында» дигән турыдан-туры эфирга корылган тапшыру оештыра башлады.

Мәдәният министрлыгы белән «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе җитәкчеләре бу җыенга бик нык әзерләнгәннәр. Беренче тапшыруга республикабызның культура тормышы

казанында кайнаган зур шәхесләрне җыйнап эфирга чыгардылар. Алар арасында музыка, әдәбият өлкәсендә танылган профессорлар: Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Миркасыйм Госманов, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Әнвәр Хуҗиәхмәтов, шагыйрь Ренат Харис, язучы Рабит Батулла бар иде. Тапшыруда Татарстанның халык артистлары, дистәләгән күренекле язучылар, композиторлар, рәссамнар, иҗат берлеге рәисләре һ.б. танылган шәхесләр дә актив катнашты. Анда бүгенге мәдәният торышы проблемалары зурдан күтәрелде, вакытында күтәрелде. Бик мактаулы эш.

Соңгы елларда мәдәният министрлыгының бу өлкәдәге хезмәтләре зур игътибарга лаек. Иҗат берлекләренә тәгаенләнгән байтак эшне министрлык үткәрә һәм финанслый. Бу бик мөһим мәсьәлә, акча булса, эш тә эшләнә. «Мәдәният дөньясы» тапшыруының да матди ягын министрлык хәл иткән, идеяне дә алар биргән. Беренче тапшыруда мәдәният министры И.Г.Тарханов үзе катнашты. Башка тапшыруларда аның урынбасарлары Р.М.Вәлиев, И.М.Ибраһимов та сөйләшүдә фикер алышучыларның һәм тамашачыларның күп кенә соравына тәфсилле җавап бирделәр. Илдус Габдрахман улы мәдәният өлкәсендә әле хәл ителәсе мәсьәләләрнең күп булуын һәм бу тапшыруга алынуның төп бурычын, аларны гомумхалык белән киңәшеп, уртак фикергә килеп уңай якка чишүдә дип белдерде. Ә республикабызның чагыштырмача яшь «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе, бу тапшыруга юл ачып, бик тә әһәмиятле эш эшләгән. Яңа тапшырулар туып торсын, яңа шагыйрьләр, композиторлар, җыр һәм сүз осталары бу тапшыруларда ачылсын, үссен. Халык кабул итмәгәннәре экраннардан, сәхнәләрдән төшеп калсын. Кыскасы, тапшыру миңа ошады.

Уңай күренешләр, бергәләп чишәсе мәсьәләләр турында «Мәдәният дөньясында» тапшыруында күп кеше фикере белдерелә, уртак нәтиҗәләргә киленә дип шатланып йөргәндә, кинәт «Шәһри Казан» газетасының «Җомга» кушымтасында (№16, 23 апрель, 2004) «Мәдәният дөньясы» — җыен буш сүз оясы» дигән зур күләмле мәкалә чыкты. Укып гаҗәпкә калдым, автор мәдәният дөньясы турындагы зур бер тапшыруны, шәхесләрнең фикерләрен, камыш тураган колхозчы кебек, чалгысы белән уңга-сулга кизәнеп, юкка чыгарып барган. Автор йә тормышны белми, яки сәнгать дөньясы белән якыннан таныш түгел. Белеме дә һәм, гомумән, журналистика өлкәсендәге осталыгы да чамалы күренде.

Инде мәкаләгә, аның эчке дөньясына кереп, андагы фактларга бәя бирү күзлегеннән караш ташлыйк.

1. Ленар Шәех тапшыру оештыручыларны һәм анда катнашучыларны нәрсәдә гаепли? «Сюжет дөрес оештырылмаган, имеш, Кол Шәриф кем ул, С.Сәйдәшев кем? Ник медицина университетына барып бу сорауларны бирергә?» Ә нигә бирмәскә? М.Җәлил, С.Сәйдәшевне дә белмәгән студент киң карашлы яхшы табиб булмаячак бит. Югары уку йортында уку чоры — студентка ныклы фундамент булдыру, күп яклап формалашу чоры. Татар теле өстенә чит телләр өйрәнү, спорт белән шөгыльләнү һ.б. чоры булырга тиеш. Мин директорлык вазифасын алып бара торган Зур концерт залында татар композиторлары әсәрләреннән алып дөнья классикларының әсәрләре дә башкарыла. Бөтен илгә танылган музыкантлар, дирижерлар монда булып китә. Чит илдән кайтып кермәгән күренекле җырчы Любовь Казарновская чыгыш ясаган концертта тамашачылар кемнәр иде диярсез? Зал тулы зыялы табиблар, инженерлар, КАИ, КХТИ, КДПУ, ветеринария, авыл хуҗалыгы вузлары укытучылары иде. Дистәләгән хезмәт ветераны, бушка кертүне үтенеп хат язып, урын сорап килделәр. Ләкин ун ел эшләү дәверендә бер генә гуманитар югары уку йортлары студентларыннан үтенеп шундый хат алганым юк, кызганыч. Казан консерваториясе безнең сәхнәдә ай саен 7 — 8 концерт бирә. Ай саен диярлек Татарстанның дәүләт симфоник оркестры, кыллы квартеты концертлары була. Татар композиторларының әсәрләрен оркестр башкаруында булачак язучылар, журналистлар, укытучылар, рәссамнар тыңласа зыян итмәс иде. Аларның эчке дөньясы баер гына иде. Ләкин залда аларны сирәк күрәбез. Хәер, яшьләр генә түгел, урта буын вәкилләре дә бездә сирәк була. Ә менә ветеран-журналист Мәгъсүм Гәрәев бер генә очрашуны да калдырмыйча йөри. Аның шул тамашаларга багышлап җитди мәкаләләре дә әледән-әле вакытлы матбугатта чыга тора. Әйе, теләгән кеше вакыт таба бит. Иңендә ил кайгысын күтәреп, халык язмышын хәл итүче җитәкчеләр дә елына биш-алты тапкыр бездә булып китәләр.

Ленар Шәех фикеренчә, С.Сәйдәшевнең кем икәнен белер өчен, мәдәният, сәнгать өлкәсендә хәбәрдар булган концерт, театр урынын сайларга кирәк.

Музыка — ул сандугач, һәр һөнәр иясенең күңеленә кереп ояларга мөмкин. Европа архитектура үрнәкләре югары-

лыгындагы бу бинага килеп, ун ел дәвамында бер тапкыр да музыка тыңламаган артистларны беләм. Әгәр югары уку йортын бетергән бер студент, кулына газета алып та укымыйча, диван сата торган кибеттә бәя әйтеп торырга эшкә бара икән, әлеге тапшыруны оештыручыларның гаебе нәрсәдә? Алар безгә бары бүгенге яшьләрнең (бөтенесе түгел) фикере тар, эчке дөньясының буш икәнен генә ачып салалар. Борчылырлык әйберләр барлыгын раслау — аларның төп бурычы. Бу бәладән котылу — ул инде икенче мәсьәлә.

2. «Алып баручылар булдыксыз. Чөнки алар турыдан-туры эфирга чыгарлык дәрәҗәгә үсеп җитмәгән», — дип дәвам итә мәкалә авторы. Бәлки, борчылырлык урын да бардыр, телевизор экраны — шул ук сәхнә бит ул. Элек дикторлык хезмәтенә профессиональ театрларның актерлары катнашында уздырылган конкурс аша алалар иде. Дистәләгән еллар дәвамында радио-телевидение тапшыруларын алып барган Иркә Сакаева, Айрат Арсланов, Әминә Сафиуллина, Мәрьям Арслановалар башта театр сәхнәсендә эшләделәр, театр йолдызлары булдылар. Бүген бу роль радио-телевидениедә журналистларга күчте. Ә журналист ул — укыла торган текст, сценарий авторы булырга хәзерләнгән белгеч. Актерлык осталыгы, нәфис сүз белеме анда юк. Авыз аппараты дөрес сөйләмәгән журналист телевидение экранында һич тә Ринат Таҗетдинов дәрәҗәсендә була алмый шул. Ләкин әлеге тапшыруны алып баручы Зәмирә Рәҗәповага мин каты бәрелмәс идем. Тәҗрибәле актерлар да каушап кала алырдай ике сәгатьлек беренче тапшыруда күреп, мин аңа гаҗәпкә калдым. Алып баручының бурычы — миллионлаган телевизор караучы тамашачылар белән тапшыруда катнашучыларны бәйләп, тапшыруның бурычын үтәүдә. Буйсын, нәфислек, фикер агышы, сөйләм культурасы — Зәмирәдә бар, Ходай осталыкны биргән. «Яңа гасыр» каналы өчен бу зур табыш. Тик аны югалтмый үстерергә генә кирәк.

«Мәдәният дөньясы» — җыен буш сүз оясы» мәкаләсенең авторы Ленар Шәех бу кызны әдәбиятны, сәнгатьне, мәдәниятне рәтләп белмәүдә гаепләп ялгыша. Мин Зәмирә Рәҗәпова йөзендә Мәскәү телевидениесенең ОРТ каналында «Основной инстинкт» тапшыруын алып баручы Светлана Сорокина образын күрдем. Әлбәттә, икенче тапшыруны алып баручы Наилә Яхина миндә сораулар тудырды. Сәхнә, экран, сәнгать яшьлекне ярата. Бирердә уйланырга кирәк.

3. Авторның күтәргән темалары: «Г.Камал театры артист-

лары ни өчен бүгенге көндә авыллар буйлап гастрольгә чыкмый?», «Китап басып тарату», «Яшь талантларга игътибар җитмәү». Композиторлар, нәшриятлар эшчәнлеге турында да сүз бара. Мәкаләдә китерелгән фикерләр бүгенге коммунистлар митингка җыелгач, хәзерге җитәкчелекне сүгү күренешенә охшап калган. Егет башында социализм чоры таләбе — кемнәрдер барысын да эшләп бирергә тиеш. «Яшьләргә» дигән девиз астында «дайте» дип кычкыру вакыты узды бит. Егерме беренче гасырда яшибез, башка гасырда таләп тә башкача. Телевидение дә бүгенге заман соравына җавап эзли, тавышы ишетелүне тели, проблемаларны чишү юлын табарга тырыша.

Ленар Шәех тә бит, йөзләгән сорау биреп, бер сорауга да җавап-чишелеш әйтми. «Өч тапшыруның икесендә «фон» буларак утырдым, чөнки яшьләргә сүз бирмәделәр»,— дип, «Яңа гасыр» каналына үпкәләвең хаклы түгел. Мәсәлән, алып баручы алдан ук мине: «Тапшыру барышында һәр сорауга карата үз фикерегез булса, бәхәскә керә аласыз», — дип кисәтеп куйды. Сез сөйләшүдә катнашмагансыз, димәк, әйтер фикерегез булмаган, «фон»да гына калгансыз. Менә мин, фикерем булгач, ике-өч тапкыр чәчрәп чыктым, тамашачы биргән сорауны ничек чишү юлын әйттем. Мәкалә буенча сезнең үз фикерегез үзегезгә каршы килә. Бер урында «китапларның укылмавы, аларның, сатылмыйча, складларда тузан җыеп ятуы» турында, икенче урында «күп китапларның тиражын арттыру кирәклеге» турында әйтәсез. Басылганнары тузан җыеп яткач, нигә аларның тиражын арттырырга, тузан җыймый торган яңа склад ясау өченме? Мин аңламадым. Китапларны тузан җыеп ятудан коткару юлын әйтегез сез безгә, энем.

4. «Татар зыялылары арасында бердәм уртак фикер юк. Телевидение татарлар өчен эшләми»,— дип дәвам иттерәсез. Республика зыялыларына бу зур гаеп ташлау. 1937 елны Кави Нәҗми, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш кебек күренекле шәхесләр шундый мәкаләләрдән соң юкка чыктылар. Әле ярый гасыр башка, еллар башка, юллар башка. «Яңа гасыр» телевидениесенең «Татарлар» тапшыруын гына алсак та, күрәбез ки — ул Россия татарлары өчен генә түгел, бөтендөнья татарлары өчен дә эшли. Дөрес, аны башка милләтләр дә карый, ә безнең республикабызның дәрәҗәсе ул тапшырулардан соң күтәрелә генә. «Татар барда — хәтәр

бар», — дип, чит илләрдә төрле милләт кешеләре тик карап утырсын безне.

Мәкалә язганда, мондый тарихи бер вакыйга искә төште. 1958 ел, мин — студент. Күренекле язучыларның әсәрләре, китап булып чыкканчы, әүвәл «Совет әдәбияты» журналында бастырылып, укучылар хөкеменә тапшырыла иде. Мирсәй Әмирнең журналда чыккан «Саф күңел» романын тикшерү өчен милли китапханәгә җыелдык. Ул чорда әсәрне укучыга тәкъдир итү зур бәйрәм төсе ала иде. Миңа да сүз бирделәр, әтәчләнеп, башны акыллыга салып, әсәрне тар-мар китердем. Җүләр баш, мин кемне тетеп атам бит — совет чорындагы классик прозаикны. Автор дәшми генә тыңлап утырды да, соңыннан торып, халыкка: «Бу егет кемдер тарафыннан бушка ялланган», — диде.

«Мәдәният дөньясы» — җыен буш сүз оясы» мәкаләсе авторы Ленар Шәех тә минем яшьлегемне кабатламый микән?!

# *Эчтәлек*

Еракка яңгырасын безнең җыр! *Р.Фәйзуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**Мин әнкәйнең бер бөртеге идем**

Мин әнкәйнең бер бөртеге идем. *И.Дәүләтшин* көе . . . . . . . . . . 6
Туй күлмәге. *М.Имашев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Яшьлегем эзләре. *Р.Хәсәнов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Мәңгелек ут. *Р.Гобәйдуллин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Әйләнеп кайтыгыз. *Р.Хәсәнов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Безнең яшьлек нидән башланды? *С.Садыйкова* көе . . . . . . . . . 14
Җиңү көне җиңел бирелмәде. *С.Садыйкова* көе . . . . . . . . . . . . 16
Бирсәнә түзем. *И.Закиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Туган җирсез яшәү юк сыман. *С.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . 19
Минем өчен син генә. *Ф.Әхмәдиев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Көт мине. *Ф.Хатыйпов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Язгы җыр. *Р.Хәсәнов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Тиңсез ярату. *Ф.Бариев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Уңҗиде яшем. *Р.Нәгыймов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Әткәм сулышы. *С.Садыйкова* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Май аенда кар ява. *И.Байтирәк* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Айнымас Самат. *М.Макаров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Бүләк ит син. *С.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Синең турында. *Ф.Хатыйпов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Аккош белән серләшү. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . . . . . . . . . 36
Сагынам Балык Бистәсен. *И.Закиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . 37
Иркәләнер көннәр алда әле. *С.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . 39
Халкым җыелган җирдә. *И.Якупов, З.Мөхәммәтдинов* көе . . . . . 40
Гүзәл затка бир түзем. *И.Байтирәк* көе . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Сагыныр өчен. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Туй балдагы. *С.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кыр казларын бергә каршылыйк. *М.Иванов* көе . . . . . . . . . . . 48
Бәхилләшмим — саубуллашам. *Р.Нәгыймов* көе . . . . . . . . . . . 50
Мин яшәргә тиеш шул хакка. *Р.Курамшин* көе . . . . . . . . . . . . 51
Йөрәгем бит һаман яшь әле. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . . . . . 53
Өлешемә тигән, әй көмешем! *А.Хөсәенов* көе . . . . . . . . . . . . 54
Сагыну. *Р.Курамшин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Тол ханым. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Васыять. *Р.Гатауллин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

Күзләремнән килеп кара. *И.Байтирәк* көе . . . . . . 60
Клара. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . 63
Мишәр кызы. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . 64
Кайтыр идем. *М.Имашев* көе . . . . . . 66
Синең күзләрең. *М.Имашев* көе . . . . . . 67
Мария, Лина, Натуша. *З.Хәйретдинов* көе . . . . . . 68
Сулар үргә акмый, диләр. *И.Сафин* көе . . . . . . 70
Бер авыл баласы мин. *Ә.Шаһиморатов* көе . . . . . . 71
КамАЗ төзүчеләр җыры. *С.Садыйкова* көе . . . . . . 72
Казанның тарихи вокзалы. *Ш.Тимербулатов* көе . . . . . . 73

**Чиксез мәхәббәтем бар**

Бик якын син, Яншык киче . . . . . . 76
Күз . . . . . . 76
Җылы җилләр исә . . . . . . 77
Туган якның якты иртәсе . . . . . . 77
Урай урманы . . . . . . 78
Гомер хакы . . . . . . 78
Кабер ташына язылачак шигырь . . . . . . 79
Үзенә дә төште . . . . . . 79
Кырыс җилләр . . . . . . 80
Сөеләсе изге бер җан калды . . . . . . 80
Мәхәббәтем бар . . . . . . 80
Сер . . . . . . 81
Казанка яры биек... . . . . . . 81
Тиңләрмен . . . . . . 82
Бер шагыйрьгә ияреп . . . . . . 82
Үпкәләмә . . . . . . 82
Ялгыз ай тиңдәшен эзли . . . . . . 83
Тиңләдем . . . . . . 83
Акчарлаклар үкси һаваларда . . . . . . 84
Су һаман шаулап ага... . . . . . . 84
Тәңкә карлар . . . . . . 85
Кем кирәк? . . . . . . 85
Мин сиңа үпкәләмим . . . . . . 86
Ярсу һәм айну . . . . . . 86
Туган ягым . . . . . . 87
Гармун моңы . . . . . . 88
Син генә... . . . . . . 88
Ялгыз аккош кайда оча? . . . . . . 88
Моңлану һәм сызлану . . . . . . 89
Тау менгәндә . . . . . . 89
Яшен . . . . . . 90
Буран . . . . . . 90
Ничәнче ел ялгыз аккош кайта . . . . . . 91
Ирләргә тиң пакь ханымнар . . . . . . 91
Туфрагында — юлаучы . . . . . . 92
Җил . . . . . . 93

Бердәнбере идем җиденең . . . 93
Сабантуй көннәрендә . . . 94
Агар су булсам иде . . . 94
Газиз әнкәм йортына . . . 95
«Бер карасаң...» . . . 96
Күккә юлланган уйлар . . . 96
Ил бәласе . . . 97
Яшәү сере . . . 97
Сагындым . . . 98
Кар суында шәл ага . . . 98
Әй, гафу итсәнә, йөрәгем . . . 99
Серле йолдыз — Алия . . . 100
Фәйрүзә . . . 100
Үзең өчен генә өз син мине . . . 101
Алма-Атаның алмасы . . . 101
Соңгы үпкә . . . 102
Күкләр алдамады . . . 102
Юк, кеше яши . . . 103
Ташлама, шигърият . . . 104
Өйрәттеләр . . . 104
Күңелдәге моңнар . . . 105
Хата киңәш . . . 105
Сызлану һәм юану . . . 106
Энекәш . . . 106
Ирләр йөрәге . . . 107
Уйлану . . . 107
Кеше һәм заман . . . 107
Көнбагыш . . . 108
Модалар . . . 108
Карурман . . . 109
Дөрес сүзгә җавап юк . . . 109
Солдат күңеле . . . 110
Тикшерделәр... . . . 110
Сыраханә янында . . . 110
Гарип калды . . . 111
Юлга чыксаң . . . 111
Кеше түзә . . . 111
Көттермәгез . . . 112
Нәрсә әйтим . . . 112
Люциякәй . . . 113
Чистару . . . 113
Мәхәббәт сынавы . . . 114
Күңел дулкыны . . . 114
Яшьлегем үткән урам . . . 115
Бу җир ял йорты түгел . . . 115
Кайда соң? . . . 116
Солтанлы мәктәп . . . 117
Ыруг . . . 118
Мин булмам . . . 118
Киек казлар кайта . . . 119

Үлем дәшкәч . . . 119
Килеп чыгар әле каршыма . . . 120
Сынмадым-сыгылмадым . . . 120
Ап-ак, диләр . . . 121
Сөю килгән кыз бала . . . 121
Алмалары пешәр әле . . . 122
Илдар Юзеевкә . . . 122
Нигә башны салга салырга . . . 122
Ләбиб Леронга . . . 123
Рәшит Шиһапка . . . 123
КамАЗ күтәрелә . . . 123
Көймә чайкала . . . 124
Җыр пәйгамбәре . . . 124
Яңа елда яңа теләк . . . 125
Өр-яңа председатель . . . 126
Әби белән бер кыз диалогы . . . 128
Бер табактан ашаучылар . . . 129
Язгы мәхәббәт . . . 130
Мөхәммәтнең җаны тавыш бирә… . . . 130
Яшәгәндә булсын . . . 131
Хатирәләр яңарганда . . . 131
Туры сүз . . . 132
Татар язмышы . . . 133
Мәңгелек сер . . . 133
Ахун бабай . . . 134
Аяныч . . . 134
Булса да . . . 135
Уфтанмагыз . . . 136
Яшәвемнең бизмәне . . . 136
Язмыш җәзасы . . . 137
Мирасчы карт . . . 137
Сихри көч . . . 138
Милли җыр . . . 139
Туган тел . . . 139
Ник . . . 140
Кем белә . . . 140
Югалтулар . . . 141
Айны, татар! . . . 142
Авыр мизгелләрдә . . . 142
Алданма . . . 143
Сүнде шагыйрь . . . 143
Кайтыйк әле . . . 144
Сызлану . . . 144
Аерма . . . 145
Мирас . . . 146
Сагыш . . . 146
Яшәү . . . 147
Күңел сәяхәте . . . 147
Капма-каршы . . . 148
Бәхәс . . . 149

Бүрек белән түфлә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Кайсы җан ничек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Хәрәкәттә — бәрәкәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Онытмагыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Могҗиза идең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Чорлар алышынганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Буран моңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Зәхмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Рәхмәтле булыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Ничек аңларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Ачык хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Тылсымлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Төштә генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Халәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Идеал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Тартылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Нәрсә әйтим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Утлы мизгелләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Кәсепчеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Кирәклеләр китә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Төрек каешлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Заман киңлегендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Ыруг . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Башкала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Бурыч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

## Ак болытларга карап

Ак болытларга карап... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Барыбер сагынам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Кадерлеләр генә хәтердә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Еллар аша дәшәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Казан кичләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Без дә чаң сукмасак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Тәгәрмәчләр җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Нәфисә Васыйлова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Бердәмлектә — көч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Таләпчәнлекне киметмәскә . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Театр — заман көзгесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Кама буе — туган як . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Узган гомер — калган хәтер . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Мин шуңа сөенәм... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
Яңа йортта яңа хуҗа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Башкалабызның сәнгать йөрәге . . . . . . . . . . . . . . 223
Казаным, Казаным... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Уңай эшкә балта чапмыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229

Литературно-художественное издание

*Шигапов Мансур Ахметович*

**Мои песни еще не спеты**

Песни, стихи, публицистика

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Музыкаль мөхәррире *И.И.Байтирәк*
Рәссамы *Г.Җ.Хисмәтуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, С.Н.Мифтахова, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.04.2005.
Форматы 84×108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 12,60 + рәс.0,84.
Шартлы буяу-оттиск 16,38. Нәшер-хисап табагы 13,34 + рәс.0,92.
Тиражы 2000 экз. Заказ А-277.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jaһat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jaһat™.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.